Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

03

март 2017

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

«ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ»

Чыңгыз Айтматов

64 нче бит

ФӘЙЗРАХМАН ӘМИНОВ. «СУ БУЕ»

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВКА – 60 ЯШЬ!

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Республикасы Президенты:

«Безгә күп нәрсә мирас булып калды – куәтле нефть һәм нефть химиясе сәнәгате, үзебезне тәэмин итәрлек энергетика, зур үсеш алган машина төзелеше. Әмма бүген республика алдында яңа бурычлар тора. Модернизация генә тотрыклы үсеш һәм алгарыш, гражданнарга мул тормыш бирәчәк. Безнең максат – республика, инновацияле хезмәтләрне кулланучы булып кына калмыйча, аларны үзе эшләүчегә әйләнергә тиеш!»

25 март, 2010 ел

Минтимер Шәймиев,
Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе:

«Рөстәм Нургалиевич – хәрәкәт кешесе, ул һәркайда һәм бар нәрсәдә дә алга барырга омтыла – эш-гамәлләрдә дә, дөньяны танып белүдә дә, яңа белемнәр һәм күнекмәләр алуда да. Һәм бу республиканың беренче заты шундый булырга тиешлектән генә түгел, ул табигате белән шундый: эшнең асылына төшенмичә һәм тиешле чишелеш тапмыйча, тынычланмый...

Хәтерлим, Республика Президенты булып бер ел эшләгәч, ул: «Иң мөһиме – без булганны таркатмадык, бөтенесен дә саклыдык һәм барысы да нормаль эшли», – дип әйткән иде. Вакыт-вакыт миннән: «Үз алмашыгыздан канәгатьме?» – дип сорыйлар. Җавап бирәм: «Мин барысы да тәртиптә булыр дип белгән һәм көткән идем, әмма ул икътисадта гына түгел, ә сәясәт өлкәсендә дә шулкадәр тиз йогынтылы шәхескә әйләнер, дип күз алдыма китермәгән идем. Иң әһәмиятлесе – ул татарстанлыларның ышанычын аклап килә, кешеләр аны яклый һәм үз язмышларын туган республика белән бәйләп карый».

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
3 (279)
март 2017

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АЖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

42

50 ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ. *Габдерәшит Ибраһимов*

74 ЖАН СЫЗЛАВЫНДА ТУГАН «ГАЛИЯБАНУ». *Рәфыйк Шәрәфиев*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Сажидә Сөләйманова*

ТАРИХИ МИРАС

4 Болгар. Капитан коесы
6 Илчеләр. *Ә.Мөхәммәдиев*
10 «Сезгә миннән ак теләк...» *М.Фәйзи*
16 Ислам галәменең казык йолдызы. *Х.Вәлиәхмәтов*
21 Гаурәт саклау. *Д.Гатина-Шәфыйкова, И.Шәфыйков*
27 Моңлы хатын Бибигайшә.
32 Жефет калага сәфәр. *С.Шәмси*
38 Бабаларым жирендә. *Ф.Табеев*

ТАТАР ГАМЕ

42 Татарстан Президенты

ДИНИ МИРАС

46 «Мәчеткә картайгач йөрермен...» *Г.Баруди*
50 Ислам дөньясы. *Г.Ибраһимов*
56 Зәкиулла Минһажев: «Аналарыбыз яшәү көчен каян алган?!»

62 МИЛЛӘТ ХӘБӘРЛӘРЕ

ӘДӘБИ МИРАС

64 Кутадгу билик. (Котайткыч белем). *Й.Баласагуни*
68 Чыңгызханның ак болыты. *Ч.Айтматов*
74 Жан сызлавында туган «Галиябану». *Р.Шәрәфиев*
79 «Шаһнамә».

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

82 Сәгыйть Рәмиев

ХӘТЕР САНДЫГЫ

84 Утлы кисәү. *Л.Гыйльфанов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

88 **Театр елъязмачысы.** *Ф.Дәминова*
91 **Илче күчтәнәче.** *Р.Вәли*
96 **Өстәл рәвешле гөслә.** *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

98 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

100 **Ислемай савытлары.** *Г.Җәләлова*
102 **Бәрәкәтле урман тарихы**
106 **Иске Казан.** *Р.Фәхретдинов*
112 **Ядкярләргә – бер гасыр.** *Р.Садыйкова*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»:** *1916 елның март ае*

ШАЯН МИРАС

116 **Кадыйр Сибгатуллинның мәзәкләре**

118 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Март*
119 **Мирасворд**

Заказ №А-475. Тираж – 1700 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 28.02.2017
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән
туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61
телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Р.Фазлыйәхмәтов төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, шулай ук томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Су буе». Киндер, майлы буяу.
Ф.Әминов рәсеме



САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА
(1926-1980)

Кешеләрне дус һәм туган иткән олы бер хис – күңел көзгесе.

* * *
Уйласаң – уй,
җырласаң – җыр,
тыңласаң, моң сызыла...

* * *
Дүрт ягым кыйбла, димәгез,
Бер генә була кыйбла...

* * *
Авыллар күп, илләр, калалар күп, ә җир шары була бер генә.

* * *
Кеше барыбер кошлар нәселеннән!
Төшләремдә очам кош булып.
Ничә очып, ничә мәтәлсә дә,
кеше сайлый барыбер кош юлын.

* * *
Үрләр менми җырлар тумас иде Җирнең матурлыгы турында.

* * *
Олы хисләр – күңел түрләрендә, тел очында йөрсә, җил алыр.
Яратуың артык тирән булса, «яратам», дип әйтү бик авыр.

* * *
Ни белән үлчәнә үткән гомер?
Калган эзләр белән,
Кеше күңеленә орлык итеп
Салган сүзләр белән!

* * *
Туган җир ул кеше күңеленә ана сөте белән салына.

* * *
Баллы, майлы мул табыны белән, ил байлыгы белән күз ямьле.

* * *
Гомер алда – үлчәүләргә сыймас хыялларың барда.

* * *
Ниятләрем яулап алу булса, төзәми дә туры тидерәм.

Текстны ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Болгар. Капитан коесы

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Болгар шәһәрлегенең төньяк-көнчыгыш өлешендә, Иерусалим чокыры тамагында Капитан коесы урнашкан. Аңа бу исем XVIII гасырда әлеге җирләрне өйрәнүче капитан Н.П.Рычков хөрмәтенә бирелгән. Татарлар чишмәне «Габдрахман сәхабә коесы» дип атыйлар һәм аның барлыкка килүен Болгар җиренә Мөхәммәт пәйгамбәр сәхабәләре килү белән бәйлиләр.

Риваять буенча, бу чишмәнең шифалы суы Габдрахман сәхабәнең юл таягы орынган урыннан ургып чыккан, әлеге су хан кызын савыктырырга булышкан. Кызының савыгу могҗизасын күреп, хан һәм аның иярченнәре ислам динен кабул иткән. Бу риваять Гренада сәүдәгәре, гарәп телендә сөйләшүче Хәмит Әл-Гарнати язмаларында тасвирланган вакыйгалар нигезендә туган. Хәмит Әл-Гарнати Идел буе Болгар дәүләтенә 1135 елда килгән, XI-XII гасырларда Болгар казые һәм тарихчысы булган Якуб ибне Әл-Болгариның китабын укыган.

Әлеге тарихи ядкярнең тагын бер исеме – «Капитан коесы» рус сәяхәтчесе һәм географы Николай Рычков (1746-1784) исеменә бәйле. Ул Петербург фәннәр академиясенең Петр Симон Паллас җитәкчелек иткән экспедициясендә катнашкан. 1769 елда капитан Рычков кое янындагы территорияләрдә тикшерүләр алып барган. Бирелдә саз рудасы һәм дары ясау өчен кирәкле матдә – селитра табылган.

Комплекс территориясен реконструкцияләү һәм төзекләндерү «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе проекты нигезендә башкарылган. ■

Безнең мирас №3 март 2017

ИЛЧЕЛӘР

Әзһәр Мөхәммәдиев

Р.Заһидуллин рәсеме

Икенче көнне таңнан торып, юлларын дәвам иттеләр. Диңгезгә таба төшкән саен, җәелеп яткан дала чүлгә тартым була барды. Яшеллек азайганнан-азайды. Кичкә таба алар, Идел буен калдырып, уңгарак каерылып, кешесез һәм мал-туарсыз иксез-чиксез дала буйлап Каф тавы төбәген чамалап китеп бардылар. Кояш даланы яндырып көйдерсә дә, яздан калган кайбер ярукларда[1] су күренә, ә кайда су – анда инде табигатьнең җанлы булуы, тормышның кайнап торганлыгы сизелә: камыш арасында үрдәк бакылдаша, балык сикереп уйный, йә булмаса, балык сагалап бер аягында катып торган челән күренә. Шундый урыннарның берсендә алар тагын бер төн уздырдылар.

– Никадәр юл киләбез, шундый иркен далалар башланды, бернинди кеше, йә булмаса мал-туар юк, – диде Тәкин, икенче көнне үзенең болгар кешесе буларак гаҗәпләнүен белдереп, – мангуллар килүеннән куркып качып беткәннәр, күрәсең.

– Бу җирләрне күчмә кабиләләр «Әтелкүзе кышлавы» дип атыйлар. Бирeдә мал-туар йөртү тыелган, Тәкин. Әлбәттә, сүз җәйге айлар турында гына бара.

– Ни өчен?

– Көзге яңгырлардан соң дала үләннәре тагын да яңара, яшәрә төшә. Үзәннәрдә тагын да ныграк булып печәннәр күтәрелә. Ләкин аңа беркем дә тими – биредә борын заманнардан калган гадәт буенча печәнне чапмыйлар, малдан да таптатмыйлар. Чөнки таптатып бетерсәң, кышка малга ризык калмас иде. Кышын бирегә Каф тавы яки Идел-Тын сулары тугайларыннан күчмә кыпчак кабиләләре мал-туарын куып

Башы 1 нче санда. «Илчеләр» – «Чыңгызхан хәйләсе» әсәренең чираттагы бүлеге.
[1] Ярук – язгы сулар сакланган һәм елганы хәтерләткән тирән чокырлар һәм күлләр.

китерә һәм аларны иркенгә, шушы мул печәнле далаларга җибәрә. Шуңа күрә Кыпчак яки Кыпчак даласы дип тә атала торгандыр инде ул.

– Кызык. Каян боларның барысын да белеп бетердең син, ә, Бибарс?

– Белмичә, мин бит Бөрҗаннан, үземнең йөргәнем бар.

– Күченепме?

– Юк, эти мәрхүм шул далаларда яшәгән күчмә кабиләләрдән елкыларны көтүе белән сатып алып, йә Болгарга, йә Хәрәземгә илтеп сатып, сәүдә белән шөгыльләнә иде. Мин дә этигә ияреп йөргәләдем. Биредәге җирләрне кайберәүләр Болгар, ә кайберләре хәзер дә Хазәр даласы дип атый.

– Боларын да йөреп белдеңме?

– Юк, боларын укып белдем, – диде Бибарс, Тәкиннең шаяртуыннан көлеп.

Саксиннан чыкканның дүртенче көнендә кичкырын гына алар еракта зәңгәрләнеп торган Каф тавы сыртларын төсмерли башладылар. Караңгы төшкәнче диярлек барсалар да, әлеге таулар бераз гына да якынайган кебек тоелмадылар.

Эңгер-меңгер вакыты җиткәч, яр астына ук төшеп, камышлы бер күл буенда атларын тышаулап утларга җибәрделәр һәм учак яктылар. Ләкин кичке ашны ашарга да өлгермәделәр, яр өстеннән атларын дөбердәтеп чаптырып, бер кул җайдак килеп чыкканын сизми дә калдылар. Ул арада җайдаклар асылган казанны, таганны һәм учак янына куелган башка әйберләрне аударып, таптатып, арыган юлчыларны урап та алдылар.

Атын өскә меңгерердәй итеп биетеп торган бер җайдак кылычы белән кизәнде. Бибарсның тыныч кына торганын күреп, күрәсең, чапмады. Шул ук вакытта бу гади бер җайдакның тәкәббер, миһербансыз киң битле йөзенә карап, Бибарс аның шул Сүбәдәй дигән явызның нөкәре икәнлеген аңлады. Ул болгар патшасы мөһере сугылган кәгазьне куеныннан чыгарып күрсәтте.

– Без – илчеләр. Сүбәдәй баһадир ыстанына барабыз, – диде.

Ләкин бу сүзләр нөкәрләргә бернинди дә диярлек тәэсир ясамады. Алар илчеләрнең кылычларын алдылар һәм атларына атланырга рөхсәт иттеләр. Бибарстан ат тезгенен алып, әлеге нөкәр үзенең ияренә бәйләп куйды – ул аның табышына әйләнде, күрәсең. Куш атларны исә башка җайдаклар алды.

Мангул нөкәрләренең мондый мөгамәләсеннән ачуы чыккан Тәкин, куенына белеген тыгып маташкан Бибарска карап, мәгълүм болгар мәкален әйтеп салды:

– Белгәнгә – белек, белмәгәнгә – чыгар да селек! – диде.

Мангул нөкәрләре нәзбереклэнеп, җиләс һавалы күл буенда, яшел үләнле үзәннәрдә төн үткәрә торган халык түгел иде, күрәсең. Алар төне буе бардылар. Бары тик таң атканда гына еракта җәелеп яткан киң һәм зур үзәндә бик күп тирмәләр, ә алар янында утлап йөргән меңләгән ат көтүләре күреп, Бибарс үзләренең Сүбәдәй ыстанына якынлашуларын аңлады. Ул монгол тирмәләре тирәсендә кыйммәтле әйбер өемнәрен күрде. Болары аңа Хәрәземнән үк таныш булган, талап алынган ганимәт – сугыш табышлары иде. Ә кайбер урыннарда сугышчыларны тәэмин итәргә юл ризыгы төяп йөртә торган ике тәгәрмәчле каплаулы кибет-арбалар күрде. Шул ук вакытта, алар арасында өстенә зур тирмә корып куелган, егермешәр үгез җигеп тарттырыла торган авыр арбалар юклыгына игътибар итте. Димәк, Сүбәдәй чирүе җиңел коралльы җайдаклардан һәм тизйөрешле олаулардан гыйбарәт иде.

Ыстан янына җиткәч, монгол нойоннары атларыннан төштеләр. Унбашы, ә бу унлыкның тоткаклар икәнлеген юлчылар төшенгән иде инде, Бибарстан болгар патшасы тамгасы сугылган белекне алды. Тәкин үзләренең атларын каядыр алып китеп яткан нойонны туктатты.

– Тукта әле, абайлы дустым, – диде ул. – Мин синең бик шәп егет икәнлегеңне аңлыйм, әмма ат өстендәге ияргә тагылган төеннәрне бир!

Унбашы, ишарәләп, бирергә рөхсәт итте. Тәкин ияргә бәйләнгән төеннәрнең бер-

сен чиште һәм кечкенә генә юл тирмәсен унбашы күрсәткән бер читтәге шундый ук тирмәләр торган урынга, күрәсең, мондый илчеләр бер алар гына түгел иде, корып куйды. Арыган, борчулы төн уздырган илчеләр тирмәгә кереп кояш чыкканчы бераз ял итеп алырга дип яттылар.

Ләкин озак ятарга туры килмәде. Тылмач ияртеп килгән әлеге унбашы аларны иртүк уятып, Сүбәдәй баһадир катына керергә әзер булып торырга кушып китте. Бибарс төеннән мондый очракта кияр өчен дип алынган яхшы ефәк чөгәсен чыгарды. Үтүк[2] булмаганга күрә, ул аны куллары белән сыпыргалаштырып, рәтләп киде.

Ул урамга чыкканда кояш әле офыктан күтәрелеп кенә килсә дә, урда җанланган иде инде: нойоннар атларын чистарта, иярли, ә кайберләре хәрби сәфәргә әзер булып, боерык көтә. Көбә күлмәкле һәм кораллы бер төркем нойон, йончыган атларын куалап, каяндыр кайтып керде. Нойоннарның иярләренә төеннәр тагылган иде.

Унбашын көткән арада Бибарс ыстанның зурлыгын чамаламакчы булып, далага таба атлады. Төссез, ләкин хуш исле вак һәм сирәк дала әреме арасында яңа күтәрелеп килгән кояш нурлары астында чикерткәләр сикерешкәне, кырмыскаларның, кояш кыздыра башлаганчы дипме, каядыр ашыкканы күренә. Ул күп тә китәргә өлгермәде, нинди дер ят бер кеше авазын ишетте, җирдә яңа казып чыгарылган балчык өеме һәм ерак та түгел халык тулы тирән баз күреп катып калды. Арырак сөңгеле бер нөкәр йөренгәне күренә. Баздагы халык яшь ирләрдән гыйбарәт булып, алар әсир төшкән кешеләр иде булса кирәк. Ул якынрак атлады. Сул күзенә канлы чүпрәк бәйләгән бер әсир, сыңар күзе белән Бибарска карап, хәлсез тавыш белән:

– Әй, алан[3], су бирче! – дип ялварды.

Бибарс тиз генә билендәге күн тышлы, су тулы яссы савытны ычкындырып, нойон күргәнче базга ыргытты. Берничә кул берьюлы савытны эләктереп алды. Су әлеге әсиргә эләктеме-юкмы, анысын абайлап өлгермәде – тизрәк кире борылды. Бу аның күңеленә гомере буе, нигә шунда тыныч кына барып, савытны ялварган әсиргә бирмәскә инде, дип үз-үзен газаплый торган бер күренеш булып уелып калды.

Бибарс тирмәдән ерак түгел генә аны көтеп торган тылмач янына килде. Анысы күптән кырылмаган җитү сакаллы, зур кәкре борынлы, каратут йөзле утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге кеше иде.

– Кемнәр бу? – дип сорады егет, базга ымлап.

Мондый нәрсәләргә күнеккән кеше иде ул, күрәсең, иңсәсен генә сикертте, дәшмәде. Бибарс, Баян вәзирнең киңәшен тотып, кесәсеннән бер учка якын көмеш болгар дирһәме чыгарды һәм аларны учында сикерткәләп торды. Тылмачның күзендә комсызлык күргәч, ул аларны аңа сузды.

– Ал. Болгар патшасы биргүе[4].

– Рәхмәт. Тик Сүбәдәй баһадирның биргү яратканлыгын онытма. Аңа көмеш кенә җитмәс.

– Хуҗаң турында ныграк кайгыртасың, ахры?

– Алтын-көмеш һәйбәт нәрсә, әмма җан кадерлерәк.

– Исемең ничек?

– Фирүз. Фарсы мин.

– Сугышларда катнашмадыңмы?

– Мин, тылмач буларак, һәрдаим сугышта – Сүбәдәй баһадир катында. Дөрес, ул үзе башкалар кебек кылыч болгап чиру алдыннан чапмый, ә оста шакмакчы[5] тактада уйнаган кебек бәрелеш белән ерактан торып идарә итә һәм җиңә.

– Бу тирәләрдә каты бәрелешләр булган, дип сөйлиләр...

---

[2] Үтүк – борынгы төрки сүзе.
[3] Әй, алан (балкарча) – әй, якташ.
[4] Биргү – күчтәнәч.
[5] Шакмакчы – шахматчы.

Тылмач мыскыллап көлде.

– Сүбәдәйгә каршы сугышырлык халыкны белмим мин бу тирәдә. Булганы да юктыр, чөнки Каф тавы буйнакларында[6] терлек, ә тар үзәннәрдә аз санлы халыклар гына яши.

– Аланнарны әйтәм...

– Алан – аерым бер халык түгел, диләр. Белүемчә авар, ас[7], ләзгин, балкар һәм башка Каф кабиләләренең уртак атамасы ул. Төрле халык җыелдымы – анда бердәйлек юк бит – берсен-берсе сата башлый. Ә мондый очракта Сүбәдәй баһадирның борыны ай-һай сизгер! Чүл бүресе бер читтә торсын. Әнә, күрәсеңме, Сүбәдәй баһадир үз яраннары янында һәм алты канатлы тирмә күләгәсендә салкын кымыз эчә, ә ыстан читендә исә алан бәкләре тирән базда бер йотым суга тилмерә...

– Сүбәдәй баһадир нойоннары: «Без сезнең белән бер ыругдан, ни өчен үзара ызгышабыз әле?» – дип, кыпчакларны аланнардан аерган, шуңа да аланнар җиңелгән икән, дип сөйлиләр...

– Һе, Отрар вә Ургәнечтән бирле мангуллар белән сугышып чигенгән кыпчаклар мангулларны күрмәгәндер, аларның нинди ыругдан икәнлеген белмәгәндер дисеңме?! Юк, Сүбәдәй баһадир котыртып, аның сугышчылары кыргызлар әйткән сүзләр бу. Сүбәдәй баһадир өчен кыргызы ни дә, кыпчагы ни. Ул барыбер кыпчак кабиләләрен туздырып бетермичә туктамаячак. Шуңа күрә, Кыпчакның соңгы шәһәре Судакка юл тота да.

– Сүбәдәй баһадир Кырымга юл тотамы?

– Кара әле, егет, син артык күп сораулар яудырасың. Исеңдә тот, Сүбәдәй баһадир моны бер дә яратмый. Башыңны югалтуың бар. Чыңгыз каганга баш орган болгар патшасы илчесе булганга гына мин сиңа боларны сөйлим. Мондый үзара сөйләшүнең зарары юк,– дип тынычландырды ул үзен. – Кыпчаклар ничек кенә көчле булмасын, язмышлары хәл ителгән инде: Сүбәдәйгә ярдәмгә, Гыйракны[8] айкап чыкканнан соң, Чабә баһадир да килеп җитәчәк...

– Әлбәттә, һәрвакыт Сүбәдәй баһадир катында булгач, аның нойоннары белән киңәшкәнен аңлап торгач, син күпне беләсең, хәбәрдар кеше, Фирүз ага, – дип, Бибарс тылмачны олуглаган булды, ләкин Чабәнең – Сүбәдәйдән кала икенче атаклы монгол гаскәр башлыгының да – үз элмәге[9] белән Кыпчакка киләчәген ишеткәч, борчылуы артты.

Үзара шулай сүз алышып торган арада, унбашы килеп, аларны ияртеп алып китте. Вак-төяк юл тирмәләре арасыннан озак кына барганнан соң, Сүбәдәй баһадирның урта бер җирдә урнашкан һәм зурлыгы ягыннан аерылып торган алты канатлы тирмәсенә якынлаштылар. Бибарс аңа игътибар белән карап алды. Ак киездән эшләнгән тирмә өскә таба тарая бара, ә очы, мич торбасы кебек калкыбрак торган өлеше йөзем сабагы һәм төрле җәнлек сурәтләре белән бизәлгән. Ишек урынына эленгән киезгә йотардай булып киереп ачылган авызыннан ут чәчрәп торган аждаһа сурәте ясалган. Тирмә үзе исә, хәрби сәфәр тирмәсе булгангамы, артык бизәлмәгән иде.

Унбашы, кулы белән ишарәләп, юлдашларын туктатты да үзе тирмәгә керде. Көтеп торган арада тылмач Бибарска монгол урдасындагы тәртипне, кайбер гореф-гадәтләрне аңлатуны кирәк тапты:

– Үзең беренче булып сүз башлама. Сүбәдәй баһадир сораган сорауга кыска һәм төгәл җавап бир. Тирмә бусагасын атлап кер, абына күрмә – бу мангулларча бик начар ишарәт, – диде ул.

Дәвамы бар ■

---

[6] Буйнак – перевал.
[7] Ас – осетин.
[8] Гыйрак – бу чорда Иранның көньяк-көнбатыш өлкәсе.
[9] Элмә (борынгы төркичә) – зур поход (бу очракта Чыңгызхан) алдыннан юлларны, күперләрне һәм нинди халыклар яшәгәнен белеп кайтырга җибәрелгән җиңел кавалерия.

СЕЗГӘ МИННӘН АК ТЕЛӘК...

Мирхәйдәр Фәйзи

ИЛЛЕ БЕР КӨНЛЕК СӘЯХӘТЕМ ЯХУД МАЛМЫЖ СӘФӘРЕ ХАТИРӘСЕ. 1916 ЕЛ

ШОДА

Бүген кешеләрнең кибән куйган җирләренә, арыш чәчкән җирләренә барып йөрдем. Кояшны су буенда баеттым. Күпер өстендә торганда «мөфти кызы» Фатыйма: «Монда, юл өстендә, безгә матап[1] торасыз, безне күрми тора алмыйсызмы әллә? Безне күрәсегез килсә, басуга барыгыз», – дип, үзебезне элеп алып, селкеп салып китте. Телемә: «Бу абыстай ләтчә[2] кебек икән», – сүзе килеп, башка һичбер лаек сүз таба алмый калдым. Ләкин моны әрләү дип юрамыйлар, бәлки чакыру дип санадылар. Шунда да бик ачуым килде.

Килгәннән бирле муаффәкыятьләр чыгып килгән Шода тормышына бу кызның сүзләре бер тап кебек тоелды. Ул кыз хакында җиңги дә, «тәрбиясез кыз», дип сөйләгән иде. Кайтып, чәй эчкәч тә, үз өемдә шушы бәетне язып ташладым:

Шода утыра матур җирдә, борылып ага сулары;
Бер кызында адәп азрак, боза ямен шулары.
Су буйлары чирәмлек, тезелеп китәкән чыршы бар;
Күп кызларның арасында ләтчә кебек берсе бар.
Кызлар алар җир йөзенең иң кадерле гөлләре,
Шундый кызлар бар Шодада, балдай тәмле телләре.
Ак бәхетләр теләп китәм барлык Шода кызына,
Түбәндә тик аерым сүзләр ләтчә кызның үзенә.
Ләтчә кызлар өй түрендә, яңа капка, ак койма;
Телеңә кыршау сугыйм азрак, үпкәләмә, Фатыйма! [...]

4ендә урманга барабыз дип йөрсәк тә, муаффәкъ[3] булмый калдык. Төштән соң берәү белән, Фатыймага үч итеп, алардан бер генә җир бире урак уручылар янына барып йөрдек. Кич белән Фатыймалар кайтканда юри әлеге урынга төшеп тордым. Ләкин эндәшми киттеләр. Мин дә тын калдым.

Каршы түбәгә менеп, су юлының матур күренешенә хәйран булып яттым.

Кояш күздән югалды, булды ахшам,
Чыгып шунда яшел чирәмдә ятсам,
Кояшка гаксе[4] төшкән шөгъләләрне[5]
Суы алтынлы фонтанга охшатсам.

Мәҗид Гафуриның бу тасвирының кыйммәтен хәзер мин тәкъдир иттем. Мин хәзер шундый күренеш алдында. Кояшның баеп барганда суга сузылып төшкән шөгъләсен суы алтынлы фонтанга охшатмый нигә охшатырсың?

Кояшны бишегенә салгач, авыл егетләренең караргяһләре[6] булган Низаметдин бакчасының почмагына барып, «Салиха» көен

[1] Матап – чуалып, комачаулап.

[2] Ләтчә – артык үткен, елгыр.

[3] Муаффәкъ – ирешкән, ирешә алган.

[4] Гаксе – каршы.

[5] Шөгъләә – ялкын.

[6] Караргяһ – тору урыны.

Текстта авторның тел-стиль үзенчәлекләре тулысы белән саклана.

Ахыры. Башы 1 нче санда

Сәгыйть Сәедгәрәй улы имамлык иткән мәчет.
Балтач районы, Шода авылы

көйләп тордым. Георгиевский кавалер Зәйнетдинның хатыны суга төшеп менде. Пәри очы ягыннан табактай ай да чыгып күренде. Шул ук яктан җил белән килгән гармун тавышы бу ямьле күренешне тагы да серлеләндерә иде. Янә Низами абзый килде. Иртәгә Сәедгәрәй абзый белән мине кунакка чакырасын сөйләгәннән соң, урам егетләреннән зарланырга тотынды. Урамда йөриләр. Картларда да эшләре юк, муллаларда да эшләре юк. Ятсаң, йокы бирмиләр, ди. Шул вакыт бу якка таба килгән җыр тавышы ишетелде:

Утырдым көймә түренә, карадым суның төбенә;
Су төпләрендә кара юк, хак язганга чара юк...

Низами абзый әйтә: «Болар 19 нчылардыр ахры. Бу җыр шундыйлардан гына чыккалый, югыйсә «Мәчтүрә» дә «Мәрфуга» күбрәк», – ди. Шундук егетләр:

– *Ай-ли Фатыйма, тилмертмә Алла хакына!* – дип йибәрмәсеннәрме. «Әнә, әйтеп тә өлгермәдем, – дип кычкырды Низами абзый, – килделәр». 19 нчы ел призывына хәзердән үк никрутланып йөрүче Нургали вә Хәлил исемле егетләр икән. Низами абзый болар янында болар яклы вә хәерхаһ[7] кеше булды да китте. Бая миңа сөйләгәннәренең көлен күккә очырды. Бая әллә минем җәямне тартып каравы булды, әллә боларга монафикълана[8]? «Мин баядан бирле капка төбендә торам, бүген әллә ник җыелмыйлар. Фәттах малае гармун алып кайткан, диләр. Күрдегезме? Яхшымы?» – кебек сүзләрне үз тиңләре белән сөйләгән кебек сибә генә. Без өчәү «пәри» очына таба киттек. Яр башында торган Мәгъмүрәнең мәгъшукы янында туктап гармун тотсак та килмәде. Нургали сызгырып-сызгырып караса да, җавап булмады. Үзенең свиданиега чыкканын сөйләп бездән калды. Без күтәрелеп килгән айга каршы карап киттек. Нургали белән Хәлил парлап җырлап йибәрделәр:

Карар инде, карар инде кара күзләре белән;
Үзәгемне өзәр инде тәмле сүзләре белән... илх[9].

Азрак баргач туктап ачы иттереп сызгырып алалар. Монысы

[7] Хәерхаһ – теләктәш, яхшы теләктә булу.

[8] Монафикъ – ике йөзле, эчкерле кеше.

[9] Илх – һәм башкалар.

Безнең мирас №3 март 2017

якын тирәдә үзләренә кулайлы кеше булса чакырулары. Пәринең очына барып, борылып килеп Гафифәләр тыкрыгыннан Шурма аша Үре очына чыктык. Әфгаләр турыннан үткәндә Нургали, песи шикелле коймадан үрмәләп, эчкә төшеп, карап килде. «Өй алдында әтисе белән катар урын җәеп, ятарга йөри», – ди. Үре урамында Шакир мулла өе янынннан «Без урамнан үткәндә ачулана хәзрәт!» дип җырлап үттеләр. Бер көн:

Сезнең мулла ни әйтә? Безнең мулла шуны әйтә:

Аяк тибеп бер җырласаң, бәрәкалла, дип әйтә, – дип җырлап үткәннәр иде. Бу йөрешләре турысында: «Сәедгәрәй хәзрәт усалрак. Болар алай түгел. Яшь хәзрәт үзе дә чит авылларда гулять итә ул», – диләр. Аерылганда, мин иртәгә китәсемне әйтеп, исәнләштем. «Каты эш вакыты туры килде, кунак итеп булмады. Безгә килгәндә йә Сабантуйлары вакытында, йә көзрәк кил», – дип калдылар.

Өйдә мине көтеп чәй эчми торганнар иде. 5ндә без Сәедгәрәй абзый белән Малмыжга китәчәк идек. Орскига киткәндә, Казанга ат белән генә бару уе куәтле булганга, шаять, Шодага килербез әле, дигән өмид белән Шодадан киттек.

Шодада 12 көн тордыгым хәлдә, тую исемә дә кереп чыкмаган иде әле. Йөреккә Нурусал апайларга кереп, чәй эчеп чыктык. Йөрек – ике мәхәлләле зур, матур авыл. Бу авылның Гыйзәтулла җизни Хәмидуллин күкәй белән эш итмәк зур байлардан. Икенче угылы Шәфигулла Казанда, кече угылы Нәбиулла Петроградта вә өлкән угылы Сәмигулланың баласы Габдулла Архангелда торып, шул ук эшне башкаралар. Йөректә бакча эченә салган йортлары пароход төсле[10].

[10] Журналыбызның 2015 елгы июнь санында төбәкне өйрәнүче, укытучы Мөнир Әһлиевнең Иске Йөрек авылы һәм Гыйззәтулла бай турында «Йөрәк түрендәге Йөрек» исемле мәкаләсе басылып чыкты. Мәкалә, фото һәм видеорепортаж белән бирердә танышырга мөмкин: http://beznenmiras.ru/jjorek-turendege-jjorek/

МАЛМЫЖ

Малмыжга кайттык. Абыстайның урыны буш. Ифрат уңайсыз булды. Һәр җир, һәрнәрсә җылап тора. Кәшшаф абзый килеп җизнигә шактый җуаныч булып калган иде. 6 нда җизни, Кәшшаф абзый, Сәедгәрәй абзый Йөрек, Шода якларына чыгып киттеләр. Мин, әни, Мостафа бер әби өендә калдык. Малмыж элек тә күңелсез иде, хәзер тагын да күңелсез. 7 ндә хатлар, шигырьләр язу белән мәшгуль булдым. Кичрәк Хаҗи белән Шушма буенда йөреп, бакчага килдек. Анда Камил Мансуров белән йөрдем. 8 ндә Сөнгать янына барып байтак утырдым. 9 нда җизни, Кәшшаф абзый кайттылар.

10 нда Кәшшаф абзый белән зиратка бардык. Кич урысча спектакль булып, «Свадьба Бальзаминова» исемле әсәр куеладыр иде. Мин Сөнгатькә барырга вәгъдә куеп, ул билет табып куярга булып калса да, без Закир Мәннәфовка чакырулы икәнбез. Шунлыктан җизнигә карышырга туры килмәде.

11 ндә Кәшшаф абзый кайтып китте. Кич Шушма буена барып байтак йөрдем. Бер сыер суга батып үлде. 12 ндә мәсҗедкә кердем, Йөрекнең бик әшәке тавышлы мулласы имам торды. Мунча кердем. Мунчадан чыгуга бакчаның бик тәмле исләре каршы алды. Әни белән Мостафа Шушма буена төшеп, бакчага барып йөреп кайттылар. Мин зиратка барып кайттым. 13 ндә Закир Мәннәфов, Гариф Габбасовлар кибетенә кереп утырып чыктым. Ун ел элек килүебездә Хәкимовта приказчик булып торган кешеләр хәзер зур-зур кибетле бай булып өлгергәннәр. Мәннәфов кичәге сәүдәсен 2 600 сум диде. Бүген артыграк булырга кирәк дип торам, ди. Сөнгать белән Хаҗи

янына кереп байтак утырдым. Кичрәк Шушма буена барып кояшны баеттым. Берәүнең кесәсеннән түгелеп калган эрбет чикләвеге белән семечканы җыеп ашадым. Алар инде бер егет белән бер кыз булгандыр. Бәлки чикләвек кызның кулындагы капчыкта, семечки егетнең кесәсендә булгандыр. Аралары бер аршиндай гына булдыгы хәлдә аерымрак түгелеп ятуларыннан шул аңлана, вәссәлам.

14 ндә бакчада күп утырдым. Хәер, бүген генә түгел, һәркөн мин монда байтак йөрми калмыйм. Коелган алмаларны җыям, шомырт җыям, беседкага кереп җырлап утырам, агачтагы алмаларны саныйм вә илх. Җизни ягыннан йөрүне уңайсыз санаганга, чыгып йөргәндә дә бакча аша үтеп өйгә, бакчага чыккан пыяла ишектән генә кереп йөрим. Төштән соң Шушмага бардым. Сөнгать, Хаҗи өчәү урамда йөреп, бакчага бардык. Анда Камил, тагы бер ниндидер егет – бишәүләп иртәгә иртүк сәгать 2 дән торып кырга барырга карар бирдек.

15 ндә сәгать 1 ½ да торып киенеп тышка чыксам, күк йөзен кара болыт каплап алган, җир йөзе тездән баткак ки, ак явым рәхәтләнеп хөкем сөрә. Ходайга үпкәләп кердем дә яттым. Шуннан башка чара юк иде. Явым көн буе дәвам итте. Җизни: «Җиләк күп җыйдыгызмы? Балык күп тоттыгызмы?» – дип үрти. «Кырчылар кайтыр, самавар куеп торырга кирәк, җиләк белән чәй эчәрбез», – ди. [...]

***

Хуш, Малмыж! Хуш, сөекле абыстабызның карарганhе! Без сездән кайгылы күңел белән аерылып китәбез. Хуш, абыстайның торган өйләре! Сине абыстаң мәңгегә ташлап киткән иде, инде без дә, Ходa белсен ничектер, синнән аерылабыз. Сездә безнең абыстабыз күп еллар гомер сөрде. Шул сәбәптән безгә дә бик якын идегез. Хушыгыз! Абыстай! Безне куанып каршы алган идең, киткәнебездә син күренмисең. Шулай ук кайтмас җиргә киттеңмени? Димәк, кабереңә барып, бер өем туфракка карап: «Хуш инде, без китәбез», – дип, җылап китүдән башка чарабыз юк икән. Үзеңнән мәңгегә аерылу өстенә, кабереңне, йөргән җирләреңне күрә алудан да җөда булдык[11]. Хуш! Рәхәт ят!.. Менә капкадан да чыктык. Әнә бер көтү хатын-кыз яшьле күз белән озатып калдылар. Бу минутта дөньяда җыламаган нәрсә юктыр... Урамнар, бар да таныш, бар да абыстайның йөргән юллары... калдылар. Телгәләнгән йөрәгем белән сезгә соң мәртәбә: «Хуш!» – дим. [...]

Без төшкәндә пароход килгән иде. Көтеп утырып калдык. Бу пристаньга җыелучылардан: әни, мин, Кәрәмәт, Ләтыйфа, Нәкыйб, Нурлыгаян, Рәхимә – китүчеләр; җизни, Сәедгәрәй абзый, җиңги, Сәгыйд – озатучылар иде. Җизни лимонадлар алып элек хатыннар бүлмәсенә, аннан безгә килеп эчереп йөрде. Бу вазыйфаны үтәгәндә эчкечеләр формасын тәмам җиренә китереп эшләп халыкны көлдерде. Түбәнтен пароход килсә дә, югарытын килми. Бик көттерде. Урын тапканнар кайсы ятып йоклаштыргаладылар. Мин теге пароходка кереп карап торганда, бик ерактан, утка чолганып килгән пароходны мөшаһәдә иттем. Ниһаять, төнге сәгать 1½ да килеп тә йитте. Без второй класска, Кәрамәтләр первыйга урынлаштык. Пароход бер сәгатьтәй торды. Икенче кычкыртудан соң озатучылар күрешеп чыктылар. Шундук өченчене биреп

[11] Җөда булдык – мәхрүм калдык.

пароход кузгалды да. Калганнар пристаньнең югарысына чыгып, без пароходның очына җыелып, яулыклар селкеп аерыштык. Бик мөтәәссир булып, пристань вә теге пароходтагы утлар тәмам күздән югалганчы карап бардым.

Элек Коръән укыдым. Аннан төрле аерылу җырлары җырлап барганнан су борылып, Малмыж пристане әллә мәңгегә, яхуд күпмегәдер аерылды. Актык «Хуш!»ымны әйтеп пароходның икенче ягына чыкканда, бик матур сызылып таң атып килә иде. Гүя мине җуатыр өчен Тәңредән йибәрелгән кебек... Чулпан йолдызы җылмаеп каршы алды. Аның матурлыгы, мәһабәте алдында сәҗдә итәсем килде. Тәмама бирелеп «Нужда» көенә:

Таң, таң ата, Чулпан калка, таң Чулпанны җугалта;

Сызылып таңлар аткан чакта җырлата да җылата... – дип җырлап йибәрдем.

Чынлап та, Чулпан калыкты, таң атып аны җугалтты. Күңелләр илаһи бер дәрт белән ашкынды. Җырладым һәм җыладым.

Мин иртә белән чыкканда пароход Малмыждан соң беренче пристань булган «Вятский Полян»га туктап тора иде. Гөлнар ханым Лебедева имениесе янындагы «Любань» пристанендә тирәкләр арасына чыгып йөрдем. Кәрамәтләр, Нәкыйбләр белән бару бик-бик күңелле иде. Әнине кодача каютларына чәйгә чакырды. Аннан ирләр второй класс салунына җыелып чәй эчтек. Истән чыкмастай күңелле хатирәләр калдырды. [...]

КАЗАН

Казанга 21 ндә көндез сәгать 1½ да барып йиттек. Малмыждан чыккан карар буенча, Гайшә абыстайга кереп чыгуга булсак та, көн явым булу, вә әнинең авыруына атта 7-8 чакрым бару уңайсыз буласын уйлап, карарны кырдык. Без барганда көндезге пароходлар китеп беткәнгә, сәгать 6 да кич китәчәк «Коммерческий» пароходын көтеп пристанена урнаштык. Ләкин сәгать 5 ләрдә аның юлда бозылып калганлыктан хәбәр килеп, кырылган карарны җамарга туры килде. Кич 9 да китәчәк «Самолет»ны соңсынып, тәвәкәлләп Казанга бармак булдык. Вә нәрсәләрне бер номерга сакларга биреп, 3 сумга извозчик яллап Әхмәд бай мәрхүм Хөсәенев йортына бардык. Бик куанып вә хуплап каршы алдылар. Ирләрдән өйдә Гайшә абыстайның энеләреннән Мәхмүд кенә иде. Тагы Мәхмүднең иптәшләреннән «Тайфун» мөтәрҗиме учитель Искәндәр Сакаев та аларда кунак иде. Безнең иртәгә китмәвебезне катгый үтенгәнгә, китмәскә булдык. Кай җирләре ике, кай җирләре өч атажлы зур таш йортның эче соң ысул белән бизәлгән вә җиһазланган ки, безнең кебекләрне генә таң калдырырга йитәрлек. Үземә хасланган бүлмәдә май кебек эреп йокладым. Гайшә абыстай миңа күренмәде. Иртә чәйне зур залда эчтек. Сигез тәрәзәле, биек бу залның күренеше тагы да шәбрәк. Бу залда сигез көзге булып, берсе стенаның өчтән берен ишгаль итеп, фәүкыльгадә матур вә гаҗәп ки, Азияда таулар арасында яткан бер кыр баласының ничек исе китмәсен.

Чәйдән соң ук Печән базары вә Проломныйга барып йөрдем. «Кәримевләр», «Сабах», «Мәгариф», «Гасыр», «Юл» көтебханәләренә кердем. Шиһап Әхмәров, Гыйлман Гобәйдулиннарны күрдем. Күрермен дип уйлаганым: Шәрәфетдин Шәһидуллин, Насыйр Ис-

хаков, Нәбиулла Хәмидуллиннарны вакыт тар булганлыктан, Габдулла Кариевны өйдә булмаганлыктан күреп булмады. Проломныйда бер парикмахерны тәшриф итеп чыктым. Иртәгесен 23 ндә Гайшә абыстайның күп рәхмәтләрен алып, аның һәйбәт ат арбаларына утырып пароходка киттек. Бердә китәчәк «Самолет»ны запас тотып «Кавказ Меркурий»га төштек. Второйга [класска] урын булмаганга, 5-6 сум аермага карамастан, беренче класска 22 сумга билет алып, ике урынлы 15 нче каютага әнине урнаштырдым вә шул ук ат белән номерга барып, 1 сум түләп нәрсәләрне алып килдем. Безнең бәхеткә 1914 нче ел гына салынган гаять дәрәҗәдә шәп «Царь Михаил» исемле теплоход туры килгән иде. Әйтүләргә күрә, «цапля» дигән шәп очучы бер кошка нисбәт белән теплоход аталган бу зур көймә, парсыз фәкать «Дизель» дигән кешенең иҗат иттеге бер куәт белән йөри. Тәгәрмәчләре дә юк. Тик арттан гына суны җырып бара. Тавышы да аз. Пароход кебек суга ятмый, өстән генә барганлыктан, очкан кебек шәп йөри. Каюталар двухсветный, зур, биек; палубасы киң; парикмахер, ванна-фәләннәр бар да йитеш вә чиксез зиннәтләр ки, тәгърифиннән[12] тел гаҗиз. Бигрәк тә салуннары искиткеч дәрәҗәдә зиннәтле. Первый класс салунының алгы стенасы тоташ пыяла гына.

Көндез сәгать 11 дә Казаннан кузгалып киттек. Әни белән бик озак Казанны тамаша итеп бардык та, каюткага кереп бик тәмнеләп чәй эчтек. Сәгать 4 ләрдә Богородскийдан үтеп, 7 ләрдә Тәтешкә йиттек. Монда Мәхбүбигә дигән хатымны салып калдырдым. Мондагы 5-6 солдаттан гармунда «Вафа» көен уйнап торган берсен бер белгән кешемә охшатып белми интектем. Иптәшләренең «Әмирхан» дип эндәшүләрен ишеткәч, Орскидагы «Әптри баласы гармунчы Әмирхан» дип мәшһүр бер егет икәнлегендә шигем калмаса да, пароход кузгалып киткәндә генә: «Сез кай якныкы?» – дип соравыма: «Уральски», – дип ап-ачык җавабы, чамамның яңлышлыгын белдерде. Ләкин исеме, кыяфәте, төсе, гармун уйнаулары шулкадәр Орски Әмирханына охшавына бик гаҗәпләндем. Әллә ул шәһәр исемен яңлыш әйттеме? Ләкин Уральски кадәресен бик ачык, анык ишеттем. [...]

***

Малмыж ягының бер караш үзән калмый тырналып беткән җирләрендә тыным тарыгып беткән иде. Үз ягыбызга чыгып, киң җәелеп яткан даланы күреп рәхәтләнеп бер сулыш алдым. Үзебезнең якның чын тауларын күреп чиксез куандым. Ямьле вә моңлы Сакмар буе белән Орскига карап тәгәрибез. Поезд бик шәп йөрми, станциаларда озак тора. [...]

Иртәгесен 27 ндә [...], кич сәгать 8 дә Орскига исән-сау кайтып йиттек. Бу тирәдә һәм бар да саулар икән. Йә Алла! Мең шөкерләр булсын сиңа, сәламәтлектә кайтарып күрештердең. Моннан соң да барча безгә тигез гомерләр, саулык, бәхет, ак тормышлар бир!

Әни өч ай да егерме ике көн дигәндә, мин бер ай да егерме бер көн дигәндә өйгә кайтып кердек. Әлхәмделиллаһ.

Тәмам.

Текстны басмага Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге баш библиографы ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

[12] Тәгъриф – белдерү, аңлату.

Безнең мирас №3 март 2017

ИСЛАМ ГАЛӘМЕНЕҢ КАЗЫК ЙОЛДЫЗЫ

Хөсәен Вәлиәхмәтов



Ирле-хатынлы Бигиевләр: Әсма белән Муса. Чистай, 1905 ел

Һинджаздан Муса Бигиев Һиндстанга китә, Деабенд дигән төбәктә (Уттар-Прадеш) штатындагы Сахаранпур шәһәре янында) ярты ел чамасы яши, биредәге ислам дине белгечләре белән аралаша, санскрит күчермәсе белән, Махабхарата нигезләрен өйрәнә. Бу галимгә ислам дине белән башка диннәр арасындагы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр тарихын тагын да тирәнрәк үзләштерергә ярдәм итә. Һинд (урда, пуштун) теле белән фарсы телләре арасында уртаклыклар зур. Шуңа күрә Муса Һиндстанда бик күп мәгълүматлар туплап, янәдән Мисырга кайта, Милли китапханәдә фәнни эзләнүләрен дәвам иттерә.

Тынгысыз галимгә һаман дә нәрсәдер җитми кебек тоела. Якындагы башка шәрык илләрен дә күрәсе килә аның. Ул Бәйрутка чыгып китә, андагы мөселман уку йортларында белем бирү тәртибе белән таныша. Инде Сүриягә барырга ниятли. Максатчан, үҗәт холыклы Муса, транспортка утырып барырлык юл акчасы да булмагач, бу ике араны җәяүләп үтә. Чүлләр-сахралар аркылы ерак юллар кичеп, күп илләрдә уку-укыту тәртибен өйрәнеп, галимнәр белән дуслашып, 30 яшен тутырып килгәндә Муса Бигиев Россиягә әйләнеп кайта.

Туган җире Ростов-Донда аңа иң зур мәхәлләләрнең берсен җитәкләргә һәм тирә-якка билгеле мәдрәсәдә укытырга тәкъдим итәләр. Муса моңа риза булмый һәм Петербургка китеп, университетның юридик факультетына иректе тыңлаучы булып йөри (Габделбари Баттал-Таймас китабында язылганча). Ләкин Оренбургта 1897 елда чыккан «Яңа вакыт» журналында Муса табигать фәннәре һәм фәлсәфә факультетына кергән дигән

Дәвамы. Башы журналның быелгы 2 нче санында.

хәбәр дә бар («Хөсәения» мәдрәсәсе турында М.Ф.Рәхимкулова мәкаләсе).

Әмма монысы әллә ни мөһим дә түгелдер. Муса Бигиевнең Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләрендә дөньяви фәннәр – аеруча математика һәм астрономия белән дә кызыксынуы турында әйтеп үткән идек. Михаил Ломоносов кебек, фәннең төрле тармаклары белән кызыксынганлыгына тагын бер кат ишарә бу. 1910 елның җәендә Муса Төньяк поляр түгәрәгенә якын булган Финляндиягә поляр көннәрне күзәтү өчен экспедициягә бара. Шул сәяхәттән кайткач басылып чыккан «Озын көннәрдә ураза» китабы ислам дөньясына зур ачыш китерә. Тагын ике елдан соң басылып чыккан «Ни өчен шәригать ел исәбен айдан башларга тәкъдим итә?» китабы да әһәмиятле вакыйгага буларак кабул ителә. Шул елларда академик В.Бартольд редакциясендә рус телендә нәшер ителүче «Мир Ислама» журналы да Бигиев әсәрләренең талантлы каләмнән төшүен, аларның аңлаешлы, нәфис телдә, гарәп-фарсы алынмаларын аз кулланып язылган булуын билгеләп үтә. Шулай ук Муса Бигиевнең Россия астрономия җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлануы да мәгълүм.

1905 елда Петербургка кайткач, ул иҗат эшенә чума. Шул чорның танылган публицисты, журналист һәм нәшир Габдерәшит Ибраһимов (1857-1944) белән таныша. Аның ярдәме белән «Өлфәт» дигән газета чыгара башлый (газетаның 1907 елга кадәр чыгып килүе мәгълүм, аннан соң ябыла). Бигиевнең үз типографиясен ачуы, гарәп хәрефләрен булдырып, үз китапларын үзе бастыруы да билгеле. Мөселман дөньясының иң зур уку йортларында гыйлем туплап кайткан Муса Җаруллаһ (ул үзе шулай атап йөрткәнне яраткан) әфәнденең, әлбәттә, халыкка әйтер сүзе дә күп җыйналгандыр. Аурупа мөселманнарына, татар халкына чын ислам мәгърифәтен алып кайта ул. Хәтта йөзләрчә, меңнәрчә еллык тарихы булган атаклы университет һәм мәдрәсәләрдәге укыту тәртибенә дә тәнкыйть күзлегеннән карап, җәдитчә укытуга күчәргә өнди. «Без хәзер күпчелек мәдрәсәләрдә мулла-имамнар түгел, ә кяферләр әзерләп-үстереп чыгарабыз», – дигән каты фикерләр дә әйтә үз хезмәтләрендә. Әлбәттә, олы дин әһелләре, мәдрәсә җитәкчеләре үз дәрәҗәләрен кимсетә торган мондый фикерләр белән килешми, нәтиҗәдә, Мусага карата һөҗүмнәр көчәя башлый.

Петербургта чагында Бигиев сәясәттә дә актив катнаша, беренче Бөтенроссия мөселманнары съездларын оештыру һәм үткәрүдә башлап йөри, 1906 елда «Русия мөселманнары иттифакының программы» (Петербург) һәм Казанда «Русия мөселманнарының өченче нәдвәсе» һ.б. исемнәрдә документлар тупланмасын бастырып чыгара. Дини-фәлсәфи хезмәтләрен язарга да өлгерә, шәрык илләрендә укып йөргәндә үк кызыксынып, яратып өйрәнгән борынгы акыл ияләре һәм ислам белгечләре Әл-Гәзери (753-833) белән Әл-Шатиби хезмәтләрен тәрҗемә итә һәм аларга шәрехләр яза, матур әдәбият белән дә мавыгып, бөек шәрык шагыйрьләре Әбү Әл-Мәгарри (973-1058) һәм Хафиз Ширази әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп бастырып чыгара. Ләкин Муса Бигиев хезмәтләренең иң зурысы дип белгечләр «Тарих Әл-Куръән вә Әл-Мәсахиф» (История Корана и Свитков) китабын саный. Аны хәтта 1907 елда Мисырда чыга торган «Әл-Манар» журналы да күчереп бастыра. Журналның редакторы Муса укып йөргән Әл-Әзһәр университеты профессоры Мөхәммәт Абдо була һәм китапны гарәпчәгә Бигиев үзе тәрҗемә итә. Коръән тарихы белән ул Әл-Әзһәрдә укып йөргәндә үк ныклап кызыксына. Соңрак хәтта Изге Китапка алты томлык шәрехләмә дә яза.

Шул елларда Рәсәйдә чыгып килгән иң популяр газета һәм журналлардан саналучы «Вакыт» (Оренбургта 1917 елга кадәр Мусаның дусты, фикердәше Фатих Кәрими мөхәррирлек итә),

«Әлгасрелҗәдит», «Тилмиз» (гарәпчә – шәкерт, укучы дигән сүз, Петербургта Габдерәшит Ибраһимов белән бергә мәдрәсәдә укучылар өчен махсус атналык кушымта-газета чыгаралар), «Шура» (Ризаэтдин Фәхреддин), «Мир Ислама» (1912-1913 елларда академик В.В.Бартольд мөхәррирлегендә чыга), «Ил» (Гаяз Исхакый) һәм башка бик күп басмалар белән актив языша Муса. Чит илләрдә, башка телләрдә чыгып килгән басмалар да үзләрендә Бигиев хезмәтләре күренүне зур мәртәбә саный.

1908 елда Муса Җаруллаһ Казанга килә, «Әл-Ислах» газетасы редакциясе урнашкан йортның икенче катыннан бер бүлмә ала, «Шәрык» китапханәсе нәшрияты хуҗасы Әхмәт Исхаки белән таныша. Бу дуслыкның нәтиҗәсе буларак, Муса Бигиевнең исемен бөтен дөньяга танытырлык олы хезмәтләре басылып чыга. Алар арасында Ислам мәзһәпләренә нигез салучы имам Мәлик хәдисләре буенча язылган «Әл-Мүватта» (Әл-Бохари белән Әл-Мөслими хәдисләренә кадәр аның җыентыгы, Коръәннән кала, икенче урында торган шәригать чыганагы булып саналган), «Әл-Мүафәкать мөкаддимәсе» (Әбү Исхак Әл-Шатибинең (һиҗри белән 790 ел) Әбү-Хәниф вә Әбү-Мәлик мәзһәпләре арасындагы хокук таләпләрен килештерү мәсьәләләренә багышланган хезмәте), «Тәсхих Хатт Рәсм Әл-Коръән» («Коръәнне бастырганда җибәрелгән нәшрият хаталарын төзәтү») кебек бүгенгәчә ислам җәүһәрләре булып саналырлык китаплар бар. «Шура» журналы да, башка матбугат чаралары да Мусаның ул хезмәтләрен шатланып каршы ала, аның турында алдынгы карашлы дин белгечләре, галимнәр мактап яза.

1909 елда Бигиевне Оренбургка чакыралар. Ул «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкертләренә диннәр тарихы, гарәп теле һәм әдәбияты тарихы, фикх (хокук белеме) һәм психология (рухият) буенча лекцияләр укый. Аны мөгаллим һәм мәдрәсә ректоры ярдәмчесе итеп билгелиләр. Фатих Кәрими, Шиһаб Мәрҗани, Гаяз Исхакый, Риза Фәхреддин кебек мөхтәрәм шәхесләребезнең күбесе Муса Бигиевнең искиткеч укымышлы, бөек галим икәнлеген таный, аны милли бәйсезлек хәрәкәтенең алгы сафында баручы көчле сәясәтче, ислам тәгълиматларының хаклыгы, сафлыгы, кагылгысызлыгы өчен көрәшүче, Коръәнне татарчага һәм төрекчәгә тәрҗемә итәргә алынган (мондый хокук ислам дөньясы тарихында санаулы кешеләргә генә бирелгән, һәм сүрәләрне, хәдисләрне тәрҗемә итү, шәрехләү хокукы булганнар исемлегендә Муса Җаруллаһ Бигиев тә бар) югары дәрәҗәле дин белгече буларак та белә.

Әмма галимне дошман күрүчеләр дә шактый була. Шул елларда чыгып килгән «Дин вә мәгыйшәт», «Бәянелхак» журналлары, мәсәлән, Муса Биги әсәрләрен тәнкыйтьләгән 40 лап язма бастыралар (1910). Бигрәк тә «Рәхмәте Илаһия гомуми» («Аллаһның рәхмәте барлык кешегә дә») дигән хезмәтне тетәләр. Г.Тукай, бу шау-шудан көлеп, «Зур бәшарат» дигән эпиграмма бастыра («Ялт-йолт»). Бигиев карашлары белән хәтта Исмәгыйль Гаспралы («Тәрҗеман») да килешми, Коръәнне тәрҗемә итәргә ярамый, дигән фикер белдерә. «Хөсәения» мәдрәсәсенең кайгыртучылары да галимгә җәдитчелекнең нигезен тәшкил иткән исләхать (реформа) темасын күтәрмәскә кушалар. Муса укыту эшеннән китәргә мәҗбүр була.

Коръән сүрәләре вә аятьләренең төрле телләргә дөрес тәрҗемә ителмәве аркасында, Китап сүзенә күпме хилафлык килүенә җаны әрни галимнең. Кызганыч ки, бу каршылык һәм караңгылык мөселман руханилары арасында йөз елгача яшәп килә. Үз заманында Фәхреддин казый да, Мәрҗани хәзрәтләре дә Коръән сүзен дөрес шәрехләмәүнең ислам дөньясына зур зыян китерәчәге турында кисәтеп килгәннәр. Ләкин үзен реформатор итеп күрсәтергә теләүчеләр исләхатьнең чын

Әсма ханым балалары белән. Сулдан уңга: Мөхәммәд, Әхмәд, Һинд, Мәрьям, Зәйнәб. Чистай, 1912 ел

асылын аңлап бетерми. Күбесе реформаторлык белән реформацияне бутый. Әмма «Ислам исләхате – ул реформация түгел, – дип яза Муса Җаруллаһ «Шура» (1912), «Вакыт» (1909) кебек журналларда чыккан мәкаләләрендә. – Без XIV-XVI гасырларда ук Ауропада үткәрелгән христиан реформациясенә ияренгә тиеш түгел, безнең дин әһелләребез арасында Җүнәйд, Мәгъруф, Мансур, Бистәми ибен-Гарәби, Шәмси Тибризи, Җәләлетдин Руми, Хафиз Ширази, Җәми кебек ислам суфилары һәм борынгы акыл ияләренең тирән фәлсәфәсен аңлап бетермәү сизелә... Хәзер ислам дөньясы бары тик Исламга гына таяна ала... Изге Коръән вә шәригать белән ныгытылган Ислам бернинди Тәүрат яки «Капитал»ларга да, фиркә яки программаларга да мохтаҗ түгел һәм булмаячак та» («Ислам милләтләренә...», Берлин, 1923), – ди Муса Биги, ачынып.

Муса Биги янәдән Петербургка кайткач та дәртләнеп иҗат итә. Рус («Мир ислама»), татар («Шура», «Вакыт», «Ил» һ.б.), төрек («Төрек йорты») телләрендә чыккан журналларда бик күп фәнни, дини-фәлсәфи мәкаләләре басыла. 1917 елга кадәр һәр ел саен 1-2 фундаменталь хезмәтен китап итеп бастырып чыгарырга да өлгерә. Алар арасында «Рәхмәт, Илаһия борһаннары» (1911), «Халык назарына берничә мәсьәлә» (1912), «Озын көннәрдә Руза» (1913), «Мөләхаза» (Уйланулар, 1914), «Исләхать әсаслары» (Реформа нигезләре, 1915), «Зәкят», «Шәригать әсаслары» (1916) кебек хезмәтләр дә бар. Шул ук елны ул Рәсәй законнары тупланмасын татар теленә тәрҗемә итә («Хокук эсаси»). Бу хезмәте һәм 1917 елда чыгарган «Фикх Әл-Коръән» дигән ике томлыгы өчен Муса Бигиевкә хәрби ахун дәрәҗәсе бирелә.

Муса Бигиев бөтен тырышлыгын, белемен һәм сәләтен фәнгә, иҗатка багышлый. Аның үз эшенә шулкадәр бирелгәнлеге, түземлеге, чыдамлыгы хәтта Тукайны да шаккаттыра. 1912 елда ул, Бигиев чакыруы буенча, Петербургта була. Кәбир Бәкернең (1885-1944) Оренбургта 1914 елда чыккан «Тукай Петербургта» исемле китабында хәбәр ителгәнчә, шагыйрь бирегә шул елның 20



М.Бигиевнең шәхси әйберләре

апрель тирәләрендә килә һәм Бигиевләр фатирында туктала. Петербург зыялылары Тукайны яңа ачыла торган «Хәбәр» газетасына мөхәррир итеп билгеләргә уйлый. Көн саен диярлек, Тукайны күрергә теләп, мөхтәрәм татарлар, Бигиевнең шәкертләре, аның хатыны Әсма ханым янына курсистка кызлар килә. Каты авыру хәлендәге Тукайны мондый очрашулар алҗыта-ялыктыра һәм ул кунакханәгә күчеп яшәргә мәҗбүр була. Соңыннан Тукай Муса Бигиевнең эшкә җаны-тәне белән бирелгәнлегенә исе китеп: «Ул хәтта төшке ашны да эш кәгазьләренә күмелгән өстәл артыннан тормый гына ашый иде...», – дип искә ала.

Әмма дини реформаторлык процессы Көнбатыш Ауропа үрнәгендә (XVI-XVII), христиан дине кысаларында барырга тиеш, дип санаучылар Муса Бигине аңларга теләми. Ә Муса Җаруллаһ әфәнде Ислам дөньясы яңарышка (XIX-XX) үз юлы, үз фикхы, үз фәлсәфәсе белән генә бара, «ул бернинди дә Рим, яһүд хокукы кануннарына һәм һәртөрле «китап»ларга иярергә тиеш түгел, ислам мәзһәпләре – хокуклар системасы тарихында уникаль күренеш, исламның бөек могҗизасы», дигән фикерне алга сөрә һәм гомере буена шуның өчен көрәшә.

Дәвамы бар

Редакциядән: *«Безнең мирас» журналында Хәмзә Бәдретдиновның Муса Бигиевкә кагылышлы «Милләтне кайгыртучы килен» (№7, 2014 ел) һәм Альмира Таһирҗанованың «Хөрмәткә лаек исем» дигән мәкаләләре чыкккан иде. Альмира Таһирҗанова билгеләп үткәнчә: «Мәгълүм ки, Муса Бигеев төрки әдәби телдә язган һәм тәхәллүсен «Муса Җаруллаһ» дип куя торган булган. Пенза татарларындагы гадәт буенча, аның фамилиясе Биги булып йөри... Архивлар белән эш итүче тарихчылар беләдер, Муса әфәнде үз фамилиясен фәкать Бигеев дип кенә язган. Рус телендәге газета һәм журналларда исә төрлесендә-төрлечә: «Бигеев тә бар, Бикеев тә, Бигиев тә...».*

Муса Бигиевнең туган елы һәм урыны төрле чыганакларда төрлечә күрсәтелә. Бу уңайдан биредә Альмира Таһирҗанованың «Хөрмәткә лаек исем» дигән мәкаләсеннән тагын бер өземтә китерү урынлы булыр: «Муса Ярулла улы Бигеев 1873 елның 25 декабрендә (иске стиль белән) Пенза губернасының Чембар өязе Мочали волостеның Кикин авылында (хәзер – Пенза өлкәсенең Каменский районы) дөньяга килә».

Альмира Таһирҗанованың 2009 елда «Книга о Мусе-эфенди, его времени и современниках» дигән китабы дөнья күрде. Тексттагы фотолар әлеге китаптан алынды. ■

Безнең мирас №3 март 2017

ГАУРӘТ САКЛАУ

(XIX гасыр-XX йөз башы татар җәмгыятендә хиҗаб мәсьәләсе)

Динә Гатина-Шәфыйкова, Илдар Шәфыйков

Татар хатын-кызы һәм аның тышкы кыяфәте, кием-салымы турындагы бәхәснең әлегә кадәр тынганы юк. Журнал укучылары өчен дә бу мәсьәлә шулай ук актуаль, дип уйлыйм, чөнки кием, аеруча хиҗаб мәсьәләсендә капма-каршы фикерләр бар. Күп кешене, элек татар хатын-кызлары җәмәгать урыннарында яулыктан йөргәнме яки аны кирәк түгел, дип санаганнармы, дигән сорау кызыксындыра. Яулык бәйләп йөрү борынгыдан килгән тарихи күренешме, әллә читтән кергән яңа гадәтме? Һичшиксез, соңгы көннәрдә булган вакыйгалар, аеруча Мордовия Республикасының Ромодан районы Азюрка (Белозерье) авылы мәктәбендә килеп туган вазгыять ялкынга утын өстәп кенә җибәрде.

«Ислам» энциклопедик сүзлеге хиҗабка түбәндәгечә аңлатма бирә – урамга чыкканда хатын-кызның йөз-кыяфәтен һәм буй-сынын каплый торган пәрәнҗә, япма, бөркәнчек. Аның төрләре: бөтен буй-сынны яки йөзне дә каплар өчен масус челтәрле, яисә күз өчен ачык урыны булган кара, кайчак башка төстәге бөркәнчек; башны каплар өчен ярым үтә күренмәле кара япма һ.б. Хәзерге заман ислам илләрендә хиҗабның гади төре – яулык һәм кул белән муенны каплый торган күлмәк киң таралган[1].

Бу аңлатма хиҗабның беренче чиратта гаурәтне, ягъни тәннең чит-ят күздән капланырга тиешле өлешен саклар өчен, ә аннары гына кием буларак кирәклеге турында сөйли. Хатын-кыз тәненең һәр җире диярлек гаурәт, бары йөзе, беләзекләренә кадәр куллар һәм тубыкларына кадәр аяк башлары гына гаурәт саналмый, ягъни гаиләдән читтә һәр гүзәл затка капланып, гаурәт яшереп йөрү мәҗбүри. Ризаэддин Фәхреддин хатын-кызларга мәчеткә кергәндә тулысынча бөркәнергә, хәтта йөзне һәм кулларны да чит күздән яшерергә кушкан. Галим: *«Болай булмаганда, ирләр тарафыннан кирәк мәнгы (тыелган) булсын вә кирәк булмасын хатыннарның мәсҗедләргә йөрүләрендә мәгънә юк, бәлкә өендә укулары яхшы»*, – дип язып калдырган[2]. Булачак мөфти җомга һәм гает намазларына килүче мөэминнәрнең ихласлыгы юкка чыгудан курыккан, югыйсә гыйбадәтханәгә бизәнеп, киенеп-ясанып килгән гүзәл затлар ир-атларга дога кылырга комачаулаячак. Икенче яктан, Ризаэддин хәзрәт кием-салымның стиль һәм форма ягыннан үзгәрүе тарафдары булган, «мөселманча кием» дигән төшенчәнең мәгънәсезлеген ассызыклаган.

«Әд-дин вә әл-әдәб» журналының бер санында Галимҗан Баруди хатын-кызларның хиҗаб киюе һәм җәмгыятьтә үз-үзләрен тотышлары турында 10 кагыйдә бастыра. Игътибарыгызга шуның бишесен генә тәкъдим итәбез, калганын beznenmiras.ru сайтыннан укырга мөмкин.

[1] Ислам: Энциклопедический словарь. – М.: Наука. Главная редакция восточной литературы, 1991. – С.278.
[2] Фәхреддин Р. «Җәвамигуль-кәлим» шәрхе. – Казан: Татар. кит. нәшрияты, 1996. – Б.344.

Ялт-йолт. - 1910. - №3. - Б.4

1) Бәләгатькә ирешкән хатын вә кызның йөзеннән вә кулыннан (вә аягыннан) башка әгъзасы ачылмагы вә намәхрәм *(ерак кардәш яки бөтенләй туган түгел.* – Авт. иск.*)* булган ир затына күрелмәге дөрес түгел;

2) Ирләр алдында (әдәпсезләрнең) күңелләрене бозардай вә нәфесләрене кузгатырдай (фетнә чыгарырдай) рәвештә купшыланып вә кыланчыкланып сөйләшүләре дөрес түгел;

3) Каплауда зарурәт булмаганда йөзләре ачык булу фи нәфсә хәрәм түгел, вә ләкин ирләрнең яманлыгыннан вә күзләре бозылдыгыннан сөннәт вә хикмәт ихтият *(сак.* – Авт. иск.*)* юлны күрсәтмеш вә каплануның әслах *(уңайлы.* – Авт. иск.*)* икәнен белдермештер «...»;

4) Фетнә ихтималы куәтле, күз бозыклыгы анык булганда йөзне каплау важибтыр, ачу дөрес түгелдер. Хосуса, никахлы хатын, никахы сәбәпле үзене зәүҗенә тәхсыйс *(хәләленә багышлану.* – Авт. иск.*)* иткәннән соң, күркәм йөзе берлә әҗнәби *(чит.* – Авт. иск.*)* күзне ләззәтләндермәге, тәмле сүзе берлә әҗнәби күңелне хушландырмагы зәүҗенә *(иренә, хәләленә.* – Авт. иск.*)* хыянәт вә никахына бер нәүг *(төр.* – Авт. иск.*)* җинаятьтер;

5) Нәмәхрәм ир берлә аулакта булмагы, күренү вә катышу, вә сөйләшү булмаса да, дөрес түгелдер «...»[3].

Шулай итеп, мөселман зыялылары хатын-кызның тышкы кыяфәте мәсьәләсендә үтә дә таләпчән булган, кайбер очракта йөз һәм кулларны капларга кушкан, ә инде чәч һәм буй-сынны чит күздән яшерү мәҗбүри саналган.

Дөрес, имамнарның язганы тормыш чынбарлыгын чагылдырмаска да мөмкин. Шул чордагы татар хатын-кызының тышкы кыяфәте визуаль (рәсем һәм фото) һәм язма чыганакларда тасвирланган.

1885 елда басылып чыккан юлкүрсәткечтә Казан шәһәрендә булган автор үз күзе белән күргәнне яза: «Күмәк күңел ачу вакытында татар хатын-кызы йөз һәм күкрәген ныклап каплаган икән, аның белән кызыксынырга да кирәкми – ул бер карчык яки шактый ямьсез хатын»[4].

Танылган миссионер П.В.Знаменский 1910 елда басылган «Казан татарлары» исемле этнографик хезмәтендә: «*Кулмәк өстеннән татар кызлары җилән яки еш кына озын җиңле халат кияләр, шуның белән башны, йөзне пәрәнҗә урынына каплаганнар*», – дип яза[5]. Шунысы кызык, автор киенүнең кайбер җирле ысулларын пәрәнҗә белән чагыштыра. Һичшиксез, бу юлларда сүз буй-сынның тулысынча капланган булуы турында бара.

1908 елда «Әл-ислах» газетасында Бәдриҗиһан Мәүлетованың хаты басыла. Хатта шул чор хатын-кызының тышкы кыяфәте ачынып тасвирлана. Мисал өчен автор: *«Ат шикелле арты-*

[3] Бабән-ниса // Әд-дин вә әл-әдәб. – 1908. – №5. – Б.136-137.
[4] Иллюстрированный спутник по Волге / Сост. Монастырский Л.С. – Казань: Типо-литография Ключникова, 1884. – С. 176.
[5] Знаменский П.В. Казанские татары. – Казань: Изд-во «Иман», 2004. – С.11.

«Казан мәдрәсәләренең берсендә шәкертләрнең өйләдән соң шөгыльләре»

Ялт-Йолт. - 1910. - №5. - Б.8

мыздан әллә нинди карчыклар да әллә нинди балалар ияртеб генә йөртәләр дә...», – дип зарлана. Аңлашыла ки, шул чордагы әхлак нормалары кыз һәм хатыннарга (аеруча бай гаиләдән булганнарга) үзләренә генә иректе рәвештә урамга чыгарга рөхсәт итмәгән, аларны кемдер озатып йөрергә тиеш булган. Әдәп өчен тышкы кыяфәт тә мөһим. Бу турыда Бәдриҗиһан: *«Ник безне чүмәлә шикелле, әллә нинди җүләр сартлар киеб йөри торган, бик ямсез, лаштырдык чапанлар белән каплаб йөртәләр?»* – дип яза[6]. Хаттан аңлашылганча, автор әлеге гадәткә каршы үзенең моң-зарын, ризасызлыгын белдерә.

1909 елда Чистайда булган бер вакыйга әһәмиятле: сәүдәгәр һәм депутат Мөхәммәтзариф Бадамшин кулга алына. Берникадәр вакыттан соң, мөселман җәмәгатьчелеге тарафыннан аны азат итү турында гариза языла. Тоткынны азат итүгә бер сәбәп итеп хатынының кайгы-хәсрәткә чумуы белдерелә, чөнки ул, сатып алучыларга үз йөзен күрсәтә алмаганлыктан, сәүдә эшен башкара алмаган[7].

«Ялт-йолт» журналының 1910 елгы санында хиҗабның рәсеме басыла. Карикатураның сюжеты өч хатын-кыз белән Европача киенгән ир-ат һәм улының очрашуыннан гыйбарәт. Улы әтисеннән: «Әти, теге бара торган нәрсәләр, ни алар?» – дип сорый,

[6] Мәүледова Б. Минем сөальләрем // Ислах. – 1908. – № 22. – Б.8.
[7] НАРТ Ф. 190. Оп. 2. Д. 414. Л. 20.

Е.М.Корнеев «Казан татарларында ат чабышы». Фрагмент

ә атасы: «Углым, алар Печән базары чүмәләләре», – дип җавап кайтара. Улы яңадан сорау бирә: «Соң, алай булгач, ник аларның аяклары бар?» Әтисе: «Углым, алар әүвәлдәрәк кеше булганлар!» – ди. Бу карикатурадан авторның хиҗабтагы хатыннарга мөнәсәбәте ачык аңлашыла, яңалык тарафдары, ягъни журнал редакциясе кадимиләргә һәм аларның яшәү рәвешенә тискәре карашын белдерә. Тарихи җәһәттән әлеге рәсем гаять әһәмиятле документ: анда гадәти киенү тәртибе – «чүмәлә» тасвирланган, татар хатын-кызы киеме белән чит-ят күздән тулысынча яшеренгән. Бу рәвешле киенеп йөрүче хатын-кызлар күп булганмы? Монысы инде башка мәсьәлә.

Алда искә алынган П.В.Знаменский дөрес яза: *«Татар баерак булган саен, ул үз хатынын ныграк яшерергә теләгән. Аңлашыла ки, ярлы, эшче халкына, шәһәр яки авылда яшәмәсен, болай итеп киенү мөмкин булмаган; әмма ярлы хатын-кыз да ир-атлар белән очрашканда йөзен капларга, һич югы аралашкан вакытта читкә карарга мәҗбүр...*[8]» Башкача әйткәндә, хатын иренең дәрәҗәсен чагылдырырга тиеш булган. Ир-ат җәмгыятьтә никадәр югарырак урын биләсә, аның хатыны, гомумән бар шәхси тормышы һәм гаиләсе чит-ятлардан ныграк яшерелгән.

Шәхси тормышның кагылгысызлыгы беренче урынга чыккан. Шуңа күрә дә Казанның татар бистәләре һәм бай татарлар яшәгән башка торак пунктлар нигездә бертөрлерәк күренгән: *«...гади яки затлы буяу белән буялган гаять биек капка-коймалар сузылып киткән. Йортлар күренми дә диярлек – хуҗалыкның уртасында, яшеллек эчендә урнашкан»*[9]. Әгәр дә йорт ызан буена салынса, күршеләргә караган диварны тәрәзәсез итеп төзегәннәр. К.Фукс та: *«Йорт гадәттә хуҗалыкның уртасына урнашкан, ә аның тирә-ягында амбар һәм башка агач корылмалар»,* – дип язган[10].

Йортның эчке-тышкы мәйданы, оештыру тәртибе һәм аның асылы ислам дине таләпләренә җавап биргән. Исламда «ир-атныкы» һәм «хатын-кызныкы», «рөхсәт ителгән» (хәләл) һәм «тыелган» (хәрәм) дигән төшенчәләр анык билгеләнгән. Юкка гына «хәрәм» һәм «гарем» сүзләре бер үк мәгънәне белдерми. Татар йорты дини һәм этник үзенчәлеккә ия, «ир-ат» һәм «хатын-кыз» почмагына, ягъни «ак як» һәм «кара як»ка бүленә[11]. Шушы үзенчәлекне истә тотып, татарда хиҗаб бер гадәти күренеш икәнен, ә «чүмәләләр» кебек тулысынча яшеренү гаилә башлыгының байлыгына һәм дәрәҗәсенә бәйле булганын онытмаска кирәк. Знаменский фикерен А.А.Сухарев язганнар да дәлилли: *«Хатын-кызлар фәкать байларның йор-*

---

[8] Знаменский П.В. Казанские татары. – Казань: Изд-во «Иман», 2004. – С.16.
[9] Воробьев Н.И. Жилища и поселения казанских татар Арского кантона ТССР. – Казань: 1-я типография «Красный Печатник», 1926. – С.5.
[10] Фукс К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. – Казань: Фонд ТЯК, 1991. – С.22.
[11] Сулейманова Д. Н. Интерьер татарского дома: истоки и развитие. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2010. – С.89-91.

К.Ф.Гун «Казан губернасындагы татар кызы»

тында гына яшеренгән, башкалар өчен алар үрнәк булырга омтылган»[12].

Татар хатын-кызлары тарафыннан гәүдә-сынны җәмәгать урыннарында яшерү мәсьәләсенә килгәндә, төрле чыганакларны тикшерергә кирәк. Мисал өчен, урыс рәссамы Е.М.Корнеев иҗат иткән «Казан татарларында ат чабышы» исемле гравюраның сул ягында көймәле арбага утырган бала һәм хатын сурәтләнгән. Бу уңайдан, К.Фукс көймәле арбаларның гадәттә урман эчендә, бәйрәм оештырыла торган урыннан ерак булмаган урында тукталуы, татар хатын-кызларының тамашаны шуннан күз кырые белән генә күзәтүе турында яза. Арба янәшәсендә мех читле такыя бүрек кигән, тезмә таккан хатын да басып тора. Чәчне каплый торган тезмә тукымадан эшләнгән, кызыл һәм зәңгәр төскә буялган ике кисәктән тора, асты чук белән бизәлгән. Хатынның өс киеме озын җиңле камзулны хәтерләтә, аның астыннан кара күлмәге күренә. Аягында – ачык төстәге оек һәм яссы табанлы үкчәсез туфли.

Гравюрада хатын-кыз тагын ике урында бар. Берсе – читтә, чирәмдә ур-

[12] Сухарев А.А. Казанские татары (Уезд Казанский). Опыт этнографического и медико-антропологического исследования: Дисс. на степень доктора медицины. – СПб.: Типография П. П. Сойкина, 1904. – С. 41.

нашкан аерым татар гаиләләре. Аларның киеме схематик рәвештә генә иҗат ителгән булуга карамастан, алгы пландагы хатын-кызларныкына тулысынча охшаганлыгы аңлашыла. Шулай итеп, рәссам XIX гасыр башы татар хатын-кызы киемен төрле яктан (арттан-алдан, яннан) тасвирлап, шул чорның җанлы картинасын тудырган.

К.Ф.Гунның 1862 елда Бирдебәк авылында иҗат иткән «Казан губернасындагы татар кызы» исемле әсәрендә хатын-кыз кәчтүме сурәтләнгән. Уң якта утырган кыз – төрле төстәге киндер трикотаж тукымадан тегелгән, өсте чуклы калфактан. Калфакның маңгай өлешенә алтынсу чуклы ука чәчәк беркетелгән. Рәсемгә карап, аның җете кызыл төстәге (өйдә тукылган тукымадандыр, мөгаен), аскы өлеше чуар фабрика тукымасыннан тегелгән бала итәкле, кулны каплый торган озын җиңле тоташ толыплы күлмәк кигәнлеген күрәбез. Күлмәкнең күкрәк өлеше төрле төстәге тукымадан тегелгән изү белән капланган. Муенында – материядән эшләнгән яка чылбыры, аның күкрәк ягыннан металл каптырмасы һәм дүрт асма бизәге бар. Сул як иңбашыннан хәситә асылган, андагы тар тукыма кисәкләренә төрле тәңкәләр тегелгән. Аягында казан татарларына хас милли аяк киеме – читек. Ул яссы табанлы, яшел төстә һәм төрле орнамент белән бизәлгән. Бу уңайдан Н.И.Воробьев язганны да искәртеп китү урынлы булыр: *«Авылларда аны таза тормышлылар гына кия, ә гади крестьяннар сирәк...*[13]*»* Бу киемнәрне гадәттә бәйрәм вакытында кигәннәр. Сул яктагы кыз, киресенчә, безне көндәлек кием белән таныштыра. Аның башында төрле төстәге тукымадан тегелгән, ияк астыннан ике почмагы белән бәйләнгән яулык. Зәңгәр төстәге өске күлмәге башка тукымадан тегелгән геометрик бизәкле бала итәк белән эшләнгән. Кызның күкрәгендә изү, аягында оек һәм чабата. Шулай итеп, рәссам бер картинада ике төрле кәчтүм комплексын берләштерә, бер үк социаль төркемдәге кызларның бәйрәм һәм көндәлек тормышта киенү рәвешен күрсәтә.

«Ялт-йолт» журналының бер санында йөзләрен җилән һәм яулык белән каплаган кызларны мәдрәсә тәрәзәсеннән күзәтүче яшь егетләр тасвирланган. Карикатура астына: *«Казан мәдрәсәләренең берсендә шәкертләрнең өйләдән соң шөгыльләре»*, – дип язып та куелган.

Татарларның киемнәре турында язганда, халыкның европалашуы хакында да онытырга ярамый, чөнки кайберәүләр үзләренә, мөселманчадан бигрәк, Европача киенүне үрнәк итеп алганнар.

Шунысын әйтергә кирәк: гасырлар дәвамында үзгәреп торган хатын-кыз киеме тулысы белән хиҗаб принцибына тәңгәл килгән. Идел-Урал буенда яшәгән мөселман хатын-кызлары никаб урынына җилән һәм өрпәкне файдаланган. Шуның өстенә күлмәк, баш киеме, бөркәнчек, яулык кебек киемнәр гаурәт саклау мәсьәләсен тулысынча хәл иткән.

Традицион халык киемнәре турында сөйләгәндә төрле аспектны күз уңында тотарга кирәк. Аерым катлау халыкка яки бер яшьтәгеләргә карап кына да фикер йөртергә ярамый. Бу мәсьәләдә катгый фикер белдергәнче, ашыгыч карар кабул иткәнче, иң әүвәле шул чордагы тарихи чыганакларны тәфсилләп өйрәнү мөһим.

***Редакциядән:** Ә сез ничек уйлыйсыз? Галимнәрне, әдипләрне һәм башка зыялыларны, шулай ук дин әһелләрен бу мәсьәлә буенча фикер алышырга чакырабыз.* ■

[13] Воробьёв Н.И. Материальная культура казанских татар (опыт этнографического исследования). – Казань: Издательство: Дом Татарской Культуры и Академический Центр ТНКП, 1930. – С.352.

Моңлы хатын Бибигайшә

(1905 нче елда үз-үзене Кабан күленә ташлаган хатынның вакыйгасы[1])



СҮЗ БАШЫ

Бу кыйссадан хисса нидер,
Шуны чынлап аңлагыз.
Бу бер чүп-чар икән, диеп,
Укымыйча калмагыз.

Әфәнделәр! Бу яздыгым хикәягә мөкаддимә уларак бер-ике сүз язмак булам.

Шәригать мотаһһәрәбез[2] адәмнәрнең сәгадәт[3] вә сыйххәтне[4] саклау өчен күп хатын алмакны мәшруг[5] итмеш.

Ләкин безем татарлар бу кануне илаһины урынсыз истигъмаль[6] итеп, гаиләнең ямене, рәхәт вә сәгадәтенең тәмене татдырмас өчен ике-өч хатын алырлар.

Мисал уларак, 1905 сәнәдә үз-үзене Кабан күленә ташлаган Бибигайшә Әхмәтҗан кызы Вәлитованы күрсәтәбез.

Мәзкүрә[7] зәүҗе[8] өстенә яшь хатын алганлыктан, зәүҗендә гаять мәхәббәте улып, көндәшеннән зәүҗене көнләдекеннән вә зәүҗе дә моның мәхәббәтенә карамаюб, соңрадан алган зәүҗәсенә хатын вә буңа бер хадимә[9] нәзар илә карадыкыннан, үз-үзене һәлак итмеш вә үзеннән соңра берникадәр яшь балалары да ятим калмыштыр.

Безем ирләребез хатын-кызны, үзләренә рәфика[10] вә эшләрендә бер ярдәмче дия карамаюб, аларны бер уенчык вә хайваниятне үтәр өчен яратылган бер мәхлук нәзар илә генә карыйлар.

Менә шул сәбәптән күп хатын-кызларның гыйффәтсез, намуссыз уларак яшәүләренә вә соңрадан да билкөлли[11] һәлак булуларына сәбәп булалар.

Ирләребезнең бу кеби гасырда бу илә фикердә улуларына җәһаләттән[12] башка ни мәгънә бирмәк кирәк.

*Я.М.**

[1] Моңлы хатын Бибигайшә: 1905 нче елда үз-үзене Кабан күленә ташлаган хатынның вакыйгасы / Наширләре: борадәран Кәримовлар. – Казан: Матбагаи Кәримия, 1908

[2] Мотаһһәрә – изге.

[3] Сәгадәт – бәхет.

[4] Сыйххәт – исәнлек.

[5] Мәшруг – шәригать каршында дөрес эш.

[6] Истигъмаль – куллану.

[7] Мәзкүр – югарыда, әйтелгән.

[8] Зәүҗә – хатын.

[9] Хадимә – хезмәтче.

[10] Рәфика – иптәш, хатын.

[11] Билкөлли – бөтенләй.

[12] Җәһаләт – наданлык.

*Якуб Мамышев *(Ред. иск.)* – Арча районының Орнашбаш авылында туган, XIX гасыр азагы-XX йөзнең беренче чирегендә яшәгән шагыйрь.

ЯЗГАНЫМА КОЛАК САЛ[13]

Менә сезгә бер кыйсса,
Колак салып тыңлагыз.
Бик күңелле булмаса да,
Көйгә салып моңлагыз.
Бу кыйссадан хисса нидер,
Шуны чынлап аңлагыз.
Бу бер чүп-чар язган, диеп,
Укымыйча калмагыз.
Аз булса да файда булыр,
Чын күңелдән укысаң.
Бертөрле бар, һични алмас
Колагына тукысаң.
Чын күңелдән укыйм, дисәң,
Моннан башкалар да бар.
Аларны да әйтер идем,
Минем вакыт әле тар.
Укы, туган, укысаң,
Белерсең син тәм кайда.
Йолаң булсын, буш вакытта
Укып алырга файда.
Мәдрәсәдә һәм мәктәптә
Укып булмый барын да.
Укып җибәр китап алып,
Азрак вакыт барында.
Бушка үтмәсен бәйрәмең дә,
Аз булса да мәшгуль бул.
Якын күреп күрсәтәмен
Сиңа, туган, тугъры юл.
Эшсезлектән азып китә
Безнең татар яшьләре.
Яманлыктан әрәм була
Алтын кеби башлары.
Көтебханә бар түгелме,
Азрак барып укырга.
Сезгә кирәк юл күрсәтү,
Ничек кирәк сукырга.
Җитәр инде, артык язмыйм,
Кәкре каләм кадалсын.
Алла безне барчабызны
Тугъры юлына салсын.

ГАЙШӘ ХАНЫМНЫҢ ИРЕНӘ ӘЙТКӘН СҮЗЛӘРЕ

Күзең төште бер яшькә,
Алдың аны көндәшкә.
Көндәш утына яндырдың,
Карамадың күз яшькә.
Сөя идем мин сине
Чын күңелемнән җаратып,
Син хезмәттә вакытыңда
Көтә идем җан атып.
Син җанымны сөя идем,
Йоклата идем кулымда.
Сөйгәнемне шуннан бел син,
Корбан булдым юлыңда.
Хезмәтемне кызганмадым,
Караң, ап-ак төннән мин.

Кабан күле. Узган гасыр башы

[13] Бу җырларның һәркаюсы («Корысын, балам») көенә укылырга тиеш.

Син никадәр җәфа кылсаң,
Барысын да йоттым мин.
Матурлыгым, зифалыгым,
Бар да иде җирендә.
Ни кушсаң да, эшли идем,
Калдырмадым берне дә.
Зөләйхаң[14] да артык түгел,
Миннән матур карарга.
Бар күңелемне сарыф иттем
Син җанымга ярарга.
Гөнаһым юк синең хакта,
Ир хакыңны куймадым.
Син никадәр сөймәсәң дә,
Мин сөюдән туймадым.
Син шулай да күрсәтмәдең
Миңа якты йөзеңне.
Ишетмәдем синең бер дә
Яхшы, тәмле сүзеңне.
Шулай да мин синнән разый,
Үлдем синең юлыңда.
Кызганамын, балаларым
Калды үги кулында.
Көндәшемнән җәберләтмә,
Күз нурларымны, зинһар.
Тәрбия кыл син аларны,
Синдә аларның хакы бар.
Өст-башларын яхшы кара,
Ертык-тишек булмасын.
Ятим булып моңаймасын,
Күңелләре тулмасын.
Көндәшемнән сакла яхшы,
Сукмасын да какмасын.
Әгәр сукса вә орышса,
Ата булып якла син.
Алар хәзер синең кулда,
Сиңа карый моңаеп.
Үги ана бик зәһәрле,
Таба бердән мең гаеп.
Вакыт җиткәч, бир мәктәпкә,
Укыр, язып, хат таныр.
Өстемә килеп Коръән укыр,
Минем рухым шатланыр.
Яшь чагында укысыннар,
Зинһар, надан калмасын.
Артын-алдын яхшы белсен,
Уңны, сулны аңласын.
Дөнья эшен эшли белсен,
Буш калмасын һичнидән.
Урак урсын, чалгы тотсын,
Куя белсен һәм кибән.
Сәясәттән хәбәр алсын,
Укып булсын һәм хәким.
Гыйльме тыйбны[15] яхшы белсә,
Доктор булса, кемнән ким?!
Гыйльме динне укып белсен,
Мелла булсын бер илгә.
Яшь вакытлар бик кадерле,
Әрәм булмасын җилгә.
Яхшылыкны үрәнсеннәр,
Яманлыктан чиксеннәр.
Гыйлем алу, һөнәр өчен
Чит җирләргә китсеннәр.
Васыятем әйтеп бетте,
Инде үлсәм дә үкенмим.
Кабан күленә сикереп төшәм,
Хушыгыз инде, мин килмим.

ГАЙШӘ ХАНЫМНЫҢ МОҢЛЫ ҖЫРЛАРЫ

Кайгы-хәсрәт күрмәдем
Яшүсмерле чагымда.
Уйнап-көлеп тордым мин
Үз әнкәм кочагында.
Үсеп җиткәч мин буйга,
Әнкәй килгән бер уйга.
Шатлык алган бар дөньясын –
Хәзерләнәдер туйга.
Күп үтмәде, туй булды,
Өйгә кодалар тулды.
Озакламый мелла килде,
Никах дәхи укылды.
Шулай итеп яшь килен
Булып китте кыз башым.
Шатлыкларым кайгы булды,
Кемгә төшәр күз яшем.
Яшь чагымда уйлый идем,
Һаман рәхәт килер, дип.
Мәрхәмәтсез бу дөньяны
Миңа гына килер, дип.
Мәрхәмәтсез канатны
Салды минем башыма.
Җәфалады, карамады
Күзләремнең яшенә.
Бу дөньядан мин биздем,
Җәфасына күп түздем.

[14] Зөләйха – Бибигайшәнең көндәше.
[15] Гыйльме тыйб – медицина.

Рәхәт булыр, димимен,
Өмидемне мин өздем.
Әллә дөнья үчең бармы?
Шуны миннән аласың.
Җәфалыйсың, хафалыйсың
Газиз адәм баласын.
Җәфаладың, хафаладың
Гомеремнең күбендә.
Ахырында чыкты җаным,
Кабан күле төбендә.
Кызганмады дөнья мине,
Җәфа салды башыма.
Алып китте, җиткермәде
Егерме биш яшемә.
Алдамасын сезне, кызлар,
Яшь чагында шат йөрү.
Исегездән һич чыкмасын
Беркөн хәсрәтләр күрү.
Дөнья көлсә бервакытта,
Егълатадыр күп вакыт.
Минем сүзне дөрест дирсез,
Килеп җитсә шул вакыт.
Хатын-кызлар колак салың,
Сезгә әйтәм сүземне.
Мисал итеп, гыйбрәт өчен
Китерәм мин үземне.
Бу дөньяда бары хәйлә,
Чын нәрсәсе бер дә юк.
Туксан тугыз ач кешеләр,
Йөздән бары бере тук.

ГАЙШӘ ХАНЫМНЫҢ БАЛАЛАРЫНА КҮЗ ЯШЕ

Балаларым, бәгырьләрем,
Калдыгыз ла яшьли сез.
Әнкәгезне сагынганда,
Белмим инде нишлисез.
Бәлки сезләр үткәрәсез
Моңаешып көннәрне.
Тәкъдир шулай, балаларым,
Ятим итми кемнәрне.
Бер сез генә түгел калган
Атасыз да анасыз.
Бәлки сезләр, балаларым,
Хәсрәт утына янасыз.
Дошман күрде сезне дөнья,
Калдыгыз ла анасыз.
Үги ана учагында
Инде сезләр янасыз.
Кызганамын, сызланамын
Сезнең өчен, нурларым.
Күз алдымда сез идегез
Миңа дөнья хурларым.
Балаларым, чәчкәләрем,
Укымыйча калмагыз.
Надан булып үзегезне,
Михнәт эченә салмагыз.
Уку кирәк, балаларым,
Мужикка да меллага.
Надан көе ничек кирәк
Якын булмак Аллага.

Кабан күле. Узган гасыр башы

Сүзем тотып укысагыз,
Якты булыр йөзегез.
Мин күрмәмен рәхәтне,
Рәхәт күрер үзегез.
Мәктәп юлы сезгә булсын
Иртә торгач такыр юл.
Бик тырышып укысагыз,
Акча булыр сезгә мул.
Хуш, балалар, сау булыгыз,
Калдырамын сезләрне.
Кайчагында искә алыгыз,
Дога берлән безләрне.

ГАЙШӘ ХАНЫМНЫҢ КАРЕНДӘШЛӘРЕНӘ ӘЙТКӘН СҮЗЛӘРЕ

Кардәшләрем, минем өчен
Кайгырмагыз сез бер дә.
Минем өчен монда рәхәт
Ялгыз яту тар гүрдә.
Бары шунысы бик күңелсез,
Сез генә юк каршымда.
Кайчагында искә алып,
Ясин укың башымда.
Үкенечем калды минем –
Күрә алмадым үлгәндә.
Балаларым, юатыгыз,
Искә төшереп килгәндә.
Дөнья мине мәҗбүр итте
Теләп үлем алырга.
Кунак булып барып калдым
Сезне күреп калырга.
Тәкъдир шулай, сабыр итегез,
Кайгырмагыз юк өчен.
Хафалаган явыз дөнья
Алды миннән тиз үчен.
Хуш, туганнар, сау булыгыз,
Тыныч булсын күңелегез.
Кайчагында искә алып,
Зиярәткә килегез.

ГАЙШӘ ХАНЫМНЫҢ ИРЛӘРГӘ ӘЙТКӘН СҮЗЛӘРЕ

Ай, чын ирләр, көзгеләр,
Сездә бармы изгеләр.
Үзегезчә әгәр әйтсәк,
Сез – гакыллы, без – юләр.
Бәгъзе берең әйтәдер,
Гакылда ким хатын-кыз.
Бу дөньяның яртысын
Түгелме соң тоткан без.
Ирләрдән бар шундыйлар,
Гакылда ким, чын җүләр.
Хатын-кызлар булмаса,
Ертык-тишек кем җүләр.
Ир булсагыз, урныгызда
Игътибарлы булыгыз.
Хатын-кызны хур күрмәгез,
Алар түгел колыгыз.
Алар берлән уйнамагыз,
Алар түгел бит курчак.
Хәзер инде сезгә вакыт
Инсан диеп белер чак.
Хатыныгызга сез карагыз
Мәхәббәтле күз илән.
Хәтере калса, юатыгыз
Төрле тәмле сүз илән.
Хатын-кызның күңеле нечкә –
Тиз кырыла, өзелә.
Хатыныңны яхшы тотсаң,
Шунда дөнья төзелә.

СҮЗ АХЫРЫ

Җитәр инде, күп моңайдым,
Туктамакчы шул җирдә.
Тагы бераз язар идем,
Табалмыймын сүз бер дә.
Каләмем дә тая инде,
Баралмыйдыр турыдан.
Каты сүзләр язган булса,
Язылгандыр гауредән[16].
Бәгъзеләрен көзге сезгә
Күрсәткәндер саташып.
Мин каләмне яңа тоттым,
Бәлки киткәнмен шашып.
Гафу итегез, яшь егетләр,
Дәхи картлар, агайлар.
«Гафу итү – ирлек», диеп,
Әйтеп киткән бабайлар.

*Текстны басмага Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге әйдәп баручы библиографы **Энҗе Сабирова** әзерләде.* ■

[16] Гаур – тирән фикер, тирән мәгънә.

Безнең мирас №3 март 2017

Җефет калага сәфәр

Солтан Шәмси

Сәяхәтнамә

Кырым таулары

Ниһаять, без каланы икегә бүлеп торган Орта капуга (Урта капка) килеп җиттек. Ул калага нигез салынгач төзелгән иң борынгы корылма икән. Башта кала Кече капу белән Урта капу арасында урнашкан булган. Моннан тыш калада Биюк капу (Олы капка) дигәне дә бар. Анысы XIV-XV йөзләрдә төзелгән. Күрәсең, ул вакытта каланы зурайту ихтыяҗы туган булса кирәк. Шуңа күрә, каланы киңәйтеп, 8 метр биеклегендәге яңа капка, аннан бераз тәбәнәгрәк итеп диварлар төзелгән. Элек, капка алдында кыяны кисеп, 9 метр тирәнлегендәге чокыр да казылган. Аның әле асылма күпере дә булгандыр. Бу якта диварның озынлыгы 128 метр икән. Ул хәзерге көнгә кадәр сакланып калган.

Мине, Урта капканы чыккач, уң якта урнашкан караим Авраам Фиркович (1786-1874) йорты гаҗәпкә калдырды. Бу кеше караимнәрнең легендар шәхесе икән. Ул гомеренең шактый өлешен борынгы яһүд телендәге китапларны, кульъязмаларны туплауга багышлаган, аларны системага салган, үзе дә китаплар язган, яһүд зиратларындагы кабер ташлары язуларын җыйган, дин әһеле – газзан булган. Кульъязмалар, китаплар туплау максаты белән бөтен Кырымны, Кавказны йөреп чыккан, шул ук максат белән Истанбулда, Иерусәлимдә, Яффада, Наблуста, Алеппо, Бәйрут, Каһирә шәһәрләрендә булган. Аның Беренче һәм Икенче тупланмалары ул вакытта дөньяда яһүд телендәге иң зур кульъязмалар җыелмасын тәшкил иткән. 1865 елда ул Якын Көнчыгыштагы сәяхәтеннән әйләнеп кайта да Җефет калада яши башлый, караимнәр ташлап киткән бу калада тормышны кабат җанландыру өчен омтылышлар ясап карый. Бер елдан аның хатыны вафат була, ул Җефет кала янындагы караимнәр зиратында җирләнә. А.Фиркович 84 яшендә кабат

Ахыры. Башы 2 нче санда.

өйләнә, әмма яшь хатыны белән дүрт ел гына яшәп кала, 1874 елда вафат була, беренче хатыны Хана янында күмелә.

Бу шәхеснең тормышы, эшчәнлеге мине шактый уйланырга мәҗбүр итте. Безнең мәшһүр Каюм Насыйри искә төште. Ул да бит авыр шартларда гомерен халкына хезмәт итүгә багышлаган. Милләтенә гомер буе хезмәт иткән бу кешенең караим халкының тарихына үз карашы булган икән. Караимнәр төрки хәзәрләрдән аерылып чыккан субэтнос (кечкенә халык) булуга да карамастан, Авраам Фиркович фәндә беренче тапкыр, караимнәрнең хәзәрләр белән этник туганлыгы юк, дип язып чыга. Алар аерым халык, хәзәрләр белән аларны дин (яһүд дине) уртаклыгы гына берләштерә, дигән караштa торган. Караимнәрнең килеп чыгышы бик кызыклы мәсьәлә, алда без аңа әле җентекләп тукталырбыз.

Ниһаять, Җефет каланы йөреп бетереп, без Олы капкадан тышкы якка чыктык. Бу тарихи каланы тамаша кылып йөрү миндә күп уйлар уятты. Төп урамындагы таш юлда кыя ташына утыз сантиметр баткан тәгәрмәч эзен күрү миңа аеруча нык тәэсир итте. Бу батып кергән эзләр гасырлар буе калада җанлы тормыш баруы турында сөйли иде. Ул юлны «меңьеллык юл» дип атыйлар икән. Чыннан да, тау өстендәге башкаланы азык-төлек, төрле кирәк-ярак белән

Авраам Фиркович

тәэмин итеп тору өчен бу юлдан арбалар гел йөреп торган, монда тормыш җиңел булмаган, барысын да астан, үзәннән ташырга туры килгән.

Җефет каладан чыккач, без аннан ярты чакрымда урнашкан караим зиратына төшеп киттек. Ул шактый киң үзәндә урнашкан булып чыкты. Бераздан без зират капкасы каршына килеп туктадык. Экскурсовод ханым зират тарихы турында сөйли. Зират таш коймa белән әйләндереп алынган. Мин



Зиратның капка баганасына «Балта тиймэз» диган язу ябыштырылган

Безнең мирас №3 март 2017

Караим гаиләсе.
1886 елның ноябре

капкадан зират эченә үк үттем. Вакыт дигән нәрсә яһүдләргә хас кабер ташларын кызганмаган. Ташларның кайберсе ауган, кыйшайган, җиргә баткан, күбесен яшел мүк каплаган. Ташларда яһүд хәрефләре белән язылган язулар күренә, ханымның сөйләвенә караганда, алар караим телендә – төрки телдә икән. Арадан берсе рус телендә кириллица белән язылган. Таш 1904 елдагы рус-япон сугышында катнашкан хәрби караимгә куелган. Караимнәрдә имән агачы изге агач санала икән. Элек зиратта юан имәннәр күп булган, хәзер алар юкка чыккан, башка агачлар үсә. Шунысы кызык, зиратның капка баганасына «Балта тиймәз» дип язылган язу ябыштырылган, астарак «Топор не тронет» дигән русчасы да бар. Бу – борынгы зират, яңа каберләр күренми. Димәк, караимнәр хәзер мәетләрен башка җиргә күмәләр. Бирегә бары тик фаҗигале язмышларын искә алу өчен генә килеп чыккалыйлардыр.

Караимнәр тарихы Хәзәр дәүләте тарихы белән тыгыз бәйләнештә тора. Хәзәр дәүләтен мәшһүр тарихчы Лев Гумилев «химера» дип атый һәм моны үзенең «Древняя Русь и Великая степь» исемле хезмәтендә исбатлап күрсәтә. Нәрсә соң ул «химера», нигә тарихчы бу дәүләтне шулай атаган? Борынгы грек мифологиясендә ут бөркеп торучы арыслан башлы, аждаһаныкы сыман койрыклы, гәүдәсе кәҗәнекенә охшаган гаҗәп бер хайван икән ул. Аны фантазия җимеше, ягъни бер-берсенә һич яраклаша алмаган, гармониягә ирешүдән ерак торган бернәрсә дип атасаң да ярый. Химера ничек пәйда була соң? Кушылуы мөмкин булмаган нәрсәләрнең бер организм булып яшәргә омтылуыннан килеп чыга ул.

Хәзәр дәүләтендә дә шундый ситуация барлыкка килә. Билгеле булганча, хәзәрләр – төрки халык. Иделнең түбән агымында алар үз заманы өчен шактый көчле һәм бай дәүләт төзиләр. Эш шунда ки, көньяк тармагы Кытайдан Урта диңгезгә, икенче төньяк тармагы Кара диңгезгә таба сузылган Бөек Ефәк юлы Хәзәр дәүләте аша узган. Шул сәбәпле хәзәрләр транзит сәүдәсеннән зур файда күреп яшәгәннәр. Ә Бөек Ефәк юлында яһүдләр сәүдә иткән. Аларны рахдонитлар дип атаганнар, ягъни юл белүчеләр. Хәзәр дәүләтенең башкаласы Итил – Идел елгасының Каспий диңгезенә койган урынында – дельтада урнашкан була. Дәүләт башында төрки Ашина ыруы каганнары торганда анда социаль каршылыклар сизелми. Әмма Иранда баш күтәргән Маздак тарафдарлары җиңелгәннән соң, бу хәрәкәткә

катнашкан яһүдләр Хәзәр дәүләтенә качып килә, шулай ук Византиядә көчләп христиан диненә күчерелә башлаган яһүдләр дә шушында килеп урнаша. Тора-бара алар, кызларын хәзәр каганнарына кияүгә биреп, дәүләт белән идарә итүне үз кулларына алалар. Бераздан хәзәрләр яһүдләр диненә күчә башлый. Дөрес, Ибне Фазлан (Фадлан) язганча, Хәзәр дәүләтендә мөселманнар да була. Төрки хәзәрләрнең бер өлеше борынгыдан килгән Тәңре динендә кала.

Бу дәүләттә яһүд динен кабул иткән караим дигән халык ничек барлыкка килгән соң? Яһүдләр белән хәзәрләрнең үзара кушылуыннан, гаилә төзеп яши башлавыннан килеп чыга бу халык. Билгеле булганча, яһүдләрдә анасы яһүдә булган кеше генә чын яһүд санала. Әгәр дә яһүд кешесе хәзәр кызына өйләнсә, ул вакытта бу никахтан туган бала инде чын яһүд түгел, ә караим була. Ул инде яһүдләрнең ябык җәмгыятенә кабул ителә алмый. Аңа изге китап Тәүратны (Тора) да өйрәтеп тормаганнар, гәрчә ул яһүд динендә булса да. Караимнәрнең килеп чыгышы менә шушы социаль тәртипләргә бәйле. Яһүд динендә булу аларның тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә, кием-салымына да нык тәэсир иткән. Татарларның теленә, тормыш-көнкүрешенә ислам дине, мәдәнияте аша бик күп гарәп сүзләре, гадәтләре кергән кебек, караим теленә дә яһүд дине аша шактый сүзләр кергән. Хәзәр дәүләтендә бер-берсеннән бик нык аерылып торган ике халык яшәгәнгә, анда гармониягә ия җәмгыять барлыкка килә алмаган. Шулай итеп, Лев Гумилев атаганча, химера хасил булган.

Баштарак әле хәзәр каганнары төрки исемдә булса (Болан каган), тора-бара каганнар инде яһүд исемнәрен йөрткәннәр (Обадия, Аарон, Иосиф). Дәүләт белән бәк идарә иткән. Бәкнең яһүдләрдән булуы шик уятмый. Ибне Фазлан язганча, бөтен әһәмиятле эшләрне ул башкарган. Бу хакта Лев Гумилев менә нәрсә яза: *«Двоевластие» в Хазарии было грандиозным обманом народа, которому раз в год показывали законного хана, уже ставшего иудеем, для того чтобы остальное время глава иудейской общины выжимал из хазар и окрестных народов средства на наемников, которые должны были хазар подавлять»* (Л.Н.Гумилев. «Древняя Русь и Великая степь». М., «Мысль», 1989. – С.150.). Шулай итеп, төрки хәзәрләргә үз дәүләтләрендә икенче сорт халык булып яшәргә генә кала.

Мондый хәлгә риза булмаган хәзәрләр баш күтәреп тә караганнар, тик уңышка ирешә алмаганнар. *«Репрессии итильского правительства против мятежников были в первой половине IX в. столь радикальны, что соотношение сил пришлого правительства и побежденного народа стало очевидным для тех и других.<....> Потому-то арабские географы различали «черных» и «белых» хазар как два разных этноса, живущих совместно в одном государстве. Поэтому-то нужно ввести два термина: «иудео-хазары» и «тюрко-хазары»* (Л.Н.Гумилев. Там же. – С.146-147.). Шушы ике халык арасында яһүдләр динен кабул иткән төрки караимнар барлыкка килә.

964 елда Хәзәр дәүләте белән руслар арасында сугыш башланып китә. Хәзәрләрнең атлы гаскәре Дон буендагы далаларда булган вакытта рус кенәзе Святослав 965 елда Идел буенча зур көймәләрдә Итил каласына килә, ягъни хәзәр гаскәренең артына төшә. Ул Итил шәһәрен басып ала, хәзәр дәүләтен тар-мар итә. Хәзәр дәүләтенең үзеге юк ителгәч, исән калган халык төрле якларга таралыша. Лев Гумилев фикеренчә, шушы вакыйгалардан соң, Бөек дала халыклары өчен 250 ел дәвам иткән этник яктан таркалу дәвере килгән. Хәзәр исемен йөртүчеләр кайсы якларга таралган соң? Аларның бер өлеше Дагыстанда тупләнә, шунда тау яһүдләре булып китә, икенче бер өлеше Кырымда урын таба. Алар соңрак караим халкына әверелә. Күрәсең, шушы вакыйгалар-

дан соң караимнәр Җефет калага күчеп килә башлаганнардыр. Караимнәрнең бер өлеше Көнбатыш Украинада сыену урыны таба. Дон буенда калган хәзәрләр тора-бара «бродниклар» булып киткән, күпмедер вакыттан соң алар Дон казакларына әверелгән. Шулай Хәзәр дәүләте юкка чыкканнан соң таркалган халыклардан төрле җирләрдә берничә кечкенә этнос (субэтнос) барлыкка килә. Киләчәктә аларның һәрберсе күршеләре белән уртак тел табып яшәргә мәҗбүр була. Лев Гумилев хәзәрләрнең Алтын Урда дәүләтендә мөселман дине кабул итүе, татар халкына килеп кушылуы турында да яза. Ул шулай ук XIII гасыр ахырында Каспий диңгезенең суы 17 метрга күтәрелүен, элекке Хәзәр дәүләте җирләренең өчтән ике өлеше су астында калуын искәртә. Өстәп шунысын да әйтик – космостан төшерелгән фотосурәтләрдә су астында калган Итил шәһәре җимерекләре бүгенге көндә дә ап-ачык булып күренеп тора икән.

Тел галимнәре караим телен кыпчак телләре төркеменә кертә. Бу телнең өч диалекты бар: Көнбатыш Украинада – Галич диалекты, Кырымда – Кырым диалекты, Литвада – Тракай диалекты. Тел галиме Әхәт Тенишев фикеренчә, караим теленең һәр диалектын аерым тел дип санарга мөмкин икән. Бу күренеш, караим халкының төрле якларга таралышып, аның төркемнәренең бер-берсеннән бик нык ераклашуы аркасында килеп чыккандыр. Караим теленең лексикасында яһүд теле алынмалары, славянизмнар, күпмедер дәрәҗәдә гарәп-фарсы сүзләре дә бар. Караимнәр үзләрен «карай», «карайлар» дип, ә телләрен «карай тили» дип атап йөртәләр. «Карай» дигән сүз төрки хәзәрләрнең үз дәүләтләрендә «кара халык» булып көн күрүеннән килеп чыкмадымы икән? Гарәп географлары хәзәрләрнең ике төркемгә бүленешен язып калдырган. XX гасыр башында Кырымда яшәүче караимнәрнең телен рус теле кулланыштан тулысынча кысып чыгарган. Хәзерге көндә караим теленең Кырым һәм Галич диалектлары тулысынча юкка чыккан, бары тик Литвадагы Тракай диалекты гына сакланып калган. Бүгенге көндә инде караим телендә сөйләшүчеләр саны якынча 540 кешедән дә артмый икән.

Кайчандыр үз дәүләтләре булган төрки хәзәрләрнең, шул исәптән караимнәрнең дә язмышы бик гыйбрәтле. Дәүләтләре юк ителгәннән соң, алар төрле якларга таралышкан, ассимиляциягә дучар булып, телләрен югалткан, дисәң дә була. Бары мөстәкыйль дәүләте булган халыкның гына үз-үзен, телен, мәдәниятен саклап калырга көче җитә. Караим халкының бөтенләй юкка чыгып баруы безнең өчен зур гыйбрәт булып тора.

Инде Чуфут кала, Җефет кала мәсьәләсе хакында фикер йөртеп карыйк. Каланың исеме турында байтак уйланырга туры килде. Фәнни әдәбиятта чыннан да каланың атамасын Чуфут-кале дип язу гадәткә кергән. «Чуфут» кырым татарлары телендә «яһүд» дигәнне аңлата икән. Әгәр дә без кала исемен «Чуфут кала» дип кабул итсәк, ул «Яһүдләр каласы» дигән мәгънәгә ия була. Каланы болай дип атауда кырым татарларының караимнәрне яһүдләр дип санавы сизелеп тора. Әмма каланың икенче төрле әйтелеше дә яши – Җефет кала. Җефет – гарәп сүзе. Ул берничә төрле мәгънәгә ия. Беренче мәгънәсе – җөп, пар; икенчесе – икегә бүленә торган сан; өченчесе – хатын.

Җефет кала чыннан да Урта капка белән ике өлешкә бүленеп тора. Шуңа күрә, аны русча «двойная крепость» дип тә тәрҗемә итәләр, ягъни ике өлештән торган кала-ныгытма. Икенче мәгънәсе бу очракка туры килми. Ә менә өченчесе – «хатын» дигәне игътибарга лаек. Мин моңа Җефет каланың исемен ишетү белән игътибар иттем. Ә инде каланың үзен тамаша кылып йөргәндә Җаникә ханым төрбәсен күргәч, миндә яңа сорау туды.

Билгеле булганча, Җаникә ханым – Туктамыш хан кызы. Ул атаклы Идегәй

Караимнәрнең борынгы зираты

мирзага кияүгә чыга. Ире исән чакта 1416 елда Җаникә ханым үзен озата баручы өч йөз җайдак белән Мәккәгә хаҗ кылырга бара. Идегәй мирза 1419 елда Туктамыш хан улы Кадырбирде белән сугыш алып барганда һәлак була. Ул вакытта Алтын Урда дәүләтендә Идегәй мирза белән Туктамыш хан уллары арасында тәхет өчен көрәш бара. Идегәй мирза үтерелгәннән соң, сарай ыгы-зыгысыннанераграк тору өчен, Җаникә ханым шушы тау башындагы тыныч калага – Кырык Орга күчеп килә һәм, хан кызы буларак, кала белән идарә итә. Ул биредә 1437 елда вафат була һәм Хаҗигәрәй хан шушы калага күчеп килә. Атасыннан соң Кырым тәхетенә чыккан Миңлегәрәй хан, Җаникә ханымга хөрмәт йөзеннән, аңа бик матур төрбә төзетә. Бу төрбә бүгенге көндә дә үзенә игътибарны тартып тора. Ул Җефет калада сакланган иң гүзәл корылмадан санала. Шушы мәгълүматларга таянып, мин Җефет кала яһүдләр каласы дип тә, ике өлештән торган кала дип тә түгел, Җефет кала – Хатын каласы дип аталгандыр, дигән фикергә килдем.

Кырым татарларының яһүд динендәге караимнәрне яһүдләр дип кабул итүе табигый. Алар каберләренә дә текстны яһүд хәрефләре белән язганнар. Гореф-гадәтләре, дини йолалары, киенүләре дә – яһүдләрчә. Шуңа күрә, Җефет кала – Чуфут кала булып киткән. XIX йөз урталарына кадәр караимнәр шушы калада яшәгән. А.Фиркович калада яшәүче соңгы караим булган. Үз халкына бик нык бирелгән шәхес буларак, каланың тормышын кабат җанландыру өчен омтылышлар да ясап караган. Әмма бу эш барып чыкмаган, караимнәр калага әйләнеп кайтмаган. Тау өстендә, җилләр кочагында кемнең яшисе килсен...

Безнең сәфәр караим зираты янында төгәлләнде. Җефет каланы тамаша кылу миндә бик күп уйлар кузгатты. Тарихны аңлавым тагын да тирәнәя төште. Мин тагын бер кат кырым татарлары белән уртак тарихыбыз барлыгын, якын туганлыгыбызны тойдым. Җефет калага сәфәр кылу моңа ярдәм итте. Кырымга сәяхәт күңелемдә тирән хисләр уятты. ■

Безнең мирас №3 март 2017

АВЫЛ ТАРИХЫ

Бабаларым җирендә

Фикърәт Табеев

Фикърәт Әхмәтҗан улы Табеев (1928-2015) – чын мәгънәсендә легендар шәхес. Ул утыз бер яшендә КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булды һәм шул постта унтугыз ел эшләде – күрелмәгән хәл! Җитмәсә, Татарстанны бөек үзгәрешләр (бернинди куштырнакларсыз әйтүем) елларында җитәкләде. Ул чагында әле автономияле республиканың көньяк-көнчыгышында нефть чыгару сәнәгате омтылышлы үсте, күз күрмәгән тизлектә яңа шәһәрләр һәм төзек эшче бистәләре төзелде, ә Кама ярларында Европада иң зур нефть химиясе комплексы һәм автомобиль гиганты калыкты һәм чиста кырда «салават күпере астында» яңа шәһәрләр үсеп чыкты. Бу төбәккә Советлар Союзының барлык почмакларыннан яшьләр агылды.

Ф.Ә.Табеевны ул чагында ук хаклы рәвештә яңа Татарстанны төзүче дип атадылар. Нәкъ менә шул елларда Татарстанның социаль-икътисади куәте булдырылды. Россиянең аграр төбәгеннән ул зур егәрле сәнәгати индустриаль республикага, җәһәт үсешле авыл хуҗалыгы төбәгенә әверелде. Безнең күптән түгелге тарихыбызга бүгенге теләсә нинди идеологик күзлектән карасак та, болар һәммәсе соңрак республиканың суверенлык алуына, һичшиксез, нигез булып ятты.

Ф.Ә.Табеев егерме ел дәвамында КПСС Үзәк Комитеты әгъзасы булды, СССР Югары Советының күп чакырылышларында депутат, СССР Югары Советы Президиумы әгъзасы итеп сайланды. Ул күп санлы орденнар, шул җөмләдән биш Ленин ордены белән бүләкләнде.

Ягъсуф Шәфыйков

Дөньяда могҗизалар булмый. Әгәр бүген Россия Федерациясендә һәм аннан читтә Татарстан турында прогресска ирешә баручы республика буларак сөйлиләр икән, моңа күбесенчә элеккеге, бигрәк тә республика белән Ф.Ә.Табеев җитәкчелек иткән дистәләрчә елларда салынган икътисади нигез аркасында ирешелде.

Минтимер Шәймиев

Мин 1928 елның 4 мартында Рязань өлкәсендәге Ермишино районының зур бер борынгы татар авылы Әзидә туганмын. Риваятьләргә, авылдашларның буыннан- буынга күчеп килгән хикәятләренә караганда, болгарлар, көньяк-көнбатыштан күчә-күчә, мондагы болынлы урыннарда, Мещера үзәнендә төпләнеп калган.

Үзенен матурлыгы белән гаҗәеп төбәк бу. Аңа үзенең үлемсез шигырьләрендә Сергей Есенин дан җырлаган. Бу – Э.Циолковскийнын ватаны. Борынгы Мещера җирендә татарлар, руслар, мордвалар гомер бакый дус булып тату яшәгән. Әлеге төбәк Россия тарихына бик күп күренекле татар исемнәрен биргән. Монда мәгълүм галимә, Сорбонна университетын тәмамлаган математик Сара Шакулова, шагыйрә Заһидә Бурнашева, зур юрист Садыя Гарифовна Беглова туган. Садыя ханым (1923-1992) Казанда КПССның Бауман райкомының беренче секретаре булды, озак еллар Татарстан Югары суды рәисе, республиканың юстиция министры булып эшләде.

Күренекле юрист С.Беглованың исеме Татарстан Республикасы Энциклопедиясенә кертелгән.

Минем авылдашым, танылган шагыйрә Заһидә Бурнашева (1895-1977) үзенең әсәрләрен «Гыйффәт туташ» псевдонимы белән бастырган. Ул шигырьләрен бик иртә яза башлый. 1912 елда аның ике китабы басылып чыга. «Гыйффәт туташ» шигырьләре укучы тарафыннан җылы кабул ителә. Ун елдан соң Казанда татар телендә «Зөһрә йолдыз» дигән бик матур әкияте басыла. Совет елларында Заһидә Хөсәеновна Кыргызстанда яшәгән, мәгариф өлкәсендә эшләгән, күп кенә шигырь һәм поэма җыентыклары иҗат иткән.

Әзидә һәм тирә-юньдә бик шәп педагог Өмет Хәсәнович Бурнашев исеме дә киң билгеле. Өмет Хәсәнович озак еллар балалар йортына, урта мәктәпкә җитәкчелек итте.

Югарыда телгә алынган Сара Шакулова 1939 елны Мәскәүдә беренче татар мәктәбенең директоры итеп билгеләнә. Бу мәктәптә татар әдәбиятының булачак классигы Габдрахман Әпсәләмов укый.

Безнең Әзи авылы казак тибындагы бик мул тормышлы авыл булган. Әдәби чыганаклар аның XIII гасырдан бирле яшәп килгәнлеген раслый. Аның кешеләре болгар дәүләтенең көнбатыш чикләрен саклаган.

Әзи авылындагы мәчет

Әзи авылындагы Ф.Табеев музее

Бүген безнең авылда яшәп килгән бер риваять буенча, Әзигә хаждан кызы белән кайтып килүче татар карты нигез салган. Анда кызы вафат булган һәм аның кабере урынында Әзи авылы (русча – «Хаджия», мишәрчә – Әзи) үсеп чыккан...

Безнең авылда җиде мәчет эшләп килгән. Мәчетләрнең дә ниндиләре генә әле! Архитектурасының гүзәллеге һәм нәфислеге җәһәтеннән, алар Россиянең күп мәчетләреннән аерылып торганнар. Архитектурасы ягыннан берсе дә икенчесенә охшамаган. Ислам төзелеш сәнгатенең бу җәүһәрләренә сокланыр өчен Мәскәүдән, Казаннан, башка шәһәр һәм авыллардан килә торган булганнар. Авылда зур мәдрәсә эшләп торган. Ул Россиядән читтә дә билгеле булган. Россиянең бик күренекле дин әһелләре дә үз вакытында анда укыганнар. Мәсәлән, бөек ислам белгече, дөньяга мәгълүм дин галиме, Коръәнхафиз Ибраһим Урманов Әзидә туган һәм мәдрәсә бетергән. Ул Каһирәдә «Әль-Әзһәр» ислам университетын тәмамлаган.

Егерменче гасыр ахырына Әзидә мәчетләр эшләмәгән инде. Күбесен утызынчы елларда җимергәннәр. Калганнары тузып-искереп беткән.

Һәм менә 1998 елда Әзи кешеләре җыенында бер мәчетне торгызу турында карар кабул ителгән. Шул максатка алар күп кенә акча җыйган. Әлбәттә, мәчет торгызуга иң зур өлеш кертүне элекке колхоз урынына төзелгән «Әзи» ТООсы үз өстенә алган.

Мәскәүдәге эш кабинетым тәрәзәсе Щепкин урамына карый иде (элек ул Беренче мещан урамы булган). Биредә Олимпия комплексы белән янәшәдә Мәскәүнең төп мәчете урнашкан. Аны 1904 елда Әзи кешеләре, эре сәнәгатьчеләр – мехчы миллионерлар Салих Йосыпович Ерзин, Нури Ширинский, Х.Акбулатов салган. Миңа мәгълүм булганча, башкаланың дини идарәсе, якташым, шулай ук Әзи кешесе Морат Сәфәров инициативасы белән, С.Й.Ерзин, Н.Ширинский һәм Х.Акбулатовның ядкярен мәңгеләштерергә һәм мәчеткә истәлек тактасы куярга карар кылган.

Әзи кешеләре бик таза булган. Монда буе ике метрдан ким ир-ат булмаган. Крестьяннар төпле шәхси хуҗалык корган. Бик күп мал-туар тотканнар. Тирәюньдә су баса торган очсыз-кырыйсыз Ока алды болынлыклары җәйрәп яткан. Мул итеп печән әзерләгәннәр, аны Россия армиясе атларына ашатыр өчен озатканнар.

Авылның үсешенә янә бер һөнәр булышлык иткән: Әзи кешеләре Россиядә мех сәнәгатенең күптәнге монополистлары булган. Иң эре мехчыларның берсе – инде телгә алынган Салих Йосыф улы Ерзин 1833 елны Әзидә туган.

Әзи ир-атлары, Россияне яклап,

2016 елның 19 ноябрендә Мәскәүдә совет партия һәм дәүләт эшлеклесе Фикърәт Әхмәтҗан улы Табеевка һәйкәл куелды. Аның ачылышында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты

барлык сугышларда катнашканнар. Аерым алганда, алар 1812 елгы Ватан сугышында актив булганнар. Атаклы Әзи эскадроны дан казанган. Кавалеристлар Париждан, туган авылларында сөрү җиренең аз булуына зарланып, патшага хат язганнар, аңардан Наполеонны җиңү хөрмәтенә бераз җир өстәвен үтенгәннәр.

Совет хакимиятенең беренче елларында авылдашларымның күбесе көйләнгән тормышның бозылуы белән килешмәгән һәм Америкага күчеп киткән. Бүген Табеев фамилияле ерак туганым АКШ штатларының берсендә татар җәмгыятен җитәкли.

Күпләр утызынчы елларда Урта Азиягә юл тотканнар. Мәсәлән, Әзидә туып-үскән Сафхидә Бурнашеваның исеме бүген Әндиҗанда киң билгеле, ә аның улы Эдуард Ильясов – талантлы хирург.

Янә бер әзилене хәтергә төшерәсе килә. Ул – 1822 елда туган Ахун Сәфәров. Соңра – Костромага күчеп килгән һәм 50 ел дәвамында бу шәһәрдәге татар җәмгыятен җитәкләгән. Ахун ага җирле татарлар арасында һәм хакимиятләрдә зур хөрмәт казанган. Аның изге Станислав һәм Александр орденнары белән бүләкләнүе тикмәгә түгел. 1900 елда А.Сәфәровка вакытыннан элек пенсия билгеләнгән. Ул вакытлар өчен бу – аның хезмәтенә иң югары бәя булган. А.Сәфәровның Кострома татарлары турында күп санлы тикшеренүләре бар.

Утызынчы еллар минем авылыма шактый зур зыян китергән. Бик күп хәлле ир-атлар, дин әһелләре репрессияләнгән. Бөек Ватан сугышы исә безнең авылга да кире кайтмас югалтулар алып килде. Бик күп ир-егетләр яу кырында ятып калдылар. Менә шул чордан Россия башкаласы Мәскәүдән ерак түгел генә урнашкан атаклы татар авылы таркала башлады...

Бүген авыл халкы катнашка әйләнде. Әзидә бик күп руслар яши. Икешәр катлы коммуналкалар төзеп куйдылар. Гамәлдә авыл милли гореф-гадәтләрен, үзенең үзенчәлекле, кабатланмас йөзен югалта тора. Әмма Әзидә һәм аннан читтә яшәүче энтузиастларның тырышлыгы нәтиҗәсендә, зур тарихлы авылның лаеклы киләчәге бар, дигән ышаныч яши. Кайчандыр Үзбәкстанга киткән якташларым Әзигә һәм Ока алды татар авылларына кайта башлады. Бу – татар авылларының яңарышына булыша. ■

Татарстан Президенты

(Р.Миңнехановның биографиясеннән кайбер мәгълүматлар һәм фоторәсемнәр)

Рөстәм Миңнеханов 1957 елның 1 мартында Татарстан АССРның Балык Бистәсе районы Яңа Арыш авылында дөньяга килә.

Рәсемдә: Р.Миңнеханов беренче рәттә иң уртада



Рөстәмгә биш яшь чагында аларның гаиләсе Саба районына күченә: булачак Президентның әтисе Нургали Миңнехан улы Миңнеханов (24.03.1930 – 17.02.2001) 1962 елның 26 гыйнварында Саба урман хуҗалыгына директор итеп билгеләнә (аңа кадәр Яңа Арыш һәм Теләче урманчылыкларында эшләгән Н.Миңнеханов 1990 елгача әлеге вазифаны башкара), әнисе Вәсига Мөбарәк кызы балалар бакчасында тәрбияче булып эшли.

Рөстәм дүртенче сыйныфта укыган вакытта аңа әти-әнисе «Чайка» фотоаппараты сатып алып бирә.

Зөфәр Сафин (Р.Миңнехановның сыйныфташы): *«Дәрес вакытында, сиздермичә генә, укытучыларыбызны кәртечкәгә төшерә идек. Кайвакыт укытучы апа күреп алып: «Миңнеханов!» – дип кисәтү ясый иде. Кәртечкәләрне ясарга урын әллә ни булмаганлыктан, без, Рөстәм белән икәү, пленкаларны карават астына кереп «проявить» итә идек...»*

Рөстәм Миңнеханов сул яктагы өченче партада утырган. Сыйныфташларыннан бер яшькә кечерәк булуына карамастан, яхшы укыган. Укытучылары Рөстәмне аз сүзле, тырыш укучы итеп хәтерләрендә калдырган. «Кулын күтәрмәс, әмма сорасаң, шундук җавап бирә иде...» – ди алар.

Зөфәр Сафин (Р.Миңнехановның сыйныфташы): *«Рөстәм буш вакытларында чаңгыда шуарга ярата иде. Без дә, аңа ияреп, чаңгыны үз иттек. Үзебезнең «Карпат тавы»нда, кулдәге бозлавыкта мәш килә идек инде...»*

Лесхоздагы мәктәпне тәмамлагач, Рөстәм Саба урта мәктәбенә йөреп укый башлый. Ара – 15 чакрым. Бу араны ул кыш көннәрендә чаңгыда уза. Укучы балаларны кайвакыт бөркәүле машина илтеп куя. Әтисенең «УАЗ»игы булуга карамастан, Сабага Рөстәм һәрвакыт башкалар белән бергә йөри.

Хәтмулла Вәкказов, Кукмара районы Байлангар урта мәктәбе директоры (Р.Миңнехановның сабакташы): *«Рөстәм укыганда ук бик мөстәкыйль кеше иде. Лидер булуы шулвакытта ук күренде. Ул, Лесхоздан килгән укучылар белән бергә, 10 «Е» классында укыды, ә мин – 10 «Г»да ...»*

Р.Миңнеханов (Арчада эшләгән вакыты), В.Минһаҗев, И.Шакиров

Әти кочагында. Р.Миңнеханов улы Искәндәр белән

1993-1996 елларда, Биектауда район хакимияте башлыгы булып эшләгәндә, Р.Миңнеханов үзенең күптәнге хыялын тормышка ашыра – автодром төзетә.

«Рөстәм, әнисе янына кайткач, мине күргән саен: «Хәлләр ничек, Алексеич?» – дип исәнләшә. Мин алар классын бик яхшы хәтерлим. Егермеләп бала укыды. Рөстәм ул чакта ук җитди иде. Уку җиңел бирелде аңа. Әгәр сорасаң, дәресен һәрвакыт белә, шундук җавап бирә иде...»

(Немец теле укытучысы Владимир Алексеевич Алексеев (1941-2013) истәлегеннән.)

Р.Миңнеханов хоккей уйнарга ярата. Автоузышларда еш катнаша. Атказанган спорт остасы.

Ике Президент

Р.Н.Миңнеханов 2010 елның 25 мартыннан алып хәзергәчә Татарстан Республикасы Президенты вазифасын башкара.

Безнең мирас №3 март 2017

ГАЛИМҖАН БАРУДИНЫҢ ТУУЫНА 160 ЕЛ

«МӘЧЕТКӘ КАРТАЙГАЧ ЙӨРЕРМЕН...»

(Җәмәгать намазының фазыйләте хакында)

Галимҗан Баруди

Һәркем җәмәгать намазын яхшы, фазыйләтле[1] дип белә. Ләкин ул белүләр белән генә калмаска, ә рәсүлуллаһның, салләллаһу галәйһи вә сәлләм, җәмәгать намазына ни дәрәҗә әһәмият биргәнен дә белергә кирәк. Аның боерганын, сәбәп вә хикмәтләрен, күп тикшермичә, үтәргә кирәк. Рәсүлуллаһның, салләллаһу галәйһи вә сәлләм, кылган һәр эшендә күп хикмәтләр бар. Без аларны тәмам аңлап җитмибез. Аның хикмәтләрен тикшерсәк, ихтимал, ялгышырбыз яки тышын гына аңларбыз. Аның шәригатендә вә боерыкларында булган чын сер вә хикмәтенә тәмам төшенә алмасбыз. Чөнки безнең калебемез төрле шөбһәләр, вәсвәсәләр белән капланган, гөнаһ караңгылыгы белән каралган. Шунлыктан, шәригать серләрен аңлау өчен әзерлегебез ким вә зәгыйфь. Рәсүлуллаһ, салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә, Аллаһның вәхие[2] белән ярдәм ителгән, гөнаһ вә хатадан, вәсвәсә вә шөбһәдән пакь вә мәгъсүм[3] бәндәседер. Шуның өчен без шәригатьтә исбатланган һәркайсы хөкем вә фәрманны кабул итеп, билфигыйль[4] үтәргә вә җиренә китерергә, ул эшнең сер вә хикмәтен рәсүлуллаһка, салләллаһу галәйһи вә сәлләм, тапшырырга тиешлебез.

«Мин рәсүлуллаһның, салләллаһу галәйһи вә сәлләм, өммәтеннән», – дигән кеше үзен рәсүлуллаһка тапшырырга тиеш. Аның тәрбиясенчә тәрбияләнергә, вә аның һидәят вә иршәдләрен[5] бөек ганимәт күреп кабул итәргә вә үтәргә тиеш. Бәни Исраил кебек төрле тәэвилләргә[6] вә төрле шөбһәләргә төшеп мәхрүм булмаска кирәк. Аларның Аллаһ вә рәсүленә (Муса галәйһиссәламгә) иманнары булган. Ләкин алар кайбер авыр хөкемнәрне: *«Моны кем кылып бетерсен яки нигә кирәге бар, яки бу хөкем фәлән максуд өчен, ул эшне башка төрле юнәтербез»*, – дигән булып, кабул итмәгәннәр. Шам диңгезеннән шулкадәр могҗиза күреп чыккач, Аллаһ Тәгалә аларга Сүриядәге бер кәфер кавем белән сугышырга боерган. Әмма алар карышканнар, Аллаһ вә рәсүленә итагать итмәгәннәр, хәзрәти Мусага: *«Үзең вә Раббың барып сугышыгыз, без монда торамыз»*, – дигәннәр.

Ошбу әдәпсезлекләре өчен Аллаһ Тәгалә аларның юлларын авырайткан,

Текстта авторның тел-стиль үзенчәлекләре саклана.

[1] Фазыйләтле – өстенлекле.

[2] Вәхи – берәр фикерне Аллаһ тарафыннан пәйгамбәрнең күңеленә салу.

[3] Мәгъсүм – кимчелексез, гөнаһсыз.

[4] Билфигыйль – чынлап.

[5] Һидәят вә иршәд – туры юлга кертү.

[6] Тәэвил – ялгыш аңлату.

Сугышта да җәмәгать намазын калдырмаганнар. 267 нче Духовщинский җәяүле полкы мөселманнары. 1916 ел

төрле җәфаларга очрап, коры сахрада хәйран хәлдә калганнар. Бабалары Ягъкуб галәйһиссәлам ватаны булган мөкатдәс җиргә бармакчы булсалар да, кырык ел хәйранлык мәгънәсендә булган «Тиһ» аталган сахрада ачлы-туклы тереклек иткәннәр. Аларның моннан башка да пәйгамбәрләренә каршылыклары булган Бәни Исраилнең бу кыйссасы вә башка хәлләре безгә гыйбрәт өчен Коръәндә зикер ителгән. Безгә элекке өммәтләрнең хәлләреннән гыйбрәт алу тиеш. Рәсүлуллаһның, салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сүзләреннән икеләнмичә, бар көчебез белән һәркайсына буйсынырга кирәк. Нәфескә җиңел булганын гына алып, авыр булганын калдырсак, бу пәйгамбәргә иярү вә итагать кылу булмый.

Намаз мәсьәләләрен, бик күп ишетелгән нәрсә инде, дип илтифатсыз калдырырга ярамый. Без намазны никадәр күп сөйләсәк тә, күп ишетсәк тә, һаман аңлап бетә алмыйбыз, тәкрар ишетергә вә мөзакәрә итәргә[7] ихтияҗыбыз була.

Җәмәгать намазының фазыйләте хакында Бохари вә Мөслимдә ошбу хәдис бар: *«Җәмәгать намазы (мәчет җәмәгате) ялгыз укудан егерме җиде дәрәҗә артык».* **Намазны өйдә укыганда төрле тәшвишләр[8] була, дөньяның һәртөрле әсбабы күзеңә күренеп, колагыңа ишетелеп торганда күңелне алардан арулап, чын ихласлык вә хошугълык белән Аллаһыга юнәлү бик авыр, шунлыктан мәчет тышында кеше үзен бөтенләй Аллаһыга тапшырып намаз укый алмый. Әмма мәчеттә җәмәгать белән укылган намаз баягы тәшвишләрдән ерак, дөньядан бөтенләй тышта булганга ихласлы калеб белән укыла. Бу тәҗрибә белән исбатланган.** Күпнең эчендә яхшы күңелле кешеләр булуы да мөмкин. Башка серләрне вә бигрәк тә егерме җиде дәрәҗә булуның серен тәфсилләп аңламасак та, шулкадәр аерма барлыгына тәмам ышанып, җәмәгатьне ганимәт белү[9] тиеш.

Дөнья эшендә файдасы азрак эшне куеп, файдасы күбрәк эшне эшлибез. Инде ахирәт эшендә дә ошбуны ригая кылып[10], нәфескә авыр булса да, һиммәт[11] вә гайрәт белән үтәргә кирәк.

Җәмәгать намазына һәр кеше дәвам итәргә[12] тиеш. Кайбер фәкыйрь кешеләр, вак кына кәсебеннән аерылып, шөгылен

---

7 Мөзакәрә итәргә – фикер алышырга.
8 Тәшвиш – буталу.
9 Ганимәт белү – бәхет дип белү.
10 Ригая кылу – кайгырту.
11 Һиммәт – тырышлык.

куеп, җәмәгать намазына киләләр. **Бай кеше җәмәгать намазына фәкыйрьдән дә артыграк дәвам итәргә тиеш. Байлык әгәр ошбуның кеби эшкә ярдәм итмәсә, аның ни файдасы бар?** Мал үзе максуд биззат[13] нәрсә түгел, бәлки аны бер рәхәтлек көтелгәнлектән кәсеп ителә. Иң зур рәхәтлек – гыйбадәт кылу, Аллаһыга үзеңнең бәндәлегеңне изһар итү[14]. Иң зур файда да ахирәт файдасыдыр. Шуның өчен мал намаз укырга ярдәм итмәсә, аннан көтелгән файда вә рәхәтлек хасил булмаган була.

Байлык Коръән телендә «хәер» дип йөртелә. Шунлыктан аны хәерлелектән чыгармаска кирәк. **Әгәр бай кешенең киләчәктә көткән савабы булмаса, байлыкның файдасы булмый кала.** Дөрес, дөньяда аның бераз заһири[15] рәхәтләре була. Ләкин алар чынлыкта борчу гына. Байлар үгрәнгән җәфа-борчу булганга гына аны аңламыйлар яки мал исереклеге белән аңламыйлар. **Минем хәзердә дә рәхәт йөргән байны күргәнем юк.**

Малны сакларга, арттырырга кирәк. Ләкин Аллаһ әмере килгән вакытта (гыйбадәт вакытларында), аны ташлап, Аллаһ әмеренә буйсынырга кирәк. Дөньяда булган һәрнәрсәгә шәригать телендә «дөнья» дип әйтелми, чын дөнья Аллаһ зикереннән туктата торган нәрсә була. Әгәр берәүнең шөгыле динне саклаудан, дин йолаларын хөрмәт итүдән туктатмаса, бу, чынлыкта, дөнья булмый.

Җәмәгать намазына кеше бик гафләт[16] кылучан. Җәмәгать намазына йөрсә, эшен эшли алмас кеби була. Ләкин җәмәгать намазын укый торып та эшне эшләргә мөмкин. Рәсүлуллаһ, салләллаһу галәйһи вә сәлләм, вә сәхабәләр, ризвануллаһи галәйһим әҗмәгыйн, моны гамәлдә эшләп күрсәткәннәр. Рәсүлуллаһның, салләллаһу галәйһи вә сәлләм, иң якын сәхабәсе булган ибн Мәсгуд разыяллаһу ганһу хәзрәтләре: *«Бер кемсә, кыяматтә Аллаһ Тәгаләгә пакь мөселман булып юлыгасы килсә, кай урында чакырылса да биш вакыт намазга килсен. Аллаһ Тәгалә рәсүлуллаһка, салләллаһу галәйһи вә сәлләм, күңү юлларын күрсәтте, бу биш намаз да күңү юлларыннандыр. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында җәмәгать намазыннан бик ачык монафыйклардан башка кешеләр калмыйлар иде. Хәтта кайбер зәгыйфь, хәлсез кешеләрне култыклап китереп утырталар иде. Әгәр пәйгамбәр юлын тотасыгыз килсә, ошбуга тырышыгыз»*,– дигән.

Госман разыяллаһу ганһу хәзрәтләре рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләреннән бу хәдисне риваять итә: *«Берәү ясигъны җәмәгать берлә укыса, ярты төн йокламый гыйбадәт берлә үткәрү савабына ирешә. Әгәр берәү иртә намазын җәмәгать берлә укыса, бөтен төн гыйбадәт берлә үткәрү савабына ирешәдер. (Бер риваятьтә иртә намаз берлә ясигъ намазының икесен бергә укыган кешегә бөтен төнне гыйбадәт берлә үткәрү савабы булыр, дип тәфсир ителгән)»*.

Аллаһ Тәгалә хәбибе[17] Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәссәлам өммәтенә бик күп җиңеллекләр кылган. Шул җөмләдән бөтен кичне гыйбадәт белән үткәрүне санарга булыр. Чөнки кичне йокламый гыйбадәт кылып үткәрү, бик мөшкел булуы өстенә, сихәткә дә зарарлы булырга мөмкин. Шуның өчен Аллаһ Тәгалә аның урынына шуның савабына бәрабәр булган икенче нәрсәне өйрәткән. Менә Аллаһ тарафыннан безгә нинди зур бәшарәт[18] вә рәхмәт! Без моның кадерен белергә тиешле. Әгәр без фәкать йокы бүләсе килмәгәннән ясигъ яки иртә намазын җәмәгать берлә укымасак, килешәме? Аллаһ вә рәсүле савапларын сөйләгән җәмәгать намазына фәкать нәфес теләгемез өчен килми калсак, акыллы кеше булабызмы? Иртә намазы инде тагын да савабы күбрәк вакытка туры килә. Йокы туйдыру – дөньяда максуд нәрсә түгел. Намаздан соң да йокларга мөмкин.

Рәсүлуллаһ, салләллаһу галәйһи вә

[12] Дәвам итәргә – килергә.
[13] Биззат – турыдан-туры.
[14] Изһар итү – ачып салу.
[15] Заһири – тышкы.
[16] Гафләт – игътибарсызлык.
[17] Хәбиб – сөекле.
[18] Бәшарәт – шатлык.

сәлләм: *«Әгәр ясигъ берлә иртә намазында никадәр әҗер вә савап барлыгын белсәләр, шуыша-шуыша килерләр иде»*, – дип, безнең хәлләребезгә карап әйткән кеби, Сахих Бохари, Мөслим, Муатта Мәлик кеби могтәбәр хәдис китапларында да Әбу Һурайра разыяллаһу ганһу аркылы риваять ителгән.

Халык җәй көннәрендә ясигъ берлә иртә намазга ялкаулана, чөнки мәшәкатьлерәк була, йокы калдырып йөрергә кирәк. Ләкин бу мәшәкать безгә зарар түгел, бәлки файда гына. Кеше дөньяви файдасы өчен никадәр мәшәкать чигә, йокысын калдыра, ашамый-эчми тора, сәфәрләргә йөри. Дини файда өчен моннан артык тырышмак ләзем, чөнки Аллаһ Тәгалә һәрбер гыйбадәткә кыямәт көнендә савап бирәчәк дип вәгъдә кыла. Шулай була торып та, без моңа тырышмасак, бик зур оят булыр. Рәсүлуллаһ заманында Мәдинәдә дә төннең кыска вакытлары булгалаган. Шулай була торып та, рәсүлуллаһ, салләллаһу галәйһи вә сәлләм, заманында ясигъ вә иртә намазларында җәмәгатьтән калмаганнар.

Җәмәгать намазы картларга гына хас түгел. Яшьләргә дә җәмәгать намазына мәчеткә барырга тырышырга кирәк. Аларга савабы күбрәк булыр. **Мәчеткә картайгач йөрермен, дигән сүзләр – шайтан сабаклары. Яшьлектә гадәтләнмәгән эшне картайгач кылу бик мөшкел була, бигрәк тә картайгач куәт бетә. Куәт бар чагында кыла алмаган гыйбадәтне куәт беткәч ничек кылырга кирәк?** Картайгач кыла алмаганда яшьлектә ни өчен кылмадым икән, дип үкенергә мөмкин. Кыямәттә бигрәк тә үкенечле булыр. Шуның өчен кыямәт яхшыларга да, яманнарга да үкенеч көне, дип сыйфатланган. Яманнарга үкенечлеге мәгълүм. Яхшылар исә, күбрәк гыйбадәт кыласым калган, аз кылганмын, дип үкенерләр икән.

Җәмәгать намазы хосусан[19] мондый кыска төннәрдә бик ганимәт эш. Моңар һәр сыйныф халык тырышмак кирәк. Чөнки Аллаһ өндәүчесе (мөәзин) манарага менә, һичкемнән курыкмый азан әйтә. Кешенең мөселманлыгын исенә төшереп, котылу юлына ашыгыгыз, намазга ашыгыгыз, дип кычкыра. Калебендә мөселманлык хисе булган адәм шуны ишетә торып, намаз укып, калебен рәхәтләндерми йоклап ята алмас, иртәнге намаз вакытына азан тавышын ишетер өчен генә дә торырлык бар. Мөәзин: *«Килегез намазга!* – дип әйткәндә, – *Син, мөселман, ислам динендә намаз бар, иман бар!»* – дип кычкырган вакытта, син, йоклап ят яки җәмәгать намазына килми тиз генә укып, йокла. Бу ислам диненә шөкерана булмый, бәлки шөкеранасызлык була. Моның нәтиҗәсеннән курку тиешле.

Аллаһ өчен йокыны бүлергә кирәк, аннан бер-ике сәгать эшең кичексә кичегер, әмма бәрәкәтне бирүче Аллаһ Тәгалә булганга, аз эшкә күп бәрәкәт бирсә, гаҗәп түгелдер. Дин әдәпләрен ригая иткән кешеләргә бәрәкәт күп булган.

Безнең хәлебез бик кызганыч. Иртә намазында бер саф халык булып җитми, ясигъ намазында да кеше бик аз була. Җитмәсә мөәзинне, тизрәк азан әйт, дип ашыктыралар. Җәмәгать намазы ваҗиб[20], бер фикердә сөннәт мөәккәдә[21]. Төннең кыскалыгы ваҗибне яки шуңа якын сөннәт мөәккәдәне калдырырга гозер[22] түгелдер. *«Ясигъ берлә иртә намазындагы хәсиятне белсәләр иде, шуыша-шуыша килерләр иде»*, – пәйгамбәрнең мөбарәк авызыннан чыккан бик зур вә гыйбрәтле сүз. Икенче бер хәдистә рәсүлуллаһ: *«Монафыйкларга ясигъ белән иртә намазыннан да авыр намаз юк»*, – дип әйткән (сахих хәдис). Монафыйклар дингә чын ихласлары булмаган адәмнәр була. Бу инде артык сүз, моннан куркырга кирәк.

Әд-дин вәл-әдәб. – 1915. – №12.

*Текстны басмага **Фатих Хәбиб** әзерләде.* ■

[19] Хосусан – аеруча.
[20] Ваҗиб – үтәлүе мәҗбүри гамәл.
[21] Сөннәт мөәккәдә – көчле сөннәт.
[22] Гозер – сылтау.

Безнең мирас №3 март 2017

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ*

Габдерәшит Ибраһимов

БОРЫНГЫ БОХАРА

БОХАРАНЫҢ ЭЛЕККЕГЕ ДАНЫ, ДӘРӘҖӘСЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕ ИДАРӘСЕ

Мин Ташкенттан Бохарага килдем. Бу шәһәр элек-электән гыйлем үзәге булган, «шәриф», ягъни «изге» дигән данлыклы исем казанган. Шуңа күрә, Бохара-йи Шәриф дип аталып йөртелә.

Бохара, дөрестән дә, кайчандыр изге дип саналырга лаек төбәк булган. Әгәр Ислам дөньясының күренекле шәхесләре белән бәйле тарихына күз салсак, мөхәддисләрнең, ягъни хәдис белгечләренең имамы Мөхәммәт бине Исмәгыйль әл-Бохари[1], Казый Бәйзави[2] һәм башка заһир, ягъни Коръән-е Кәримнең ачык мәгънәләре белән хөкемнәрен яхшы белүче һәм батын, ягъни Коръән-е Кәримнең тирән мәгънәләре белән серләрен яхшы белүче галимнәрдән күп кенә бөек затның исемнәрен укырбыз. Мавәрәүннәһер гыйлем үзәге дәрәҗәсен казанган бу шәһәр, кайчандыр Бохара-йи Шәриф исеменә, Ислам солтанаты һәм дини гыйлем чишмәсе һәм башка шундый югары сыйфатларга ия булган.

Бүгенге көндә бу Бохараның хәлторышы ничек, нәрсәләргә ия икән соң? Хәзер дә Бохара – башкалардан аерылып тора торган Ислам әмирлеге, ике миллионга якын кеше яши торган төбәк. Ишетеп кенә белүчеләр, ихтимал, аны мөстәкыйль ил дип тә уйлыйлардыр. Дөрестән дә, Бохара хакимияте мөстәкыйль дәүләткә бик охшаган: биредә хөкүмәт башлыгы Габделәхәт хан бүгенге көндә дә бердәнбер әмир. Аңа бу хакта сорау бирелсә, аның үзүзен әмир дип белгәнлеге аңлашылыр иде. Ләкин ул да: «Мин – бу дәүләтнең хуҗасы», – дип әйтә алмас. Чынбарлыкта Габделәхәт хан – рус наместнигы, ягъни җирле идарә башлыгы, рус генералы, Бохара шәһәренә керә дә алмый, шәһәрдән 20-30 километр читтә, Кәрмәнә дигән авылда яши. Инде менә егерме еллап, Бохарадагы хөкүмәт сарае Арк буш тора. Шул рәвешле, бүген «Бохарада әмирнең исеме бар, җисеме юк», дияргә мөмкин һәм бу дөреслеккә туры килә, дип уйлыйм.

Хәзерге вакытта Бохарада башкарма эшләре Кош Бәге исемле бер түрәнең кулында һәм кануннлаштырылган гадәтләр буенча алып барыла. Шәригать белән бәйле эшләр исә, фикъһ, ягъни Ислам хокукы китапларына туры китереп эш итү шарты белән Казый Гәлян дигән кешенең идарәсенә тапшырылган. Моннан тыш, канунлаштырылган гадәтләргә бәйле һәм мөлек идарәсенә охшаш тагын бер түрәлек вазифасы бар. Рәис һәм мөхтәсиб дип атап йөртелә торган бу түрә, чикләү, шелтә белдерү, җәзага тарту кебек гамәлләрне башкарырга хокуклы. Үзе теләсә никадәр шәригатькә каршы гамәлләр кылса да – зыян юк, әмма башка берәүдә шәригатькә каршы бер хәл күрсә, шунда ук аны яткызып суктыра, кыйната.

Бу «дарб», ягъни сугу, кыйнауны да шәригатькә туры китерелмәгән, дип әйтеп булмый. «Дарб» гамәлен

Дәвамы. Башы журналның 1 нче, 2 нче (2017) саннарында.

*Текстта авторның тел-стиль үзенчәлекләре тулысы белән саклана.

[1] Мөхәммәт ибн-Исмәгыйль Әл-Бохари (810-869) – танылган хәдис белгече (Türk Ansiklopedisi. MEB, İstanbul, 1989, Cilt 8. – S.349-350).

[2] Казый Бәйзави (650/685 - 691) – Коръән-е Кәримгә шәрехләр биргән Ислам дине белгече (Türk Ansiklopedisi. MEB, İstanbul, 1989, Cilt 6. – S.300-301).

Баһаветдин мәдрәсәсе. Бохара, 1905 ел

башкаручы кеше таяк тоткан кулын иңбашына кадәр генә күтәреп суга ала, кулының терсәктән югарыгы өлеше хәрәкәтләнмәскә тиеш. Ләкин «дәррә» дип аталган бу суктыру таягының авырлыгы, Фәһим (Паша)ның Бурса[3] музеенда саклана торган, авырлыгы дүрт килодан артып киткән бастон таягын хәтерләтә. Менә бу гамәлләрнең һәммәсе гаделлек буларак танытып башкарыла.

Бохара хакимияте менә шулардан гыйбарәт. Губернада һәр өч түрәлекнең дә вәкилләре бар, алар да үз төбәкләрендә мөстәкыйль рәвештә дип әйтерлек эш алып баралар. Бохара һәм аның төбәкләрендә шәригать буенча хөкемгә тартуга руслар берничек тә комачау итмиләр. Биредә, кирәк дип табылса, шәригатьчә кысас, ягъни җинаятьтә түләшү (мәсәлән, кыйнаган өчен кыйнау, үтергән өчен үтерү һ.б.) юлы да кулланылырга мөмкин.

ИГЕНЧЕЛЕК, ХАЙВАН ҮРЧЕТҮ ҺӘМ СӘҮДӘГӘРЛЕК

Бохарада кырлар гаять дәрәҗәдә уңдырышлы. Бүгенге көндә Бохарада игеннең бөтен төрләре дә диярлек игелә. Хайваннар, бигрәк тә куй үрчетү алга киткән. Язын бәрән тиресе сәүдәсе белән зур эшләр башкарыла. Бәрән тиресе сату эше Аурупада да бик мәшһүр. Бәрән туа, аны ун-унбиш көннән суеп, тиресен туныйлар. Шуннан да артык кала алмый, чөнки тиренең ялтыравыгы, бөдрәлеге бетә башлый. Бу тире бик кыйммәт йөри. Бәясе ун сумнан егерме биш сумга кадәр җитәргә мөмкин. Бигрәк тә хатын-кызлар өчен зиннәтле кием дип санала. Бу тирене каракүл дип атыйлар, ул бары тик Бохарада һәм Әфганстанда гына җитештерелә. Дөньяның башка бер генә җирендә дә мондый тире эшләнми. Аурупа илләрендә бервакытлар җитештерергә тырышып карадылар,

---

[3] Фәһим Паша (1873-1908) – Госманлы солтаны Абдулхәмид IIнең ярдәмчесе һәм жандарм башлыгы. Илчеләрнең шикаяте сәбәпле, Бурса шәһәренә сөрелә. Беркадәр вакыттан соң үтерелә. (Türk Ansiklopedisi. MEB, İstanbul, 1989, Cilt 16. – S.198).)

ләкин барып чыкмады. Анадолудагы ангора кәҗәсе тиресе яисә мамыгы кебек, каракүлне дә табигать махсус бу җирләргә бүлеп биргән, атаган. Бер еллык каракүл сәүдәсеннән алынган табыш биш миллион сумга җитәргә мөмкин. Әмирнең генә дә каракүл сәүдәсе бер миллион сумнан артып китә. Соңгы елларда татарлар каракүлне Америкага ук алып барып бик зур сәүдә итәләр. Мамык җитештереп сату да гаять дәрәҗәдә алга киткән. Сәүдәнең бу ике төрендә миллионнар әйләнештә йөри.

ГАЛИМНӘР, ШӘКЕРТЛӘР, МӘДРӘСӘ ҺӘМ БЕЛЕМ АЛУ

Бохарадагы галимнәрнең саны мәгълүм түгел, ләкин ике йөзгә якын мәдрәсә һәм егерме җиде меңгә якын шәкерт булуы билгеле. Бик борынгы һәм бик зур мәдрәсә биналары бар. Мәдрәсә биналары тәртиптә тотыла, шуңа күрә вакыфлар да бик күп. Мәдрәсәләр – Бохараның иң мөһим табыш чыганагы. Мәдрәсә бүлмәләрендә яшәүчеләр шәкертләр булса да, боларның төп хуҗалары – бай кешеләр.

Хәтта Казый Гәлян һәм мөфтиләр дә зур мәдрәсәләрнең торак бүлмәләрен мал иткәннәр, аларның вакыф акчасын ашап яталар. Мескен шәкерт буп-буш бүлмәдә яшәү мөмкинлегенә сөенә (әгәр бушлай тора алса). Кайбер мәдрәсәләр бушлай да яшәтмиләр, бүлмәнең вакыф акчасын да ашыйлар, шәкертләрдән дә бераз акча түләтәләр. Бер дә булмаса, шәкертләрне үз дәресләренә йөрергә мәҗбүр итәләр. Кайбер бичара шәкертләр, бүлмә тоту өчен, җаһил мөдәррис-укытучылар янында гомерләрен заяга уздырырга мәҗбүр булалар.

Мәдрәсәләр өчен чынлап та хуплауга һәм зурлауга лаек вакыфлар оештырылган. Ләкин шунысы кызганыч: алар вакыф ителгәннең файдасына тотылмый, байлар кесәсен өзлексез калынайту чарасы булып тора. Мәдрәсәләр һәрвакыт вакыф мәдрәсәсе булып кала, вакыфлары һәм рәсми язулары – гомерлек, безнең

Соңгы әмир. Бохара

Мәккә-и Мөкәррәмә харәм-и шәриф (Кәгъбә) тирәсендәге мәдрәсәләр кебек бөтенләе белән Аллаһы ризалыгы өчен булган милек шәкеленә кертелмәгән.

Бохарада вакыф һәрвакыт вакыф булып кала. Әмма ләкин мәдрәсә бүлмәләре, сатылган вакытта, мал-мөлкәт итеп сатылмый, бары тик аның интифасы, ягъни китерәчәк табышы гына сатыла. Башка төрле итеп әйтсәк, бүлмәне сатып алучы чынбарлыкта бүлмәгә хуҗа түгел, бары тик бу бүлмәнең берьеллык вакыф керемен генә хуҗа булып чыга, бары тик вакыфын гына ала.

Бохарада мәдрәсәләр күп булуның сәбәбе нәрсәдә икән соң? Мин моңа җавапны тиз генә уйлап табалмадым. Ләкин бераздан шундый катгый фикергә килдем: күрсәң-баксаң, Бохарада һәм бөтен Төркестанда байларның иң игелекле һәм саваплы эше – мәдрәсә салу икән. Бер кеше баеса, һичшиксез, үз мөмкинлеге дәрәҗәсендә бер мәдрәсә салдыра. Акча таба, табыш ала башлаган һәрбер кеше, эшенең нәтиҗәсе итеп,

Баһаветдин мәдрәсәсенең гомуми күренеше. Бохара. 1905 ел

бер бина салуны күңеленә беркетеп куя. Байлар, акчалы кешеләр генә түгел, һөнәрчеләр дә шулай эшли торган булган, хәзер дә шулай. Мәдрәсәләр 15-20 бүлмәле, 40-50 бүлмәле, бөтенләе белән бүлмәләрдән торган биналар рәвешендә дә салына. Хәтта 140-150 бүлмәле мәдрәсәләр дә бар. Хөкүмәт исә, мондый мәдрәсә салырга рөхсәт бирер өчен, мәдрәсәнең озын гомерле булуын һәм анда яшәячәк шәкертләрнең көн күрүен тәэмин итүне дә кирәк дип саный. Шул рәвешле, кем дә булса мәдрәсә салдыра икән, мәдрәсәнең һәрбер бүлмәсенә ким дигәндә, 1 түгәрәк икмәк китерәчәк керем дә вакыф итә. Бу хәл бүгенге көнгә кадәр шулай үзгәрешсез дәвам итеп килгән.

Мин шундыйлардан Гүрбан (кабер казучы) мәдрәсәсен барып күрдем. Бу кеше кабер казучы булып эшләп тапкан акчасына 20 бүлмәле мәдрәсә салдырган. Кечкенә генә булса да, бу мәдрәсә бик тәртипле, җыйнак иде. Хуҗасы белән күрешеп сөйләштем. «Мин бу көнгә кадәр эшләдем, бик күп мәет күмдем, җир астына салдым, ләкин шуннан соң да аларның [рухларының] җир өстендә калуларын, югары үрләүләрен өмет итеп, тапкан акчама бу мәдрәсәне салдырдым», – диде.

Мондый фикер Бохара халкында әлегәчә яшәп килә. Ләкин Бохара галимнәре – боларның капма-каршысы. Укыту ысулы бик начар. Шәкертләр бер китапның кереш өлешен 5 ел буе укып өйрәнәләр, 20-30 ел мәдрәсә бүлмәсендә утырып, бөтен гомерләрен гыйлем алу чарасы булган телне өйрәнеп үткәрсәләр дә, укуны бетереп, ике кәлимәне бергә кушып гарәпчә сөйләшә алмаган кебек үк, бер юл гарәпчә язу да яза алмыйлар. Укыту-өйрәтү ысуллары йөрәк әрнетерлек хәлдә. Бөтен мәдрәсәләр, бөтен Бохара шәкертләре бу тоташ өметсезлек эчендә болай диләр: «Бүлмәләребездә утырып заяга үткәргән гомеребезнең хисабын кыямәт көнендә вакыф хуҗалары каршысында ничек бирерсез икән?»

Бохара голәмәсе һәм шәкертләре арасында уяну, күтәрелеш бөтенләй дә юк

Безнең мирас №3 март 2017

түгел. Яшь буын мөдәррис-укытучылар элекке буыннар кылган гамәлләрне фикер үлчәвенә салып үлчи башлаган инде. Бу хәлләрдән соң уяныруар дигән өмет бар. Кайбер мәдрәсәләрдә бүгеннән үк омтылыш ясарга кирәклеген аңлаган кешеләр дә очрый. Тик шәкертләргә гомумән хас булган сүлпәнлек, иренчәклек кинәт кенә юкка чыкмас шул. Галим-голәмәләрдән кайбер олы затлар белән дә күрешеп сөйләштем. Әлеге дә баягы шул Казый Гәлян белән дә берничә тапкыр фикер алыштык. Ул, укыту ысулын үзгәртү зарурлыгын бик үк кабул итмәсә дә, шәкертләр өчен һич кирәге булмаган кайбер таләпләрне юкка чыгару белән килешкәнлеген белдерде. Мәсәлән, ифтитах, ягъни ачылыш дип аталган, шәкертләрнең җанына тия торган бер бәла бар. Бу – мөдәррисукытучылар мәнфәгате өчен уйлап чыгарылган «дәрес ачу» ысулы: һәр уку елы тәмамланганда, киләчәк ел өчен «ачылыш дәресе» үткәрелә. Моның исә тәртибе түбәндәгечә:

Ачылыш дәресенә керергә теләгән шәкерт төрле тәм-том белән килә – болар ясалма һәм файдасыз эшләр, чыгымнар; аннары мөдәррис җәнапларына бер җөббә – шәрәф киеме – кидерелә, акча җыеп бирелә.

Кыскача әйтсәк, бу – шәкертнең көче җитмәслек салым кебек бернәрсә, фарыз дәрәҗәсендә үтәлә. Инде мәрхүм Казый Гәлян менә боларның кирәксез авырлык икәнлеген таный, шулай булса да, бөтенләй юкка чыгуын да теләми, җөббә алуны казаныш дип саный иде.

ТЕЛӘНЧЕЛЕК

Бохарада күңелгә хуш килерлек бер күренеш бар: ул да булса шәһәр эчендә теләнчеләрнең булмавы. Бохара халкы тулаем алганда һөнәрчеләрдән һәм сәүдәгәрләрдән гыйбарәт. Кая гына барсалар да, кәсеп итәләр, сәүдә белән шөгыльләнәләр. Кайбер хаҗи калдыгы теләнчеләр очраса да, алар – Кытай Төркестаныннан килгән кешеләр. Бохара халкы арасыннан чыккан теләнче бөтенләй юк.

БОРЫНГЫ ӘСӘРЛӘР

Бохарада борынгы әсәрләр дип атарга, барып карарга лаек нәрсәләр – әлбәттә, мәчетләр һәм мәдрәсәләр. Биредә Тимур чорыннан калган туплар һәм борынгы сугыш кораллары саклаган – гаҗәпләнеп карарлык. Болардан башка, тарихи Арк эчендә урнашкан борынгы китаплар келәте бар. Китапларның һәммәсе дә – моннан 800-1000 ел элек язылган кулъязма әсәрләр. Алар арасында бик нәфис китаплардан башка тагын шактый санда руб-и мүҗәййәб такталары, ягъни әйләнәнең дүрттән бер өлеше төшерелгән такталар да бар.

ТЕЛ

Бохара халкын тулаем таҗиклар тәшкил итә. Рәсми телләре – фарсыча, халыкның күпчелек өлеше төркичә дә белә.

ЯШӘЕШ

Бөтен шәрык халкында булган кебек, кунакчыллык һәм кирәгеннән артык тыйнаклык, дөресрәге ясалмалылык, икейөзлелек күрсәтү боларда да бар. Аеруча, тәксез, ягъни әле сакалы-мыегы чыкмаган яшь егетләргә хөрмәт белән карау гыйбадәт дәрәҗәсенә җиткән. Тагын башка бик күп күренешләр дә бар, язарга теләсәң, каләм җавапка тартылыр. Әхлакый бозыклык, кеше үтерү һәм башка шундыйлар гадәти хәлгә әйләнгән.

ГАСКӘРИ ХЕЗМӘТ

Бохарада гаскәри хезмәт дип атарлык берни юк, дисәм дә, дөреслеккә туры килер. «Сипаһи», ягъни атлы гаскәр дип йөртелә торган бер төркем бар, ләкин болары да кышлакларда эшсез яталар, ашыйлар-эчәләр, берни белән дә шөгыльләнмиләр. Бу халык төркеме эчендә 8 яшьлек малайдан алып 80 яшьлек бабайга кадәр бар. Чөнки канун буенча, гаскәргә бер тапкыр кергән кеше аннан чыга алмый. Араларын-

да сукырлар, аксаклар, бөкреләр дә аз түгел. Ләкин шул ук вакытта, үзләренә күрә башлыклары, офицерлары да бар. Дөресен генә әйткәндә, Бохара гаскәре (сугышка әзерлекле гаскәриләрдән түгел) иминлек һәм тыныч тормыш гаскәриләреннән оешкан.

Бохарада гаскәргә алыну гомуми кагыйдәгә нигезләнеп башкарылмый. Бер кеше берәр төрле җинаять эшләсә, моның өчен аңа гаскәргә җибәрү аша җәза бирелә. Гаҗәеп сәер хәлләр дә бар. Мәсәлән, һич гөнаһсыз бер кешенең капка төбендә ике азгын талашып сугышса, «Без бу кешенең улы өчен сугыштык», дисә, бичараның улын гаскәргә алалар. Мондый начар гадәтләр аркасында, гаепсез, гөнаһсыз кешеләр кимсетелә, хурлана. Бохарада бу эш белән көн күрүче юлдан язган әхлаксызлар бар, гаепсез кешеләрне куркытып, янап, алардан акча каералар.

БОХАРА АКЧАСЫ

Бохараның үзенең акчасы – «сиккә»се, алтын, көмеш һәм вак акчалары бар. Вак акчага «пул-ы сиях», ягъни кара акча диләр, кыйммәте якынча 1 акча. Әйләнештә йөргән төп акча шул «пул-ы сиях». Моның басылган акча дип әйтерлек бер җире дә юк, бары тик коелган бронза кисәгеннән генә гыйбарәт.

Менә шул акча мәсьәләсе ничек кенә булса да үзенә бертөрле бәйсезлек, мөстәкыйльлек күрсәткече булып тора. Руслар бу акчаны әйләнештән чыгарыр өчен шактый тырышып караганнар, ләкин ни сәбәпледер, моңа ирешә алмаганнар. Бу хәлдән соң руслар Бохара өчен аерым бер кәгазь акча бастырырга теләсәләр дә, әмирлек мөмкинлек бирмәгән, тегеләре артык басым ясамаганнар.

Бохара әмирлеге менә шул каршылык күрсәтү, үз сүзен итү булып күренгән хәлләр аркасында, үзен бәйсез итеп тоя, мөстәкыйль дип уйлый. Ләкин чынбарлыкта Бохараның бәйсезлеге – Бохарада рус түрәләр юк, үз көннәрен үзләре күрәләр дигән сүз генә. Рус түрәләре һәм рус гаскәре Бохарадан 9 километр ераклыктагы Каган дигән җирдә урнашып яши, кирәк дип табылганда шунда ук бер рус түрә шәһәргә килә, ни теләсә – шуны эшли, һәр эшкә катыша.

БОХАРАНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ

Бохара хөкүмәте бүгенге көндә дә, киләчәктә дә, бер генә яктан да, хәерле булыр, дип өмет итә торган хәлдә түгел. Ни Бохара халкы өчен, ни башка мөселманнар өчен – ни динияты, ни кешелек күзлегеннән чыгып караганда – бер файда да китерергә охшамаган. Әмир исемен генә йөртүче, чынлыкта исә рус хезмәтчесе Габделәхәт ханның мин-минлегенә хезмәт итеп, Бохара халкының табигый сәләтен юк итүдән башка эшкә ярамаган бәхетсез, залим хөкүмәт бар, ул да Бохара халкын талап кулга төшерелгән акчаларны Петербургка җибәреп тору чарасы гына. Бохара әмире шулкадәр «галиҗәнап» зат ки, руслар кайда да булса бер эшкә тотынсалар, шунда ук җитешә: Балтыйк диңгезендә корыч тышлыклы бер сугыш корабле тулысынча әмир җибәргән акчага төзелгән, япон-рус сугышында әмир русларга биш миллион сум акча белән ярдәм күрсәткән, дип сөйлиләр.

Гыйлем эстәүче шәкертләр белән дә күп тапкырлар күрешеп сөйләштем, алардагы табигый сәләтне сынап карадым. Бохара шәкертләренең бер өлеше шактый сәләтле, шуңа күрә, кирәк булганда омтылышны, максатны әйтеп аңлатырга мөмкин. Мин әле Бохарада идем, Русиянең Кагандагы түрәсе Бохараның кайбер сарайларында тикшерү башлатты. Ул көнне шәкертләр арасында зарарлы язу бастырып таратылган, кайбер урамнарда халыкны рухландырырлык мәкаләләр язып ябыштырылган, диделәр. Бу хәбәрләрнең халык арасында киң таралуы минем Бохарадан китеп баруыма сәбәп булды.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе.* ■

Безнең мирас №3 март 2017

Зәкиулла Минһаҗев: «Аналарыбыз яшәү көчен каян алган?!»

(Монологны журналга әзерләүче һәм кереш сүз авторы – язучы Юныс Сафиулла)

Алан авылы чагыштырмача яшь авыл булган, күрәсең, бик бай авыллардан саналмаган, халкы да азрак булган, шуңададыр, анда яшелчә, җиләк-җимеш белән шөгыльләнүчеләр бөтенләй булмаган диярлек. Табигый, моңарчы мондый байлыкны күрмәгән яшь-җилкенчәк бакчага агыла. Сыйланып кына калсалар бер хәл, алмагачларны ботарлап, помидор-кыярларны сабагы-ние белән өстерәп чыгучылары да була. Ямьсезләнеп йөрми бакча ияләре, балаларга сабак биргән чакта шунда берочтан яшелчә үрчетү серләренә дә төшендерергә тырышалар. Аларда иң зур кайгы – бала кайгысы. 1921 елны туган Шемсемөхәммәд тә, 1923 елны туган Габделкави да бер-бер артлы үлеп китә. Моңа ил өстендә котырган ачлыклар да сәбәпче булгандыр. Тора-бара тормыш берникадәр җайлангандай итә. Хәзрәт белән абыстайның 1924 елны Мәсгуть һәм 1926 елны Әнәс исемле уллары туа. 1929 елны күптән көткән кыз-бала – минем булачак әнием Тәүхидә дә дөньяга аваз сала. Әмма шул елның кара көзендә күршеләренең: «Каюм мулла Сираҗи белән мунчада тун бөркәнеп колхозны таркату турында сөйләшә», – дигән доносы буенча бабамны кулга алалар.

Әти ягыннан булган бабам Минһаҗетдинның сөйләвенчә, бу доносның нигезендә аның абыйсы Сираҗетдиннән үч алу яткан. Әле революциягә кадәр үк авылның Гали атлы кешесе, Фәхретдин малайлары урманнан агач урлыйлар, дип, урядникка әләк язуы тапшыра. Ә асылда агач дигәннәре агачның үзе түгел, нибары кисеп ташланган очлары, ботак-чатаклары гына була. Шушы гадел булмаган шикаять аркасында тавыш чыгып, эш зурга китә һәм Сираҗи доносчы Галигә кул күтәрә. Революция түнтәрелешеннән соң инде Галинең улы Мөхи (Мөхетдин), комсомол ячейкасы башында торуыннан файдаланып, әтисе өчен кайтару нияте белән Хәлиулланың тол хатынына әйтеп, Сираҗи өстеннән әләк язуы яздырып ала. Шуның буенча Сираҗины да кулга алдырта. Ары таба Сираҗи белән ни булганы билгесез, ул эзсез югала.

Суд буласы көнне Фатыйма әбием, дүрт айлык сабыен күтәргән хәлдә, Аланнан 12 чакрым ераклыктагы Яңгул авылына чыгып китә. Бала елап комачаулар, дип, аны судка кертмиләр. Фатыйма абыстай, баласын күрше өйләрнең берсендә калдырып, кире килә. Татар Баш Судының күчмә сессиясе Габделкаюм хәзрәтне, РСФСР ҖКның 58-10 2.б. статьясы нигезендә, атарга хөкем итә. Суд карарыннан шашынып калган ир белән хатын бер-беренә ни әйтергә дә белмиләр. Өзгәләнгән Фатыймасын ничек тә тынычландырырга тырышкан Габделкаюм: «Үзеңне сакла, кулыңда өч сабый, мондый хәлеңдә син инде алар-

---
Ахыры. Башы журналның быелгы 2 нче санында

Фатыйма абыстай (уңнан беренче басып тора) туганнары белән.
Уртада – сеңлесе Фагыйләнең ире Гомәр, икенче рәттә сулдан икенче басып тора – Гомәр жизнинең икенче хатыны Бибинур. 60 нчы еллар

ны саклап та кала алмассың, ә нишли аласың соң, үлсәләр дә үзеңне саклый күр, үлгәннәр артыннан үләргә ярамый, Фатыймам», – ди.

Фатыйма, судтан чыккач, кая барып бәрелергә белми. Баласы искә төшеп, ниндидер өйгә адашып керә дә бишектә яткан сабыйны күтәреп чыгып китә. Баланың анасы, Фатыймага: «Абыстай, бу синең балаң түгел, синекесе, әнә, безгә каршы өйдә», – дип, судка керер алдыннан дүрт айлык Тәүхидәсен кертеп калдырган өйне күрсәтә.

Шул вакыйгадан соң күп тә үтми, Фатыйма абыстайны зәмһәрир салкын көнне өч баласы белән өеннән мунчага чыгарга мәҗбүр итәләр. Әби, балалары бик туңгач, мунчага морҗалы мич әмәлләп куя. Мулла белән абыйстайның 1918 елны Мирҗәмнән күчеп килгән әлеге өйләренә колхоз идарәсе урнаша. Хуҗасының бар булган әйберен бер бүлмәгә бикләп куялар. Ачкычның берсе – аңарда, икенчесе – колхоз рәисе кулында булгач, кемнәр генә анда кереп йөрмәгәндер, әйберләренең яртысы югала. Берочтан аларның мүкләк булса да сөтне бик мулдан биргәнгә авылда беренче саналган сыерын да, «зингер» тегү машинасын да алалар.

Мүкләк сыерны, мулла өстеннән донос язганы өчен, ярлылар һәм тол хатыннар комитеты әгъзасы булган мәрхүм Хәлиулла хатынына бирәләр. Аның сыерга ашатырлык печәне дә, кертеп ябарга рәтле каралтысы да булмый. Җитмәсә, гомерендә сыер терлеге асрамагач, ул аны рәтләп карый да, сава да алмый. Сыер күз алдында бетәшә. Авыл советы рәисе авыруга сабышкан, күтәрәмгә калып барган сыерны Фатыймага кире кайтарып, аякка бастыра күр инде моны, ди. Сыер рәтләнеп җитүгә, әлеге тол хатын әләк язуының яңасын әмәлли. Янәсе, сыерны миннән алып, кабат кулак хатынына кайтарып бирделәр. Авыл советы рәисенә тикшерүче алдында, сыер бик ябыккан иде, без аны, иткә тапшырганчы ашатып торсын, дип кенә биреп тордык, дип акланырга туры килә. Сыерны иткә тапшырырга дигән карар чыгарылган көнне колхоз рәисе Гаяз Юнысов килеп, Фатыйма сөтлебикәсен үзенең кәҗә хәтле генә кысыр сыерына алмаштырып китә. Яңа хуҗалар мул сөтле мүкләктән әле озак еллар рәхәт күрәләр.

Менә чират өч сабыйның тилмереп карап торганы – кәҗәгә дә җитә. Сөт кенә түгел, балаларга төрле кием-салымнар бәйләрлек мамык та бирүче кәҗәне иткә тапшырырга кушалар. Кайгылы уйлары йокы бирмәгән Фатыйма җиде төн уртасында каралтыдан ишетелгән шаушуның сәбәбен белергә дип чыга. Ай яктысы су кебек. Шул яктыда авылның икенче бер ярлысының мамык кәҗәсен өстерәп чыгып килүен күрә ул. Г. исемле бу кеше абыстайның күзләренә туры карый алмый читкә борыла. Аның өчен оялган Фатыйма да йөзен читкә бора. Шулчакта абзардан Г.нең сөт бирми торган кәҗәсе атылып чыга. Аны тотарга азапланган хатын-кыз да кадала-тәгәри мүкәләп килә. Фатыйманың сүзсез торуыннан кыюланган Г.:

– Барыбер суялар икән бит, шәп мал әрәм булмасын, дидек инде, – дип куя. Ире сүзен хатыны елый-елый җөпли башлый:

– Абыстай, рәнҗемә, без наданнарга. Алыйк инде кәҗәңне, бушка түгел бит, менә алмашка үз кәҗәбезне калдырабыз! – ди.

Иртәгесен Фатыйманы авыл советына чакырталар. Рәис кеше:

– Балаларың бик кечкенә, шуңа кәҗәңне иткә тапшыртмаска булдык, абыстай, – ди. Әби моңа каршы тыныч кына:

– Кәҗәмне алып киттеләр шул инде, – ди. Моңа каршы авыл советы рәисе:

– Их, абыстай, абыстай! – дигән сүздән башка әйтер сүз тапмый. Ярлыдан кәҗәне кире кайтартып кара. Ярлы-ябага хуҗа булырга тиеш замана бит. Инде абыстайның мунчасына да чират җитә, ансын авылның өченче бер ярлысына өй итеп бирәләр. Бу мунча колхоз идарәсенә дип тартып алынган өйләреннән яңарак, Фатыйма салган мич тә яхшы гына җылыта, шулай итеп, мулланың мөлкәте тагын бер ярлыга совет властена кайнар мәхәббәт тәрбияләргә ярдәм итә.

Фатыймага «лишен в правах» (хокукларсыз) дигән тамга салынганга, колхозга ала алмыйлар, «единоличница»га чыгарып, җирнең дә иң уңдырышсызын бүлеп бирәләр. Туганнары, аның хәлен ишетсәләр дә, ярдәмгә килә алмыйлар. Чөнки алар үзләре дә асылда дин белән бәйле кешеләр һәм илдә барган үзгәрешләр аларның тамырларына да балта белән чаба тора. Алай да туганнар, киңәшә торгач, Фатыйма гаиләсенә 49 яшьлек апасы Таһираны күчерәләр. Биш кешедән торган гаиләгә Габделкаюм мулланың йорты да кире кайтарыла, чөнки Мирҗәмнән килгәндә үк иске булган бу йорт идарә карамагында торганда тәмам тузып беткән була. Габделкаюм да кайтыр, Аллаһы боерса, балаларны да шатландырып бер күрешербез әле, балаларының исән-сау булганнарын күреп бик сөенер әле, дигән уйлар белән канатланып яшәгән Фатыйма, үзләре янына апасы да күчеп килгәч, Кукмара ягындагы Тарлау авылына җыена. Аңа, шул авылга Архангельск янындагы лагерьдан бер тоткын кайткан, дип ишеттергән булалар. Фатыйма, ашкынып, Габделкаюмым турында берәр хәбәр белеп булмасмы икән, дип, озын юлга чыгып китә. Очрашуда әлеге тоткынлыктан котылып кайткан кеше: «Габделкаюм хәзрәтне яхшы белә идем, 1931 елны мәрхүм булды. Аның бик тә сезнең белән күрешәсе килә иде. Өзелеп сагынды. Срокны алдарак тутырып булмасмы, дип, үз-үзен аямыйча эшләде. Ахырда – өзлекте. Эчендә нәрсәдер өзелде», – ди. Фатыйманың күңелендә дә нидер өзелгәндәй була. Йөрәге өздереп сызласа да сыгылып төшми. Ходай Тәгалә миңа менә тагын бер сынау җибәрде, рәхмәт Аңа, дип, юл буе Ходайның рәхмәтенә сыенып кайта. Өйдән әниләрен сагынган балалары йөгереп чыккач, Фатыйма үзен тәмам кулга ала. Яшьле күзләрен сөртеп, сабыйларын кысып-кысып коча, әле ярый сез газизләрем бар, ди. Тик малайларга әти дә кирәк шул. Менә аның кече улы Әнәс, балаларын беркайчан да ач тотмаган, бәйлисен бәйләп, тегәсен тегеп өсләрен дә бөтен йөрткән әнкәләренә:

– Әни, әтине базардан алып кайтып булмыймы соң? – ди. Әнисе дә җавапсыз калмаска тырыша:

– Акча каян алырбыз икән соң, балакайлар? Аңа бик күп акча кирәк бит, – дип, сүзләрен кире кага.

– Безнең чалма белән төлке тун бар, син аны авыл очындагы апаларга биреп тордың, – дип, сүзгә кушыла малайларның олырагы. – Шуны сатыйк та...

Әмма, иремнең төсе итеп карармын, дип танышларына сакларга биреп торган затлы чалма да, тоташ төлке тиресеннән тегелгән кыйммәтле тун да бу вакытта инде каядыр юкка чыккан була. Күпме эзләп тә таба алмыйлар.

Җитәкчеләр, Фатыймага начар җир бүлеп биргән идек, дип тормыйлар, һәр елны йөкләмәне тутырып түләтәләр. Алай гына да түгел, авылга килгән йөкләмәнең яртысы ялгыз Фатыйма өстенә төшә. Ит, май, йон, сүс, ашлык йөкләмәләренең һәммәсен дә карусыз тапшыра бара абыстай. Бәхеткә, янында апасы Таһира бар. Кечкенәдән егылып имгәнеп бөкре булып калса да, гаиләдәге башка кызлар кебек үк, үз заманы өчен тирән белем, яхшы тәрбия алганга, ул Фатыйманың чын аркадашына әверелә. Алар тегү-чигү эшендә бик осталыклары булмаган Алан халкына көнне төнгә ялгап тегү тегә, чигү чигә, шәл, кофталар бәйли. Авылдашлары, яхшылыкның кадерен белеп, абыстайга эшләрендә җиңеллек тудыралар, ягъни җирен сөрәләр, чәчәселәрен чәчкәч, кирәк вакытларда төрлечә эшкәртеп тә бирәләр.

Кызы Тәүһидә дә боларны күрепбелеп үсә.

– Әйе, әнием Тәүһидә сөйләгәнне искә төшерәм. Бервакыт авылга ашлык йөкләмәсе килә. Күпме икәнен әни әйткән иде дә онытылган, алай бөртекләп хәтерләмим. Әнинең әнисе, ягъни Фатыйма әбием вакытында тапшырыйм, өстемдә тормасын, дип, төне буе көлтә суга. Башкалар кебек чабагач белән кыйнап-чәчеп түгел, ә көлтәсен селки-селки башаклардагы орлыкларны саклык белән генә паласка коя-коя. Иртән иртүк, кулбашының сызлавына чыдый алмый, күрше авылга юнәлә. Чыккан буыннарны урынына утыртучы имче карчык: «Кулбашың җилкә буыныннан ычкынган бит синең, абыйстай», – дип, Фатыйманың кулын рәтли. Әнә шул имгәнгән кулы белән бер олау көлтә селкегән икән бит әбием. Ашлык заданиесен тапшырырга баргач, колхоз рәисе аңа: «Сиңа бу ашлыгыңны Кукмарага илтеп бирергә туры килер», – ди. Ә Кукмара белән Алан арасы – 50 чакрым.

Ниһаять, абыстайны, кызганып, колхозга да алып куялар. Колхозда эш җиңелдән булмаса да, Аллага шөкер, ялгыз хуҗалык чагындагы кебек түгел. Шуңа Фатыйма иркен сулап куя. Кушкан һәрбер эшне җиренә җиткезеп эшли ул. Терлек маллары карый, сыер сава. Ә кичләрен үсеп килгән балаларына киемсалым әмәлли. Авылдашларын да онытмый – сораган нәрсәләрен тегә, чигә, бәйли. Колхозчыларның эшләгән өчен түләргә акчалары булмый, әлбәттә, әмма алар йомырка, май, бал кебек нәрсәләр китерә, ә бу инде биш кешедән торган гаилә өчен бик ярап тора. Абыстайның авыл халкы каршында дәрәҗәсе зур булса да, арада төрле кеше очрый. Көнләшүчеләре дә булгандыр. Ирсезнисез яшәп тә авырлыкларны җиңел күтәрүче, биш вакыт намазын калдырмаучы, зирәк зиһенле, күркәм холыклы, йомшак фигыльле, рәхмәт төшкере дигән сүздән башка орышу сүзе дә белмәгән Фатыйманы сынап карарга теләүчеләр дә булган икән. Фермада сыер савучы булып эшләгән чагында була бу хәл. Вакыйганың монысын әбинең замандашлары булган карчыклар авызыннан ишеткән идем. Кыш көннәрендә сыерларга эчәр суларын кайната торган булалар. Сыерларга су күп кирәк. Су кайната торган запарник (терлекчеләр йорты) шактый еракта, әнә шуннан суны көянтәләп ташый Фатыйма. Күпме генә алып кайтса да сыерлар, мөгрәп, кабат су сорый.

– Ни булды соң сезгә бүген, малкайларым? – ди дә, Фатыйма, кабат су ташый. Әмма берсендә улакка бер көянтә суны аударып чыгып китә дә

кабат әйләнеп керә. Караса, шул арада су тагын беткән. «Әһә, менә, ниһаять, абыйстайның чын йөзе ачыла, безнең кебек аты-юлы белән катлы-катлы сүгенсен әле», – дип, салам өеме артына качып көтеп торган сыер савучылар, шунда нибары:

– И, рәхмәт төшкерләре, тагы малларымны сусыз калдырганнар инде! – дигән карусыз сүзләрне генә ишетәләр. Атасы Закир хәзрәт гаиләсендәге тәрбия әнә шулай үтемле булгандыр, күрәсең.

Сугыш чоры булуга карамастан, балаларын укудан аермый ана. Алар Аланнан 6 чакрымдагы Борбаш авылына йөреп укыйлар. белемгә омтылалар. Әнәс белемле, чын-чынлап оста куллы булып үсә. Һәрнәрсә белән кызыксынучы малай, күрше малайларының өйләренә җепләр сузып, үзләренә күрә телефон шикелле нәрсәләр әмәлләп, дуслары белән шуның аша сөйләшә торган була.

Нечкә тәрбия аша килгән түземлелек гаилә тоткасы булган анага олы улы 19 яшьлек Мәсгут турындагы «Ленинград янындагы сугышта һәлак булды» дигән авыр хәбәрне күтәрешергә дә ярдәм итә. Мәсгутнең энесе белән сеңлесенә, әнине тыңлагыз, дип язган хатын кат-кат укып, төннәрен үлгән баласы өчен хәсрәт эчендә янып уздырса да, балаларына беркайчан да күз яшьләрен күрсәтми Фатыйма. Әнә, уртанчы улы Әнәсне дә ФЗУга чакыралар. Ул Казандагы Пороховой заводта авылдашы Зиннур белән эшли башлый. Имгәтә торган эш өстенә, суыгы үзәккә үтә торган баракларга кайтып, төннәрен йоклау урынына төрле бөҗәкләр «гаскәре» белән сугышып интегүләр, аеруча ачлы-туклы тормыш хәлләрен ала аларның. Болар Әнәскә һич кенә дә мантып китәргә ирек бирмиләр. Буйга да үсә алмый тора малай. Тәмам бетәшкән бу, дип, Әнәсне сугышка да җибәрмәгәннәр. Әнәсе өчен дә борчылган ана улының хәлен җиңеләйтерлек чаралар эзли. Менә Әнәс үзенең иптәше Садрый Зиннуры белән, ял көннәре җитүгә, товар вагоннарының түбәсенә менеп, Шәмәрдән станцасына кайтып йөри башлый. Фатыйма абыстай бу вакытта инде Зиннурның әнисен, безнең авыл сөйләме белән әйтсәк, Садри җиңгине (безнең авылда еш кына ялгыз карчыкларны мәрхүм ирләренең исемнәре белән атыйлар иде: Хәлиулла карчыгы, Кәримулла әби, Хәлиулла җиңги һ.б) ияртеп, авылдан 25 чакрым ераклыкта булган әлеге станцага җәяүләп килеп җиткән була. Кулы эш белгән кеше кайда да кадерле. Шәмәрдәнгә раскулачиваниедән качып килгән авылдашлары Сәләхи абзыйлар әбине һәрчак көтеп ала торган булалар, чөнки ул, анда килгән саен, Сәләхи абзыйлар гаиләсенең өс-башын бөтенәйтеп китә. Малайларга ашарга пешереп, туклыклы ризыклар белән сыйлап, мунчалар ягып, чиста түшәкләргә йокларга салгач, түр якка чыгып машина артына утыра да Сәләхи абзый гаиләсенә төне буе кием-салым тегә. Берникадәр көч җыйган балаларны Казанга озатып авылга кайткач, Садри җиңги авылдашларына: «Улымны күрү бер бәхет булса, Фатыйма абыстайның шундый да тәмле ашларын улым каршына утырып ашаулары гомер онытылмаслык бәхет инде», – дип сөйли торган була.

Йортларының тәмам эштән чыгуы да Фатыйманы күптән борчып килә. Аланга күчеп килгәнче үк шактый искерә төшкән, ә монда инде ир-ат кулы күрмәгән, үзем тапкан мал түгел, кешенеке җәл түгел кебек караш астында да яшәп алган бу йорт сугыш елларында менә-менә башыгызга ишеләм дигән хәлгә төшә. Күпме яксаң да җылы тота алмый торган тәрәзә тирәләре, түбәсеннән яңгыр үтүдән тәмам череп төшәргә торган түшәм такталары, нигездәге һәм бүрәнә араларындагы йөзләрчә тишек-тошык Фатыйманың вак-төяк төзәткәләүләренә, сыер тизәге кушылган кызыл балчык белән сылауларына карамый. Миче кызудан ярылып бетәрлек итеп ягылса да, төнгә инде кабат ягып алу кирәк, утын җиткерер хәл юк. Абыстай ярдәм сорап колхоз идарәсенә баргач, аңа, әнә Бурятиягә күчеп киткән

күршеләреңнең өендә торып тора аласың бит, дип, борып кайтаралар.

Фатыйма башта бу уй белән ризалашса да, кеше өендә торуның үз читенлекләре булуын да уйлап ала. Үз өеңне торгызсаң, үз хуҗалыгыңны булдырсаң гына чын, бөтен, таза тормышка ирешеп була, ди ул. Һәм идарәдәгеләрнең, йөрмә баш катырып, булмый ул синнән, абыстай, дип кирегә сукалап торуларына да карамастан, тәвәккәл тәгаләллаһы, дип, шул сугыш чорында ирләр кулыннан да килмәслек зур эшкә керешә. Иң әүвәл йорт сала белүче картларны барлый. Аңа яхшы танышы: «Сөмәел авылына барып кара әле, анда ике бертуган карт бар, бик осталар, булышырлар, иншаллаһ!» – дип киңәш итә. Әлеге картларны Фатыйма абыстай тиз эзләп таба, бәясен килешә һәм сарык суеп, шуны Казан базарына алып барып сатып та кайта. Өй салдырырга йөргүен күргән көнче авылдашы: «Абыстай мулланың алтынын акчага алыштырып кайткан икән», – дип гайбәт тарата. Ниһаять, Фатыйманың чын-чынлап тотынуын күргән колхоз идарәсенең дә оятына көч килә, ул, абыстайга ат бирергә, дигән карар чыгара. Яше шактый олы булу аркасында фронттан калган Гыйләҗ карт белән 13 яшьлек Тәүхидә – минем булачак газиз әнием – урман каравылчысы янына китәләр. Лесник аларга корыган агачларны күрсәтеп чыга. Гыйләҗ абзый Тәүхидә белән әлеге агачларны егып, бүрәнә итеп әзерли башлыйлар. Әни: «Гыйләҗ абзый бик түзем карт, арып, кисәргә көчем җитми башлагач та җайлап кына, кызым, пычкыны менә шулайрак тартып кис, шулай иткәндә армассың, дип, таза-таза ирләр өчен дә авыр урман эшен мөмкин кадәр җиңеләйтергә тырыша», – дип сөйли торган иде. Эшләре шактый озак вакытка сузылса да, бер йортлык агачны авылга ат чанасында әкрен генә ташып бетерәләр. Әлеге сөйләшкән ике карт та килеп эшкә керешә. Язга инде йорт әзер була. Мичен дә чыгарттыргач, шунда күчеп яши башлыйлар.

Фатыйманың алдан күреп шушы йортны салдыруы туганнар тормышында да уңай роль уйный. Зурлыгы бишкәбиш булган бу йорт үткән гасырның туксанынчы елларынача яшәп килде. Язмыш сынаулары бөтен Советлар Союзы буенча тараткан туганнарга очрашып күрешергә, туган туфракка кайтып сыенырга бер ышык урын була ул. Бу йорт бусагасын кем генә атлап кермәсен, ризыгын да, җан җылысын да, ихлас ярдәм һәм яклауны да, төпле киңәшләрне дә тапкан. Репрессияләрдән качып китүче туганнарыннан калып, соңрак бу яңа йорт чормасына күчеп сакланган сандык-сандык китаплар да Ташкент, Фрунзеларга киткән хуҗаларына кире кайтарыла. Кайбер гарәп шрифтында күчерелгән кульязма китаплар Казан университеты китапханәсенә тапшырыла. Анда бу китапларның күпчелеге дини китаплар булмаганлыгын ачыклыйлар.

Фатыйма әбием беркайчан да мактанмас, масаюны зур кимчелеккә санар иде. Шулай да миңа бер җылы гына сөйләшеп утырганда кыенлыклардан курыкмаска кирәклекне төшендерде. Мин, диде ул, тәүлегенә 4 сәгать йоклап, биш вакыт намазымны калдырмый яшәдем. Уразасын да җиренә җиткереп тоттым. Ходай җибәргән сынауларны да рәхмәт итеп кабул иттем. Һәм менә күр, 99 яшькә дә җитә алдым.

Намаз ахырында теләк теләгәндә: «Йә, Раббым... хасил булган әҗерсавапларын... шулай ук мөэмин-мөэминә булып үткән барча әти-әни, әбибабаларыбызның рух шәрифләренә ирештерсәң иде», – дибез. Әбиемнең рух шәрифләренә дә шуннан өлеш чыксын иде. Амин. ■

МИЛЛӘТ ХӘБӘРЛӘРЕ

Фотолар һәм видео **beznenmiras.ru** сайтында

● 1 февральдә «ТАТМЕДИА» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының киңәйтелгән утырышында ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сафәров «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары Марат Закирга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Рәхмәт хатын тапшырды.

● 7 февральдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Тукай энциклопедиясен тәкъдим иту булды.

Әлеге чарада күренекле галимнәр Ким Миңнуллин, Зөфәр Рәмиев, язучы-галимә Рифә Рахман, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов һәм башкалар чыгыш ясады.

● 11 февральдә Татарстан Республикасы Архив эшләре буенча дәүләт комитеты, Бөтендөнья татар яшьләре форумы белән берлектә, Февраль һәм Октябрь революцияләренә багышлап, «Тарихи бранч» клубының тәүге утырышын уздырды.

● 12 февральдә ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры, күренекле җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, «Безнең мирас» журналының редколлегия әгъзасы Рафаэль Хәкимгә 70 яшь тулды. Юбилярны ТР Президенты Р.Миңнеханов, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин котлады.

● 15 февральдә Казанда Муса Җәлилнең тууына 111 ел тулу уңаеннан бер төркем галимнәр һәм әдәбият-сәнгать әһелләре герой-шагыйрь һәйкәленә чәчәк салды. Соңыннан ТР Дәүләт музеенда шагыйрьне һәм аның көрәштәшләрен искә алу кичәсе булды.

● 15 февральдә Казанның Бауман урамындагы элекке Матбугат йорты бинасында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның «Татарстан Язучылар берлеге» дигән китабын тәкъдим итү булды.

● 17-18 февральдә Казанда күренекле дин галиме Галимҗан Барудиның (1857-1921) тууына 160 ел тулу уңаеннан фәнни-гамәли конференция оештырылды. Әлеге чарада күренекле татарлар белән бәйле йортларны саклау мәсьәләсе дә күтәрелде.

● 18 февральдә Кукмарада «Салават күпере» иҗат берләшмәсенә 50 ел тулу уңаеннан тантаналы кичә булды. Әлеге күркәм чарада байтак еллар берләшмә җитәкчесе булган эзтабар-шагыйрь Шаһинур Мостафин, шагыйрьләр Газинур Морат,

Рифә Рахман, Рүзәл Мөхәммәтшин, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон катнашты һәм чыгыш ясады.

● 20 февральдә Казанда бер төркем милләтпәрвәр күренекле җәмәгать эшлеклесе Садри Максуди (1878-1957) һәйкәленә чәчәк салды.

● 20 февральдә «Безнең мирас» журналы редакциясе, «Азатлык» яшьләр оешмасы белән берлектә, мәшһүрләребез Гаяз Исхакый белән Садри Максудига багышланган түгәрәк өстәл уздырды.

● 21 февральдә КФУның Л.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты бинасында Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевкә 70 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә узды.

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни (Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Бу кол-күң, ат-айгыр, җир-су барчасын
Илбик бирде, ачты дәүләт капкасын.

Нигъмәт таптың шунда, төрле игелек,
Илдә батыр атың булды билгеле.

Ярар микән сиңа, тагын да килеп,
Йөз чөерсәң аннан, дошманлык кылып.

Ярдәм итәр чакта китсәң качынып,
Рәнҗетерсең аны, ул бик ачыныр.

Сиңа кылды илбик чиксез игелек,
Кайтару кирәксез, дисеңме, егет?

Кеше күрсә, мактап, алкышлап сине,
Вафалы дигән дан таралыр иде.

Ни ди, ишет, бераү – кеше изгесе:
Кешелек булыр чын кеше билгесе.

Кешелек кыл, и, ир кеше, бул олуг,
Кеше шулай сала кешелек юлын.

Кеше бул кешегә, кешечә кылан,
Инсан дигән матур исемне казан.

Мең игелек күрдең илбигеңнән син.
Хәзер инде кайтар шуның нергәсен[1].

Җаваплы була ул – адәм изгесе,
Халыкта абруйлы була шул кеше.

Кече идең, углан, белексез идең,
Сине ул күтәрде һәм котлы итте.

Фида булсын аңар җаның вә тәнең,
Оеп ятма, көн-төн эшен кыл аның.

Игелеккә каршы игелек, диләр,
Ходай сиңа шуңа әҗерен бирә.

И, күңелдәш, акыл иясен ишет,
Ни ди миһербанлык кылучан кеше:

«Кем икмәген җийсәң, эшлә син шуңа –
Миһербанлык өстә хәләл ашыңа».

Тоз һәм икмәк хаклап, асыл егетләр
Җийдергән кешегә баш салып эшләр.

Ирештең теләккә, рәхмәтле дә бул,
Изге күңел белән хезмәт итә бел.

Ефәк хөллә кидең – затлы кумаштан[2],
Күреп, хөсетләнең күзе камашты.

Син инде илбиккә дан туны кидер,
Баш исен дошманнар, әчләрен көйдер.

Кеше бул кешегә, кешечә кылан,
Инсан дигән матур исемне казан.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.
[1] Нергә – «бүләкккә каршы бүләк».
[2] Кумаш – «тукыма» (бигрәк тә кызыл тукыма, комач).

Житешлектә яшәп җийдең мең нигъмәт,
Бугайныкы[3] кебек буең һәм иңнәр.

Бу көчне тот инде илбик эшенә,
Дога артсын синең озын яшеңә.

Дөнья малы җыйдың, үзең бай булдың,
Кәвәл һәм аргамак, тази тай менден[4].

Байлыгыңны эшләт илбигең өчен,
Теләккә ирештер, алсулат йөзен.

Тәхеттә ул тыныч булсын, бүген үк
Еракган җир үпсен дошман, йөгенеп.

Кулың озын итте, сүзең – үтемле,
Кем дошман, кем дус син белдең бит инде.

Син инде догаңны арттыр, и, дустым,
Дәүләтең зур булсын, гомерең озын.

Асыл кеше кылыр шундый изгелек,
Аты аның калыр бакый-мәңгелек.

Ни шәп әйтелгән бер гарәп шигърендә:
«Кешенең асылы – аның шөгъелендә,

Кешенең аслына кылмышы танык:
Кылмышы ни булса, асылы шул ук.
Кемнең аслы изге – кылмышы уңай,
Яманның аслына да эше танык».

Кылыгын үзгәртсә илбик, тап форсат,
Яман юлдан кайтар, дөрес юл күрсәт.

Барча игелекләр илбиктән тора,
Син шулар каршында таш булып торма.

Миңа ышанып, син киңәш сорадың,
Барча белгәненмне, менә, сөйләдем.

Мин әйткәнчә кушып үзең белгәнне,
Уйлап кара ныклап-эшең юнәлер.

Сөенде Үгделмеш, күр, әйтте: – Кардәш,
Шулай кирәктер, и, кешелеккә баш.

Ни яхшы әйттең, бу сүзләрне бүген,
Язылды миңа бу төелмеш төен.

**Игелеккә каршы игелек, диләр,
Ходай сиңа шуңа әҗерен бирә.**

Минем алдым томан иде бу хәлдә,
Син әйттең һәм, гүя, ачылды пәрдә.

Мин инде ташладым ялгыш теләкне,
Ходай бирсен инде рухи терәкне.

Илаһым сакласын, төз булсын күңлем,
Кылык-кылмышымда чын юлга күним.

Дога илә миңа кыл ярдәмеңне,
Тапшырылдым сиңа – онытма мине.

Сүзен кисте, купты аякка үрә,
Атланды атына, китте өенә.

Өйгә килеп керде, бераз йөренде,
Ашап-эчеп алды, кайгы сүрелде.

Капланылды тирмә – күкнең киезе,
Билен баглады ул, тол тунын киде[5].

[3] Бугай – кечле үгез, эш үгезе: рус телендә дә бар, бездән кергән.
[4] Кәвәл – «Европадан китергән чабышкы», тази – «гарәп аты».
[5] Монда күк гөмбәзе тирмәгә охшатыла; тирмәнең иясе – тол хатын тол сөкәт алдында траурда билен буып утыра, сөкәт – аның үлгән иренең сурәте.

**Син инде догаңны арттыр, и, дустым,
Дәүләтең зур булсын, гомерең озын.**

Кояш үргән чәчен язды шикелле:
Каралды күк йөзе кама, кеш кебек.

Түшәк сорап алды, ятты урнына,
Оеды беркадәр бик татлы гына.

Уянды, каранды, башын күтәреп:
Күк елмая – гүя, кыз килә көлеп.

Кояш күтәрелде – шатлык йөзендә,
Бөтен дөнья керде аккош төсенә.

Тиз торды Үгделмеш һәм тиз юынды,
Намазын укыды һәм дога кылды.

Ат менеп сәрайга тотты ул юлны,
Төшеп, керде илбик каршына туры.

Илбик Уйгырмышның хәлен сорады:
Әйтте: – Исән-саумы, фикре югары.

Догасында мине искә аламы,
Дога ич элгәртә бәла-казаны.

Дога белән инсан игелек таба,
Дога белән бара җәннәткә таба.

Галәмдә булмаса өмет һәм дога,
Яманнар җиңәрләр иде ич, туган.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш әйтте шундый сүз:
– Дөрес тәгъбирләдең, фәнчә дә төп-төз.

Кардәш анда бу көн ялгызы калып,
Безнең өчен дога кыла, моңланып.

Үз кайгысын куйды, безне коткара,
Шундый зат тагын бармы – әйтеп кара.

Һәм бездән гафилрәк бармы тагын да?
Без гөнаһ кылабыз – ул дога кыла.

Бүген ул илбиккә игелек теләп,
Догасын өзмидер күңелдән, телдән.

Шундый миһербанлы тагы булырмы –
Безнең өчен генә дога кылырлык.

Һәм бездән гафилрәк булырмы, илбик?
Гомер гыйбадәтсез уза, кул тими.

Үзебезне нигъмәт илә симертеп,
Кәеф-сафа корып, рәхәт көн итеп.

Ахырда корт ашый, чери үлек тән,
Тик үкенеч кенә кала үлектән.

Ни диләр, тыңла, бу белкәләр сүзе
(Эш итсәң бап аның илә, и, кузый)[6]:

Тәнең симерсә – корт, еланга азык:
Сөенәсең, ә бит дөнья – тик кунык.[7]

Төшең генә синең бу тереклегең,
Кичәге көн үтте һәм үтәр бүген.

Җавап биреп илбик, әйтте: – И, ирән,
Ничек тотанаклы булырга икән?

Миңа синнән бүтән юк рәхимле зат,
Шуның өчен синең киңәшең кыйммәт.

Мин инде өй эчрә ятамын гафил,
Эшләрем тыштадыр, и, гыйльме кямил.

Күзем-колагымсың, син күзәт, ишет,
Рәтсезлек күренсә, чара күр, эш ит.

Кирәк булса миннән ярдәм берара,
Әйт кенә, ул эшкә табырмын чара.

Бер як икенчесен җиңә алмаса,
Мин, вакыт уздырмый, бер якка басам.

Ерак тотсын илбик үзен залимнән,
Белексезләр үлсен, калсын галимнәр.

**Илаһым сакласын, төз булсын күңлем,
Кылык-кылмышымда чын юлга куним.**

---

[6] Кузый – «бәрән». КБ-тә иркәләү сүзе мәгънәсендә кулланыла – «егет, матур егет».
[7] Кунык – Кб-тә конук – «кунып китә торган урын, төш, кунакханә һ.б.т.; кунылгы».

Баесын бар халык һәм чәчәк атсын ил,
Шуңарга шатланып шөкер итсен тел.

ҮГДЕЛМЕШ СҮЗЛӘРЕ

Җавабән Үгделмеш әйтте: – И, бийем,
Ирләрнең асылы, артсын тәүфигың.

Теләгем дә шул һәм кирәгем дә шул:
Ача бирсен миңа Тәңре туры юл.

Рәхәттә яшәсен котлы илбигем,
Син авырма, башым авыртсын минем[8].

Синең өчен фида кылыйм үземне,
Тынычлыкта яшә, олуг ил биге.

Бер генә хаҗәтем бар бүген минем
(Сез аны шатланып үтәрсез, димен):

Беләсез, берәүне күтәрсә бийләр,
Бу хакта юк-барны күпләр сөйлиләр.

Менә сез дә мине бик кадерлисез,
Һәм әләкче халкы калмыйдыр сүзсез.

**Исәр илне тартыр акылсыз юлга,
Яманлык шул якка эз салып куйган.**

Туңа алпар батыр[9], ишет, ни дигән
(Ул үгет-нәсыйхәт сүзен дә белгән):

«Кеше күңле бик тиз бозыла – ит кебек,
Абайлап кап итне, и, кодрәтле бик».

Әләкне бер ир дә тыңламый калмас,
Ошакчы[10] арада бер урын алгач.

Әләкне никадәр тиз тотса да ир,
Әләкче тирәдә булгач, ышаныр.

Күңел – патша һәм тән – хезмәтче колдыр,
Вә туңар ул сүздән, сүздән кызыныр.

**Яманлык эшләмә һәм явыз түрә
Яман эш уйласа, мөмкинлек бирмә.**

Кешенең холкы дүрт капма-каршылык:
Бере – көлдергечтер, берсе – ачулык,

Бере шашкын, берсе ипле һәм тыныч,
Бере – көлеш, бере – елау, кычкырыш.

Сөенечкә каршы көенеч килә,
Көенеп торганда сөенеч көлә.

Шуңа мин аптырыйм, и, котлы илбик,
Бер әләкче кешең шыңшыса килеп,

Авырая холкың, күңел күзенә
Хезмәтем күренми, табым күренә.

Үтенечем шулдыр, тик шуннан тора:
Әләкче кем, шуны син миннән сора.

Бүтән кешедән дә сора һәм сорат,
Төгәл белгәч кенә бер хөкем чыгарт.

Әләкчедән тәүдә җентекләп сораш,
Ул йә ялган сөйли, йә фараз кора.

Ни шәп әйткән элек инсанның бере:
«Сүз тыңла – күңелдә калдырма керне».

Тагын да әйбәтрәк әйтә мәкаль дә
(Син аны, изге зат, куллан гамәлдә):

«Һәрбер сүзне тыңла, кирәген ал, от,
Кирәкмәгән сүзнең барчасын оныт».

Сүземне ишет һәм ялганны чыннан
Аер, чынны үз ит, ялганны кыйна.

Ялганчылар илә бу дөнья тулы,
Кадерлә, кодрәтлем, шуны, кем тугры.

Дәвамы ■

---

[8] Мондый игелек теләү шәрыкъта киң таралган, чагыштыр: грузинча шени чериме «исәнмесез» – сүзмә-сүз әйткәндә – «синең чирең миңа (булсын)».
[9] Туңа (туңка) алпар – борынгы бер атаклы хөкемдар.
[10] Ошакчы – ярамсак, әләкче.

Безнең мирас №3 март 2017

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

Романга бәян

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)

Ә барабаннар, икесенә бер, өркәчләр генә аерып торган уртак бауны бүлешкән гашыйкларның дала белән бәхилләшеп узуын тантаналы гүләүләре белән оза-та барып, ярсып һәм буыла-буыла үкерде. Йөзбашы белән чигүче хатынның тынсыз-җансыз гәүдәләре шундый күтәргесез йөк күтәргән малкайның як-ягында чайкалып барды, – бөтен дөньяны үкчәсе астына салырга дип ашкынучы хаканның, Кояш баешына барып җитеп, канлы тәхет баскычына басар өчен корбан чалуы иде бу.

Добулбаслар, күңелләргә боз коеп, шом салып, әле һаман да тына белмәде һәм ул көнне һәркем, бернигә карамый үз максатына омтылган ханның ихтыярына каршы бара калса, аңа да ни буласын үз күзләре белән күрә алды...

Ясавыл-җәлладлар, мескен дөя – күчмә дар агачы белән гаскәр һәм олаулар яныннан башларын югары тотып узды, алдан казып куелган чокырга мәетләрне төшергәнче, добулбаслар тынмады, барабанчылар, кара тиргә батып, үгез тиресен кагуларын белде.

Ул арада гаскәр яңадан юлга кузгалды һәм Чыңгызхан чирүен сыендырган дала да кояш баешына таба шуышты. Атлылар, олаулар, тамак туйдыру өчен куып барылган көтүләр, тәгәрмәч өстендәге корал ясаучы һәм башка шундый остаханәләр – кыска-сы, сәфәрдә катнашучыларның һәркайсы, ашык-пошык җыенып, Сарүзәк даласының бу каһәрле урыныннан тиз генә китәргә тиеш иде, алардан калган тирмә-учаклар эзендә үз-үзен кая куярга белмәгән һәм башкаларның да исенә төшерергә кыймаган бердәнбер җан – кулындагы бала белән хезмәтче Алтун гына калды. Аның турында дәррәү генә һәммәсе онытты, аның әле дөньяда икәнлегеннән оялган кебек, барысы да аны күрмәмешкә салышты, берәүдә дә бу ике хәсрәтле җан иясенең кайгысы юк иде.

Тиздән тирә-юньдә үле тынлык урнашты, бернинди добулбаслар, бернинди өндәү авазлары, байраклар калмады... Бары атлылар тезелеп киткән юл, тояк чокырлары – Сарүзәк даласында тиздән эреп югаласы шушы эзләр генә сәфәрнең кайсы якка таба юнәлгәнен күрсәтеп тора иде...

Алтун, колакларны чыңлатырлык ялгызлыкка ияләшә алмый каңгырып йөргәндә, кичәге учаклар яныннан ташландык азык калдыкларын җыйгалап, ите яртылаш кимерелгән, күмерләнгән сөякләрне, алдагы көнгә, дип, букчасына салгалады, бүтән чүп-чар арасында кемдер онытып калдырган сарык тиресенә юлыкты, шул тирене, ирексездән үзенеке иткән бала белән икесенең асларына төнгелеккә җәяргә дип, кул-тык астына кыстырды...

Чынлап та Алтун алга таба нишләргә, кай тарафка юл тотарга, кайда сыену урыны табарга, яңа туган баланы ничек тукландырырга икәнен күз алдына китерә алмый иде. Әле кояш яктыртып торганда, ул нindider могҗизага өметләнде: ә бәлки, көтмәгәндә бәхет елмаер да, нindider торак – далада югалып калган көтүче тирмәсенә тап бу-лырлар. Көтмәгәндә-уйламаганда берьюлы ирек тә, язмышның авыр йөген дә алган кол хатын, куркуын җиңеп, киләчәген хәерлегә юрарга тырышты. Тик нарасый тиздән ачыгачак, сөт таләп итә башлаячак һәм аның күз алдында ачлыктан үләчәк бит. Менә шул куркыта аны. Нәрсәдер эшләргә хәленнән дә килми иде.

Алтун исәп тота алган бердәнбер хыял – далада очраклы узгынчыларны булса да очрату, әгәр аларның арасында бала имезүче хатын да туры килсә, Кунанны аңа уллыкка бирү, ә үзен ирекле коллыкка тәкъдим итү. Хатын бушлыкны иңләп-буйлап үзенә урын

Башы журналның 2016 елдагы 8 нче санында. Тәрҗемәче – **Мөдәррис Вәлиев**.

таба алмый йөри, кулында бала тоткан килеш, ару-талуны белми, бер юнәлешне дә аермыйча бара да бара – әле көнчыгышка, әле көнбатышка, аннары кабат көнчыгышка... Инде төш җитеп килгәндә, сабый торган саен күбрәк кыбырсый, шыңшый, үкси, ими сорый башлады. Хатын аның биләүсәсен кабат төрде һәм, юл җаенда тирбәткәләп, тагын алга атлады. Тиздән бала чынлап торып елауга күчте һәм инде, тынычлана алмыйча, зәңгәрләнеп чыкты, Алтунга туктамый чара калмады, ул тирә-ягындагы өметсез бушлыкка карап ачыргаланып кычкырды:

– Ярдәм итегез! Ярдәм итегезче! Нишләргә инде миңа?

Күз иңләп бетерә алмаслык дала киңлегендә ни төтен, ни ут әсәре күренми. Бер кеше заты калмаган дөнья үзе дә өнсез-тынсыз ята... Иксез-чиксез дала шундый ук иге дә, чиге дә күренмәгән чалт аяз күккә тоташкан кебек, тик баш очында кечкенә ак болыт кына, кайда тукталырга белмәгәндәй, тып-тын әйләнеп йөри...

Бала елап өзгәләнде. Алтун аның өстенә иелә төшеп такмаклады:

– Йә гөнаһсызым, син миннән ни көтәсең соң?! Туганыңа әле җиденче көн генә бит! Үзеңнең бәхетсезлегеңә бу дөньяга килгәнсең... Ни белән тукландырыйм икән, ятимкәем? Күрмисеңмени, тирә-юньдә җан иясе дә юк! Бөтен дөньяда син дә мин, без икебез генә, хәсрәтле ике җан көеге һәм тагын күктәге ялгыз ак болыт, хәтта кош та очып үтми, нибары шул ак болыт әйләнә дә тулгана... Кая барыйк инде без синең белән? Мин сиңа кайдан ризык табыйм, бәбкәчем? Безне ташлап калдырдылар, ә атаң белән анаңны астылар да кайдадыр күмделәр. Сугыш җәясе тартып, бу адәмнәр кайсы кыйблага табына, ни өчен байраклар тотып, барабаннар кагып, көч өстенә көч ташлана һәм ул кешеләр сине, яңа туган балакайны ятим итеп, ач үлем авызына ташлап, кая бармакчылар?!

Алтун елаудан шешенгән сабыйны үзенә нык итеп кысып, яңадан дала буйлап йөгереп китте, йөгерүе – тик бер урында басып тормастан гына, хәсрәттән аягүрә үлмәс өчен... Ә нарасый аңламый, сыктаудан туктый алмый, елаудан буыла-буыла, үзенә тиешлене таптыра, анасының җылы сөтен таләп итә иде. Аптырагач, Алтун бер таш өстенә чүкте, күз яшьләре һәм ачу белән күлмәгенең якасын йолкып ертты һәм, тәмам өметсезлеккә бирелеп, аңа үзенең инде яшь булмаган, беркайчан да бала ирене тоймаган кечкенә имиен каптырды:

– Йә, мә инде, мә! Ышанмасаң – ышан! Мин сиңа сөт суырырга бирмәс идеммени, бәхетсез ятимкәй! Мә, ышан! Бәлки, ышанырсың да мине йолыккалаудан туктарсың! Әй, нәрсә сөйләп торган булам соң! Кемгә сөйлим! Минем буш имием ни дә, сүзләрем ни! И, Күк-Тәңрем, шул көнемдә нинди җәза әзерләдең миңа?!

Бала, имигә ябышып, шунда ук тынып калды һәм, бөтен барлыгы белән, көтеп торган рәхәткә тиенәм дип өметләнеп, иреннәрен чупылдатты, шулвакытта шатлыктан яктырган күзкәйләрен бер ачып, бер йомып, теш казналарын эшләтә башлады...

– Йә, күрдеңме инде? – дип, бер ачусыз шелтәләп алган булды талчыккан хатын ими таптыручы бәләкәчне. – Ышандыңмы? Буш куыкны тарткалавыңнан ни файда? Син бит бу юлы тагын да ачырак итеп күз яше түгәчәксең, ул чакта шул каһәр суккыры далада нихәл итәргә? Алдыйсың, дип әйтер идең, мин сине алдыймммы соң инде?! Бөтен гомеремне коллыкта үткәрдем, еллар буе кол булып йөрим, шулай да һичкайчан һичберәүне алдамадым, миңа әнием бала чакта ук әйтә иде, безнең нәселдә, минем Кытайда калган кардәшләрем арасында берсе дә беркемне дә алдамаган. Йә, йә, бераз юанып ал инде, хәзер син ачы хакыйкатьне төшенерсең...

Хезмәтче Алтун, үзен котылгысыз фаҗигагә әзерләп, шулай сөйләнде, әмма бәләкәй «колын»ның буш имидән аерылырга һич исәбе юк иде кебек, киресенчә, аның уч төбе хәтле генә йөзендә ләззәт яктысы балкуы бик сәер тоелды.

Алтун имиен сабыйның иреннәреннән сак кына тартып алды һәм кинәт аның йөзенә шул кечкенә имидән ап-ак сөт агынтысы сирпелгәч, әкрен генә аһ итеп куйды. Бу хәлгә исе-акылы китеп, ул яңадан балага имиен каптырды, аны кабат алды һәм чынлап та тагын сөт тамчыларын күрде. Аңа сөт төште! Хәзер ул үзенең бөтен тәненә ниндидер яңа көч иңүен ачык итеп тойды.

– Йа Хода! – Хезмәтче Алтунның аптыравы ирексездән йөзенә чыкты. – Минем сөтем бар! Чын сөт! Ишетәсеңме, бәләкәчем, мин синең әниең була алачакмын! Син хәзер үлмәссең! Күк безне ишетте, син – минем михнәтләр чигеп алган балам! Синең исемең – Кунан, сине әтиең белән әниең шулай дип атады, сине дөньяга китерү өчен алар бер-берсен яраткан иделәр һәм шуның аркасында һәлак булдылар! Балакаем, безгә бу могҗизаны тудыручыга – синең хакыңа сөтемне бүләк итүчегә рәхмәт укыйк...

Шушы хәлдән тетрәнеп, Алтун тынып калды, аңа эссе булып китте, маңгаена тир тамчылары бәреп чыкты. Чиксез киңлектә тирә-ягына каранып, ул, элеккечә үк, сыңар җан иясе дә – ни адәми зат, ни җанвар күрмәде, бары тик чалт аяз күктән кояш кына яктырта һәм баш очында ялгыз ак болыт әйләнә иде.

Ап-ак сөт белән тукланып һәм шуннан оҗмах рәхәтлекләре алып, сабый йоклап китте, аның каз каурые кебек җиңел гәүдәсе йомшарды, ярым бөгелгән беләктә ышанып-тынычланып калды, сулыш алуы тигезләнде; ә хатын, бөтен кичергәннәрен, колагында кабат шаулый башлаган добулбасларның рәхимсез дөпелдәвен онытырга тырышып, моңарчы таныш булмаган бәхетне – баласын имезүче ананың җан-тән ләззәтен тойды, – чиксез күк, дала, сөт – аның бәләкәй имиенә кереп йомарланган кабатланмас бер бәхет йомгагы иде...

Ә ул арада бөек дала чирүе – атлы гаскәрләр, олаулар, көтүләр – сәфәрен дәвам итте... Дөньяны яулап алырга чыккан кансыз хаканның сугыш арбасы кояш баешына таба тәгәрәде дә тәгәрәде. Кизүвыллар һәм яраннары озатуында, байрак йөртүчеләр артыннан җилдә җилфердәгән ачык кызыл каймалы, уттай ефәк һәм алтын-ефәк җепләр белән чигелгән, авызыннан ялкын ургылдыручы ярсу аждаһалы кара һоруңнар уртасыннан ару-талуны белмәс, язмышның үзе кебек гаҗәпсендереп торган төстәге – ак яллы һәм кара койрыклы алыштыргысыз юргасында Чыңгызхан «утравы» йөзеп бара иде... Юрганың кургаштан койган кебек авыр тояклары астында гүләп, җир шары артка таба тәгәрәде, хаканның чиксез мәмләкәте офыкка кадәр җәелеп, яңадан-яңа киңлекләр исәбенә һаман артты, үскәннән-үсә барды. Шушы чиксезлек һәм бөеклек белән чагыштырганда ком бөртеге генә булган хакан, һаман комарланып, күз күргән һәм күреп бетерә алмаган җирләрнең һәммәсенә ия булырга, Дөньяның Дүрт Тарафы аны үз хуҗасы итеп тануына ирешергә ашкына иде. Шуңа ул яу белән чыкты һәм чирүен һәлакәткә алып барды...

Ул көнне хакан үзен кырыс һәм сүзсез-өнсез тотты, аңа шулай булу килешеп тә тора шикелле. Әмма күңелендә нинди ташкын-давыллар уйнаганын берәү дә күз алдына китерә алмый иде. Кинәт һичкем көтмәгән хәл килеп чыкты – хакан кисәк кенә атын кайтыр юлга борды, артыннан ашыга-ашыга килүчеләр, аның белән чак кына йөзгә-йөз бәрелешмичә, як-якка читләшеп өлгерде. Хакан, борчылулы йөз белән, калтыранган учын каш өстенә куеп, юкка гына аяз күк йөзен айкады, юк, ак болыт кайдадыр тоткарланмаган, артта да калмаган, алда да күренми иде. Шулай көтмәгәндә югалды аны бер дә ташламый озатып барган ак болыт. Ул көнне дә, икенчесендә, бер атнадан соң да бүтән күзгә чалынмады. Болыт хаканны ташлап китте.

Идел якасына барып җиткәч, Чыңгызхан Күкнең аннан йөз чөерүен аңлады. Ул алга таба барудан туктады, Аурупаны яуларга улларын һәм оныкларын җибәрде, үзе, калган гомерен уздырып бетерергә һәм кайдадыр билгесез урында җир куенына иңәр өчен, Урдасына кире борылып кайтты».

* * *

Бу якларда поездлар кояш чыгышыннан кояш батышына һәм кояш батышыннан кояш чыгышына таба йөри иде...

1953 елның февраль урталарында Сарүзәк далалары аша кояш чыгышыннан кояш батышына таба баручы пассажир поездлары арасында махсус вагон өстәлгәне дә кузгалып китте. Тәртип саны куелмаган, иң алдагы багаж вагоны артына ук тагылган, чуен тәгәрмәч өстендәге бу «арба» башкаларыннан берни белән дә аерылмый, тик тышкы яктан бер

өлеше почта бүлеге булып, аңардан тома аерылган икенче яртысы дәүләт куркынычсызлыгы органнарына аеручa кирәкле мәхбүсләргә вакытлыча яшәү урыны иде. Бу очракта шундый «бәхет»кә Казагыстан МГБсының бер оператив бүлегендә армый-талмый хезмәт куючы өлкән тикшерүче Тансыкбаев уйлап тапкан эшнең корбаны Әбүталип Куттыбаев ирешкән булып чыкты. Нәкъ менә аны, Тансыкбаевның уяу күзәтүендә һәм көчәйтелгән сак астында, башка калаларга «гастроль»гә алып баралар иде.

Тансыкбаев, чыннан да, үз максатына ирешүдә ару-талуны белмәс бик тынгысыз бәндә икән, – сорау алулар юлда да дәвам итте. Майорның бурычы, аның уенча, немец әсирлегеннән серле шартларда качып, Югославиягә барып чыккан һәм анда, булачак югослав ревизионистлары белән генә түгел, Англия разведкасы белән дә турыдан-туры элемтәгә кергән затлардан корылган ятьмәне соңгы төененәчә сүтүдән гыйбарәт иде. Совет хакимиятенең шул заманда ук әзерләп куелган һәм сәгате сукканчы посып торучы дошманнарын, берәм-берәм, армый-талмый сорау алу, аларның күрсәткәннәрен башка чыганаклардан алынган мәгълүмат белән чагыштыру юлы белән ачыкларга, аннары тикшерү эшенең иң төп нәтиҗәсе-йомгагына – бусын «гаделлек ханбикәсенең тантанасы» дип йөртәләр бугай – гаепләнүченең үз гөнаһын тулысынча тануына һәм кылган эшләре өчен үкенүенә ирешергә һәм, шуңа таянып, ул адәм актыкларын ахыргача фаш итәргә, гадел хөкем кулына тапшырырга кирәк.

Моңа инде тиешле оеткы салынган – Әбүталип Куттыбаевтан фашистларга каршы Югославия җирендә сугышкан элеккеге хәрби әсирләрнең дистәгә якынын исемләп хәтеренә төшертү мөмкин булды; тикшереп карагач, аларның күпчелеге, әле дә исәнимин көе, илнең төрле почмакларында яшәп ятуы ачыкланды. Тегеләре шулай ук инде кулга алындылар һәм, үз чиратларында, көрәштәшләреннән тагын байтак кына исемнәрне атадылар. Бер сүз белән әйткәндә, әлеге эш күзгә күренеп үсә, ныгый, аңа инде ит куна башлады. Тансыкбаев аны, өстә утыручы башлыкларының фатихасы белән, чын-чынлап җитди фасылга күчереп бара иде. Уңышлы булып чыккан очракта, Югославия компартиясе белән кызганнан-кыза барган халыкара ызгыш-талаш җирлегендә, Сталин үзе Титоны идеологик каһәренә дучар иткән чакта, ул шактый отышлы булып чыгарга мөмкин. Өстәвенә, әлеге гадәттән тыш «эш», аны кузгатыпкыздырып җибәргән Тансыкбаевка гына түгел, башка калалардагы күп санлы коллегаларына да «мул уңыш җыеп алу» вәгъдә итә, – форсаттан файдаланып, барысының да өскәрәк үрмәлисе, үсәсе килә иде. Шуңа алар бергәләшеп хәрәкәт итү юлына бастылар да инде. Һәрхәлдә, Чкалов (элеккеге Ырынбур), Куйбыш, Сарытау кебек өлкә башкаларында, күзгә-күз очраштыру һәм төрле яклап сорау алу өчен, Әбүталип Куттыбаев дигән «күчтәнәче» белән, Тансыкбаевны түземсезләнеп көтәләр.

Тансыкбаев та вакытны бушка уздырмады, ул һәр эштә тизлек белән алдырырга һәм үз дигәнендә нык торырга ярата иде. Тикшерү астындагы тоткынның, ярым подвалдан чыгып, юлга кузгалуны ничек кичерүен, тәрәзә артыннан йөгереп узган станция яны авылларына нинди сыкрану һәм сагыш белән текәлүен дә күрде ул, әлбәттә, күрмичә калмады. Куттыбаев күңелендә нинди давыллар уйнаганын аңлый иде Тансыкбаев һәм, шуңа күрә, мөмкин булганча, аның ышанычына керергә тырыша, янәсе, ул, намуслы тикшерүче, аңа бер тамчы да яманлык теләми, чөнки Куттыбаевны әллә ни гаепле дип санамый, имештер, аның резидент, чит ил махсус хезмәтләренең агентура челтәре җитәкчесе түгеллеге билгеле, әгәр Әбүталип Куттыбаев өер башында торган резидентны ачыкларга һәм, иң мөһиме – аны фаш итәргә, күзгә-күз очрашу вакытында һич шикләнмәслек итеп исбатларга булышса, шуның белән үз хәлен җиңеләйтә алачак. Бик тә, бик тә. Биш-алты ел дигәндә, күрерсең дә торырсың, гаиләсенә, балаларына әйләнеп кайтыр. Теләсә нинди очракта, тикшерүнең гадел төгәлләнүенә ярдәм итсә, иң югары җәзадан – атып үтерелүдән котылып калачак, ә киресенә катып, «эш»не никадәр бутаса, органнардан дөреслекне яшерсә, аның үзенә шулкадәр начаррак булачак, гаиләсенә шулхәтле күбрәк бәхетсезлек китерәчәк... Тансыкбаев тоткынны шуңа ышандырырга тырышты.

Безнең мирас №3 март 2017

Аның тагын бер уен тузы – корбанының Сарүзәк риваятьләрен язып алган кәгазьләре, бигрәк тә маңкорт турындагысы һәм «Сарүзәктә җәзалап үтерү» дигәне: әгәр хезмәттәшлек итүгә барса, алар «эш»кә теркәлмәячәк, ә инде Әбүталип моңа колак салмый икән, Тансыкбаев хөкем итүчеләргә боларның барысын да ачып салырга мәҗбүр булачак, борынгылык тузаны астына яшерелгән милләтчелек коткысы дип карарга тәкъдим итәчәк. «Маңкорт турындагы риваять» – надан бабайларның онытылган һәм хәзер чүплеккә ташланырга тиешле телен торгызуга юнәлгән, милләтләрнең кушылуына каршы булган зарарлы өндәү. Ә «Сарүзәктә җәзалап үтерү» – бөек юлбашчыбызны гаепләү (әстәгъфирулла!) һәм дәүләт интересларының аерым шәхес мәнфәгатьләреннән өстен куелуы идеясен тәнкыйтьләү, череп таркалган буржуаз «шәхес иреге»нә теләктәшлек күрсәтү – күмәкләштерүнең, ягъни хезмәт коллективын бер максатка буйсындыруның гомум алгарышына кизәнү, ә бит моннан инде социализмны инкяр итүгә дә ерак калмый. Билгеле булганча, социалистик тормыш кануннарын бозуның теләсә нинди очрагы кырыс җәзага тартыла... Рөхсәтсез җәмгать малына кул сузган – әйтик, күмхуҗ басуыннан бер башак алып кайткан кешене юкка гына ун елгача лагерьга хөкем итәләрмени?! Ә инде идеологик «башак»ларны җыючы турында әйтеп тә торасы түгел! Әгәр шулай төреп бирсәң, хөкем мондый гаепләүләрне өстәмә статья буенча карарга мөмкин. Ныграк ышандыру-куркыту өчен, Тансыкбаев Сарүзәк әкиятләренең ачык кинаяләрен кычкырып укып күрсәтте, болар, ул һәрвакыт басым ясап әйткәнчә, Куттыбаевны кулга алу һәм аның белән хәтәр «уен»ны башлап җибәрү өчен, Буранлы станциясеннән килгән беренче әләк-нигез булган иде...

Поезд инде икенче тәүлек юлда. Билгесезлеккә бару булса ни, рәшәткәле тәрәзә аша булса ни, – Сарүзәккә якынлашкан саен, күз алдыннан йөзеп үтүче киңлекләр Әбүталипның рухи халәтен барыбер ныгыта иде. Сорау алулардан бушаган сәгатьләрендә, йөрәкне тырнап торган янаулардан һәм «яхшылык теләү»ләрдән арыса да, ул табаклы калай белән тышланган купе-камерасына кереп бикләнә дә үз-үзе белән ялгызы гына кала ала. Дөрес, Алматы ярым подвалындагы кебек үк, монда да бөтен төштән төрмә исе килә, назирның ишек тишегеннән зәһәр карап торган бәбәге астында яшәү биредә дә андагыдан рәхәтрәк түгел, шулай да бу – барыбер хәрәкәт әле, юл халәте, урын алыштыру һәм, ни генә димә, монда ул теге, тилерү хәленә җиткергән, тәүлек буе түшәмнән күзне сукырайтып ишелүче яктылыктан котылды, иң мөһиме – күңелендә, бер кабынып китеп, янә сүнеп янган, һич тә тынмый торган өмет яктысы – Буранлы станциясе аша узганда, балаларын, хатынын бер мизгел эчендә генә булса да күреп калу мөмкинлегенә кабынды. Шултикле вакыт эчендә аларга ни бер хәбәр сала, алардан да ни сыңар юллык хат ала алмады бит ул.

Ябык төрмә машинасында аны Алматы янындагы станциягә алып барганда һәм каравыл астында махсус вагонга – мәхбүсләр купесына этеп-төртеп керткәндә, менә шушы өмет һәм борчулар белән мөлдерәмә тулы иде Әбүталипның күңеле. Юлга кузгалгач та, поездның Сарүзәк ягына таба барганын сизүгә, күңеле яңа көч белән сыкрана башлады – күзенең бер кыры белән генә, бер керфек каккан арада гына балаларын, Зарипасын күрергә иде, аннары ни булса, шул булыр...

Бик сагынган иде ул, хәзер бүтән нәрсә турында уйлый да алмый, Алладан бары, Буранлы аша үтү көндезге вакытка туры килсен, тик төнгә, караңгыга калмасын да, поезд шушы станция аша, нәкъ менә Зарипа белән балалар урамда, күз алдында булган вакытта узсын, ягъни алар барак эчендә чакта уза күрмәсен, дип ялвара.

Язмыштан сораган нәрсәсе менә шул гына иде. Аз да түгел, күп тә түгел. Ә бит, уйлап карасаң, чынлап та, язмыш дигәненә ул көткән мәлдә балалар белән Зарипаны ишегалдына алып чыгу ни тора, – малайлар үзалларына уйнап йөргән булсын, ә Зарипасы, бауга керләрен элә-элә, узып баручы поездга борылып карасын, балалар да кинәт, баскан урыннарында уеннарыннан бүленеп, вагоннарның кояш нуры сикереп уйнаган тәрәзәләрен санап калыр иде. Ә бәлки әле поезд, тотар да, станциядә берничә минутка туктарга уйлар, – сирәк булса да, андый хәлне дә күргән бар иде бит! Әбүталипның күңеле

айкала башлый: бер яктан, кинәт шундый бәхет ишелеп төшмәс микән, дип өметләнә, икенче яктан, юк, кирәкмәс, мондый авыр сынауны, кичерешләрне йөрәге күтәрә алмас, шартлар, өстәвенә, балалар да кызганыч, – аталарын рәшәткәле тәрәзә артында күрсәләр, аларга ни булыр, үкереп еларлар тагын... Юк, юк, күрешмәвең хәерлерәк...

Язмышның күңелен йомшарту һәм теләкләре тормышка ашсын өчен, ул, әледән-әле тимер юл тамгаларына карап, тукталышлар буенча поездның хәрәкәт итү вакытын исәпләргә һәм чамаларга тырышты, – аңа Сарүзәктәге Буранлы станциясен тәүлекнең кайсы вакытында узачакларын билгеләү мөһим иде. Шулай да шикләнү һәм борчылулардан бу исәпләүләрнең туры килгән чагында да котылып булмый, бигрәк тә кышын бу еш очрый, – күп итеп кар яуганда, поезд тоткарланырга, графиктан чыгарга, соңгарырга мөмкин бит. Иң үкенечлесе – аталары поезд белән төнлә, өйдән берничә дистә адым ераклыкта гына узып киткәнен сизмичә, балалар белән Зарипа йоклап калырга мөмкин. Ә болай килеп чыгуы бик ихтимал, Әбүталип үзенең тулысынча көчсезлеген, язмышның кая таба борылуыннан һәм мәгънәсез бер очракка туры килүеннән тулысынча бәйлелеген танып, тагын да ныграк газап чигә иде.

Әбүталипның тагын курыкканы һәм Ходайдан аны бу бәладән йолуны бик сораганы – лачын күзле тикшерүчедән шул мәлдә генә булса да коткарып торуы, Тансыкбаевның чираттагы сорау алуны алар Буранлы станциясен узып барган сәгатьтә оештырмавы иде.

Кешенең бары тик мизгел эчендә генә якыннарын күрергә дигән самими теләгенә күпме каршылык һәм хәтәр киртәләр явызларча каршы тора, – иректән мәхрүм ителүнең бәясе шулкадәр иде; тик бернәрсә сөендерә һәм өметләндерә, аның камерасындагы тәрәзә барган шәпкә уң тарафта – нәкъ шул Буранлы станциясендәге барак урнашкан якта булып чыкты.

Барча бу фикерләр, шик-шөбһәләр, куркулар Әбүталипны кичерешләр чоңгылына тартып кертеп, аның хәзерге булмышын оныттырган кебек иде, ул инде, киеренке көтү халәтенә тулысынча күчеп, үзе турында кайгыртмый, бу дөнья гамьнәре белән яшәргә теләми, тикшерүче Тансыкбаевның авыру хыялында уйлап чыгарылган, имештер, әле сугыш вакытыннан ук әзерләп куелган дошман агентурасы челтәрен ачыкларга, шулай итеп, янәсе, дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү максатына ирешергә маташкан оятсыз бәндәнең аңа таккан һәм тануын берөзлексез таләп итеп торган коточкыч гаепләүләрен дә башыннан чыгарып ташлаган кебек иде.

Кулыннан ни Ходай, ни иблис тота алмаган Тансыкбаев үзе, Ходай белән иблис шикелле, бөтенесен алдан исәпләп һәм билгеләп куйган, бары тик ул кушканча хәрәкәт итәсе генә калган. Шул ният белән ул юлга чыкты, шунлыктан менә мәхбүсләр купесында Әбүталип Куттыбаевны да, «i» өстенә соңгы ноктаны куярга дип, үзе уйлап чыгарган «дошманнар» белән күзгә-күз очрашуга алып бара.

Әбүталипның исә Ходайдан үтенеп сораганы шул гына – вагон тәрәзәсеннән, бер мизгел эчендә булса да, мәңгегә саубуллашып, уллары Эрмек белән Даулны күзләре белән иркәләп узарга, Зарипасын күрергә һичкем комачаулый алмасын иде. Ул инде бүтәнгә өметләнми, язмыштан узмыш юк икәнлеген күңеле сизеп һәм аңы белән ачынып кабул итә, – тәкъдире шулай, күрәсең! Бу – аңа бәхетнең соңгы елмаюы булачак, бүтән беркайчан да гаиләсенә әйләнеп кайту турында хыяллана алмаячак, чөнки Тансыкбаев каршында ул, чиксез хакимияткә ия хан алдындагы кебек үк, тулысынча яклаучысыз һәм хокуксыз, димәк ки, иртәрәк булырмы, соңракмы, барыбер, атып үтерелү яисә лагерьларда черүдән кала, һичнинди өмет юк, башка бер юл да күренми. Әбүталип күптән шундый нәтиҗәгә килде: ул – Тансыкбаев кулындагы котылгысыз һәлакәткә дучар ителгән корбан. Үз нәүбәтендә, Тансыкбаев, мескенкәй – мәгънәсез тормышында икмәк черетүче, бер күнлек данга мохтаҗ, әмма даими рәвештә үзен-үзе чарлап торган, имештер, социализмның дөньяны яулап алуын туктатмакчы һәм җирдә коммунизм тантанасына комачаулык итмәкче дошманнарны армый-талмый эзләүгә һәм аларның тамырын корытуга юнәлтелгән җәза машинасының бер вак кыргыч кисәге.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №3 март 2017

Җан сызлавында туган «Галиябану»

«Галиябану» драмасы язылуга – 100, Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 125 ел тулу уңаеннан

Рәфыйк Шәрәфиев

Заман хисләренә кагылам да,
Галиябану, Сезне сагынам!

Илдар Юзеев.

Моңа кадәр Мирхәйдәр Фәйзи тормышын һәм иҗатын тирәнрәк өйрәнүчеләребез (Барлас Камалов, Муса Мөлеков, Лерон Хәмидуллин) игътибар иттеләрме, юкмы, аның шәхси тормышындагы бәхетсез гыйшык вакыйгасы белән драматургның иң әйбәт мәхәббәт драмасы туган чор бер вакыткарак туры килә икән.

Менә 1916 елның җәе, тиздән чын драматург булып танылачак егетнең Орск шәһәрендә яшәгән чагы. Шунда ул уналты яшьлек сылу кыз белән таныша. Әйбәт гаиләдән, сәүдәгәр кызы, танышудан соң күп булмаган очрашулар... Кыз Мирхәйдәргә фоторәсемен дә бирә. Егет аңа:

«Гомерем барда, исемең телләремдә
Гөлләр белән тиңләп тирбәлер», –

дип язып куя.

«Гомерем барда...» Егерме биш яшьлек егет (ул 1891 елның яңа стиль белән 1 ноябрендә Орск шәһәреннән ерак түгел Күкшел утарында Фәйзуллиннарның унберенче төпчек баласы булып дөньяга килә) гомеркәйләренең бик тә кыска икәнлеген уйлардымыни соң әле? Аның карашларын чиксезлеккә юнәлтеп яшәр чагы түгелмени?!

Әгәр сырхаулары борчып тормаса, шулай булыр да иде, бәлки. Тик «гомергә китүе игълан ителгән авыру» (М.Фәйзи көндәлегендәге үз сүзләре), аның хыял киңлекләрен чикләп, алдагы көнгә якты өметен әледән-әле сүрелдереп тора. 1913 елда солдатка каралырга баргач та аны алмыйлар: «Мирхайдар Файзуллин не годен!» – дип чыгаралар. *«Бөтенләй не годен булгач, минем хәяткә яраксызлыгым табыла түгелме?»* – дип яза ул көндәлегенә. Бераз элегрәк докторлар «Хөсәения» мәдрәсәсендә укуыннан да тыйганнар иде аны. *«Зур үкенеч белән укудан аерылдым. Надан көе калдым»*, – дип язды соңрак. Саусызлыгы, «хәяткә яраксызлыгы» гел исенә төшеп, җанын сыкратып тору нечкә күңелле романтик егетнең үз мәхәббәтенә дә фаҗигале төс биреп килгән, бу хәл аның әсәрләрендә дә чагылмый калмаган. Гөлсирә белән очрашуларыннан да бәхетле нәтиҗәгә өметләнмәгәндер ул. Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, 1916 елда бертуган абыйсының кызы Кәримә йөрәк авыруыннан үлеп китә. Күкрәгендә яшьтән өянәкле йөрәк йөрткән егет бу хәлдән тагын бер сискәнеп куйгандыр. Әдипләребез бәхет күрмәгәч, без дә күп вакыт бәхетсез мәхәббәт кыйссаларында, фаҗига каһарманнарында гына үзебезне таныйбыз. Мирхәйдәр Фәйзи дә 1921 елда Виктор Гюгоның «Сәфилләр» романын укыгач, анда бик тиз үзен «таба». *«Шулай, Жан Вальжан, Фантина, Козетта, Мариуслар кебек, мин дә бер сәфилмен... Балам булса, Жан*

Галиябану (Мәсгудә Хәйруллина) белән Хәлил (Роберт Әбелмәмбәтов)

Вальжан дип кушар идем», – дип яза көндәлегенә. Бер гасыр эчендә үзләрен Галиябануда һәм Хәлилдә «танучылар» никадәр икән?!.

Йөз ел элек язылган мәшһүр драманың беренче исеме «Сәгадәтбану» була. Моның сәбәбе, кайберәүләр расларга тырышканча, драматург кунакка килеп йөргән Шодадамы, бүтән авылдамы Сәгадәтбану атлы кыз яшәвендә һәм вакыйганың шуннан алынуында түгел, ә автор беренче ишетүеннән үк бик ошаткан, күңеленә бикләгән, шуннан файдаланып пьеса язу уе туган җырның «Сәгадәтбану» исемле булуында. Мирхәйдәрнең Шодада яшәгән Сәетгәрәй абыйсының улы журналист Сәгыйть Фәйзуллин истәлекләренә караганда, «Сәгадәтбану» көен алар тәүге тапкыр Орск өязенең Дүрткүл авылында яшьләрнең кымыз кичәсендә ишетәләр. Аны сугыштан бер кулын өздереп кайткан егет сыңар кулы белән гармун уйнап җырлый. Мирхәйдәр көйне бик ошата һәм отып та ала. Шул ук 1916 елның җәендә ул Сәгыйтькә ияреп Шодага килә, ә җанында һаман шул көй. *«Малмыж бакчасында «Сәгадәтбану» һәм «Җәмилә» көйләренә җырлап утырдым»*, – дип яза ул. Үз якларына кайткач, дәвам иттерә: *«Казан ягы авылларында йөреп кайттым, бу яктагы авылларда күргән матур күренешләрдән файдаланып, «Сәгадәтбану» исемле пьеса язу уе туды. Көннәрем шул хакта мәшгуль булып уза башлады»*. «Матур күренешләр» дигәндә ул, һичшиксез, кыз белән егетнең бәхетсез гыйшкын түгел, яшьләрнең су буендагы, Шода чишмәсе янындагы (монда ул «Их, нинди күңелле!» дигән шигырь дә яза) кичке уеннарын күздә тота. 1916 ел көндәлекләрендәге Шода күренешен «Галиябану»дагылар белән чагыштырып карасак, гаҗәеп тиңдәшлек күрер идек. *«Матур су буе манзарасы мине тәмам сихерләде. Кояшны көн дә су буенда озатам. Бу якларда һәр авылда елга булу өстенә, суны чишмәдән алалар. Ул чишмә яны кызларның, егетләрнең иң кадерле урыннары була икән. Кояш баеган вакытларда чишмә янында чиксез бер чуарлык, шул нисбәттә бер күңеллелек хасил була. Егетләр йөргән кызларын күбесенчә шушында очратып сөйләшәләр»*, – диелә көндәлектә. Кайсы гына авылга барып чыкса да, анда

яшьләр белән аралашырга, уеннарында катнашырга, җырларын тыңларга яраткан ул. Күңеленә иң якын иткән дуслары да җырчылар-гармунчылар бит. Шуңа күрә аның әсәрләрендә дә җыр үзе бер үзәк персонаж кебегрәк тәкъдим ителә. 1913-1914 елның кышында Мирхәйдәр Җүнәйдә яшьләр уенын карый. *«Җырлаучылар эчендә Дүрткүлнең Хәсән Зөфәров исемле унсигез яшьлек ямьле бер егетнең җырлары шундый үзәгемә үтте, шундый көчле тәэсир бирде ки, шундый саф, матур тавышлары бар халык та бәхетле булмаса...»* – дип яза ул көндәлегенә. Шул юл белән драматург моңлы Хәлил белән Галиябануның да, «Ак калфак»тагы Бакыйның да, «Асылъяр»дагы Шәрәфнең дә (автор бу әсәрен «укуга барганда буранда адашып иңрәп үлгән халык баласы Шәриф Сәйдәшевкә» багышлый) бәхеткә хаклы булуларын күрсәтергә тели. Тик, ни көенеч, аларның бәхетен Исмәгыйльләр, Сәлим мирзалар, гадел булмаган җәмгыять һәм мәгънәсез сугышлар кисеп тора. «Галиябану» драмасы язылачак 1916 елда Мирхәйдәр «шундый саф, матур тавышлы» җырчы Хәсәннең, сугышка алынган җиреннән авырып, лазаретта үлгәнлеген ишетә. *«Капиталны химая (яклау, саклау) юлында, моңа кадәргеләре янына, тагын бер корбан,* – дип яза ул көндәлегенә. – *Синең үлемең мине рухан газаплый, ил егете! Синең матур хәрәкәтләрең, мәгъсүм кыяфәтең, саф тавышың күңелемдә кадерләп тибрәтелер, туган!*

Уйлап торсам, җаннарым әрни: сугыш тормышны бәрбад итте (җимерде). Никадәр ямьле яшь егетләр әрәм булды, була. Никадәр яшь өметләр илләреннән, сөйгән ярларыннан җода булып (аерылып) читтә тилмереп михнәт чигәләр. Туганнар бер-берсен үтерә, кан коя. Элек җан кыйган кешене Себер җибәрәләр иде, хәзер кешене күп үтергән саен мактап медальләр тагалар. Кан, күз яше, аһ-зар, бөлгенлек, ятимнәр, ачлар, мәҗрухлар (яралылар), каберләр белән дөнья тула. Бәхетемә ирештем, дигәндә генә үлем каршына барып баскан яшь өметләрне һәлак итү никадәр җинаять, никадәр дәһшәт... Боларны үз мәнфәгатьләренә харап иткән мәнфурмәннәргә (җирәнгеч кешеләр, кабахәтләр) мәңгелек нәфрәтләр, ләгънәтләр яудырам».

Драма менә шундый җан әрнүләре, күңел газаплары шартларында языла. Шуңа күрә дә аның каһарманнарын, аларны бик яратса да, бәхетлеләр итеп сурәтли алмый ул. Ниһаять, драма әзер. Көндәлектән юллар: *«Декабрьдә «Сәгадәтбану» исемле биш пәрдәле пьеса яздым... Моңарчы татар әдәбиятында булмаган бер тарызда (рәвеш, ысул) җырлар, уеннар белән язган вә идеалымның көзгесе булган пьесамны тәнкыйтьчеләр аяусыз тибеп җибәрерләр инде».* 1917 елга чыккач дәвам иттерә: *«Сәгадәтбану»ны, тәвәккәлләп, Мортазин-Иманскийга җибәрдем. Ул бик күтәреп каршы алды. Мактап, күңелне күтәрде. Арабызда озын хатлар язышу китте. Үзе тапкан кимчелекләрне күрсәтте. Кабул ителердәен төзәттем. Исемен дә «Галиябану»га алыштырдым. Иң элек көенең тарихы итеп бетерсәм дә, соңынтын чын тарихына җинаять булыр дип үзгәрткән идем. Бу инкыйлаб пьесага бер гайре табигыйлык биргән иде. Мортазинның мәслихәте белән, куанакуана, әүвәлге калыбына салдым».* Бу язмадан аңлашылганча, пьеса нигезенә салынган бәхетсез мәхәббәт вакыйгасының «чын тарихы» да булган, әмма драматург аны көй тарихы итеп сурәтләргә тырышкан. «Галиябану»ның беренче басмасына кереш сүзендә Галимҗан Ибраһимов әлеге уңайдан менә ниләр яза: *«Галиябану»ның бөтенләй яңа хасиятләреннән берсе – аның бездә беренче мәртәбә сәхнәгә музыканы, җырны, бер иттифакый (очраклы) зиннәт ясап кына түгел, бәлки төп матди итеп, асыл мөндәриҗә (эчтәлек) кыйлып кертүедер. Буны «Галиябану» башлап җибәрде. Хәзер инде буңа тәкълитләр (ияру) дә була башлады. Бу, шөбһәсез, бездә яңа нәрсә иде, кирәк нәрсә иде... Менә шундый хасиятләре белән «Галиябану» бездә ялгыз урында тора, драмалар галәмендә*

Галиябану
(Марзия Миңлебаева)
белән Хәлил
(Гыйльметдин Газизов)

Галиябану (Илсөяр Төхвәтуллина) белән Хәлил (Рамил Төхвәтуллин)

яңа мәктәп ача һәм, шулар аркасында, бик хаклы буларак, гаммә алдында иң кадерле урыннарның берсен ала».

Мирхәйдәр Фәйзи, яңа әсәренең иҗат ителү тарихын бәян итеп, көндәлегенә: *«Баш каһарман Хәлил Юлык егете Вафа Әдһәмовның тибы аркылы сөзелеп чыкты, пьесаның язылуына да Вафа сәбәпче булды»*, – дип язып куя. Нәкъ шушы сүзләр кайберәүләргә, «драмадагы вакыйгалар Юлыктан алынган, драматург аны шушы авылда эшләгән чагында язган», дип белдерергә сәбәп биргәндер. Юлыкның хәзерге Башкортстанга керүен истә тотсак, «Галиябану»ның туган җирен шул республика белән бәйләргә маташулар да ачык күренә. Әмма чынлыкта Вафаның баш каһарманга охшашлыгы – аның да Хәлил кебек моңлы җырчы, гармунчы булуында гына. Драматург белән алар 1915 елда, Вафа Орскидан солдатка каралудан кайтып килгән чакта Җүнәйдә танышалар. *«Матур көйләр уйнавы күңелемдә матур типлар, матур уйлар тудырды»*, – дип яза бу очрашу хакында Мирхәйдәр Фәйзи. Мәшһүр әсәргә Вафа нәкъ менә «матур тип» буларак керә. Бу вакытта драматург Юлыкны күреп белмәгән әле, чөнки драма язылып берничә ел узгач кына ул авылда эшләгән. Драманың кулъязмада гына калган беренче вариантында баш каһарманның исеме Вафа була. Аның Хәлилгә әверелүенә, мөгаен, тагын Шода авылы сәбәпчедер. Менә 1916 ел (!), кайгылы, борчулы чак – герман сугышы дәвам итә. Әнә Шоданың 1919 елда солдатка каралася япь-яшь егетләре, сугыш аркасында, быел ук никрут булып йөриләр. Хәлил исемлесе, туган җирләреннән һәм якыннарыннан аерылу сагышы белән, бигрәк тә моңлы җырлый. Драматург бу исемне дә, яшь егетнең моңлы тавышын да хәтеренә салып куя. Әдип күңелендә Юлыклы Вафа, Дүрткүлле Хәсән, Шодалы Хәлил тудырган «ямьле күренешле» моңлы сурәт, җуелмыйча, әсәр язылып кат-кат уйналганнан соң да озак саклана әле. Берничә елдан Шодада Хаҗи исемле егет белән танышкач ул көндәлегенә: *«Шундый егетләр күргәндә миңа «Галиябану»дагы Хәлилем исемә төшә дә, уңышым белән куана башлыйм»*, – дип язып куя.

Фоторәсемнәр Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры архивыннан алынды. ■

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

«ШАҺНАМӘ»

Шагыйрьләр һәм тәрҗемәчеләр секцияләренең берләштерелгән утырышы беркетмәсе

19 март, 1981ел

Катнашалар: Х.Туфан, Ә.Исхак, И.Юзеев, Р.Гатауллин, Ә.Рәшитов, К.Миңлебаев, Р.Мингалим, Ф.Гыйззәтуллина, Р.Хәлиуллина, Р.Зәйнуллин, М.Гайнетдинов, Н.Хисамов, Н.Ханзафаров.

Көн тәртибе: М.Г.Гайнетдиновның Фирдәүси «Шаһнамә»сеннән тәрҗемәләрне тикшерү.

МӘСГУТ ГАЙНЕТДИНОВ:

– Галимҗан Ибраһимов «Шаһнамә» әсәрен һәр татар укучысының өстәлендә булырга тиеш китап дип саный. Аның белән кызыксыну бик күптәннән килә. Әмма әсәрнең үз телебездә бүгенге көнгә кадәр күренмәве һәрберебезне борчыгандыр. Төп чыганак итеп төрки вариантын алдым. Бу эчтәлектәге әсәрләр Фирдәүсигә кадәр дә булган. Фирдәүси аны шигырь итеп язган. «Шаһнамә» рус телендә 4 том итеп чыгарылды. Тәрҗемә иткәндә мин төрле вариантларны чагыштырып эшләдем. Бу бигрәк тә исемнәрне билгеләгәндә кирәк булды.

Фарсы варианты белән кызыксынмадым.

ӘХМӘТ ИСХАК:

– Фирдәүсинең зур икәнен әйтеп тору кирәкмидер. Аның тәрҗемәсенең кирәклеге көн кебек ачык. Моңа кадәр мираска мөнәсәбәтебез аркасында күп кенә әсәрләребез бүгенге укучыга килеп

Безнең мирас №3 март 2017

Мәсгут Гайнетдинов



Әхмәт Исхак

җитми. Безнең алда Фирдәүси әсәренең бер өлеше генә. Чын тәрҗемә оригиналдан тәрҗемә итүне сорый.

Хатип Госман Сәйф Сараи әсәрен гарәп хәрефләре белән бастырып чыгарды. Аны бүгенге татар теленә тәрҗемә итәргәме һәм ничек? Тәрҗемә иткәндә Сараидан түгел, Сәгъдидән кирәк.

Үлчәм мәсьәләсендә кыенлык.

Бүгенге телгә тәрҗемә иткәндә борынгы тәгъбирләр, әйләнмәләр, стиль зур комачаулык итә. Аңлатма бирергә кирәк була (мисаллар китерә). Сүзләрне рифма өчен генә бозулар бар бу тәрҗемәдә. Бүгенге әдәби телне сакларга кирәк. Рифмалар. Хәзер рифмага таләп зур. «Хәл-тере» кебек рифмалар тәрҗемәдә булырга тиеш түгел.

Исемнәр. Оригиналдагыча түгел. Үлчәм кайбер урында сакланмый. 11-11 алынган да, кайчагында 10-10 белән китә.

Татарча булмаган юллар бар. Кытыршылыклар. Фигыль заманнары шактый буталган.

НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВ:

– Тәрҗемәнең читенлеге хакында. Шул чор тарихын, әдәбиятын белергә кирәк. Мәсгут шигърияттән шактый хәбәрдар. «Шаһнамә»нең тәрҗемәсен чыгару безнең бөтен әдәбиятыбыз өчен зарур. Төрки һәм үзбәк тәрҗемәсе булу татарчага тәрҗемәне җиңеләйтә. Мәсгут, эчтәлекне тулы саклаган хәлдә, әсәрнең бүгенге көн өчен кирәкмәгән өлешләрен кыскартуга да бара. Төзәтергә мөмкин җитешсезлекләр. Теле мәсьәләсендә. Кайбер борынгы әсәрләрне чыгарганда, борынгы традицион тәгъбирләрдән дә файдаланырга мөмкиндер.

Мишәрчәлек бар. Кайбер сүзләрдә ул үз-үзен аклый шикелле. Стиль күп урында саклана. «Солдат», «закон» сүзләре биредә бөтенләй ятышмый.

Җыеп әйткәндә, Мәсгутнең тәвәккәллеген хупларга кирәк. Әсәрне татар телендә күрәсе килә.

ХӘСӘН ТУФАН:

– Мондый ритмлы әсәрләрне мин бер генә борынгы әсәребездә дә очратмадым. Бу көе әле тәрҗемә әдәби эшләнелгән дип булмый. Мондый чатак ритмлы әйберне укып булмый. Мин дә укый алмадым.



Хәсән Туфан

Кыям Миңлебаев

НАЗЫЙМ ХАНЗАФАРОВ:

– Фән өлкәсендә эшләүче, шигырь белән таныш кешенең мондый тәрҗемәгә алынуы бик табигый. Мин тулысы белән кызыксынып укып чыктым. Кимчелекләре байтак, әлбәттә. Ләкин төзәтмәслек түгел. Әлегә укучыга шул көе тәкъдим итү дә ярыйдыр. Чөнки аның академик басмасы кайчан әзерләнә ала.

КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВ:

– Мәсгуткә ихтирамым бик зур. 10000 юлны тәрҗемә итү – зур фидакярлек. Әмма мин Хәсән Туфан фикере белән килешәм.

ӘХМӘТ РӘШИТОВ:

– Биредә кайбер иптәшләр, тәрҗемәне укып чыкмыйча гына, аның бер-ике строфасы буенча гына фикер йөрттеләр. Мин кулъязманы тулысынча диярлек укып чыктым. Кайбер кытыршы урыннарга юлыксам да, бөтенләй үк төртелеп калмадым. Әсәрнең әһәмияте бәхәссез. Без көнбатыш әдәбиятын биш бармагыбыз кебек белгән чорда, үз әдәбиятыбыз субашына – көнчыгыш поэзиясенә игътибар итмәвебез, аны үз телебездә яңгыратмавыбыз бик зур кимчелек. Бераз патриотлар булырга кирәктер. Тәрҗемәгә махсус редактор беркеткәндә, әйбәтләп редакцияләгәндә, татар укучысына әйбәт бүләк булыр иде.

РӘДИФ ГАТАУЛЛИН:

– Сөйләшү бик кызыклы булды. Төрле фикерләр әйтелде. Әмма төп нәтиҗә: тәрҗемә әле кондициягә килеп җитмәгән.

Карар: Фирдәүси «Шаһнамә»сенең Мәсгут Гайнетдинов тарафыннан тәрҗемә ителгән бүлекләренең тәрҗемәсен укып тикшергәч, шагыйрьләр һәм тәрҗемәчеләр секциясе кулъязманы әле эшләнеп бетмәгән, нәшриятка тәкъдим итәргә иртәрәк, дип таба һәм аны тулы кондициягә китерү өчен тәрҗемәчегә кире кайтара, тәрҗемәнең төзәтелгән вариантын кабат секцияләр утырышына куярга кирәк, дип саный.

Утырыш председателе – Р. Гатауллин
Секретарь – Ә.Рәшитов

*Беркетмәне **Ләбиб Лерон** укыды.* ■

Безнең мирас №3 март 2017

Сәгыйть Рәмиев.
1911 ел

Сәгыйть Рәмиев
(1880-1926)

1916 елда Сәгыйть Рәмиевне Уфаның жандарм идарәсенә чакырталар. Куркытылган һәм ялган тыңлап башы әйләнгән шагыйрь, хезмәттәшлеккә ризалык биреп кул куя. Аңа аена 25 сум билгеләп, татар зыялылары арасында «панисламистик һәм пантюристик настроениеләр турында җиткереп тору» бурычы йөкләнә. Әмма әдип, «охранка»га илткәнче, әләгендә кем турында сүз барса, язганнарын әүвәл шул кешегә күрсәтә торган була, һичкемгә зыян салмаска тырыша. Бурычларына салкын карау сәбәпле, бер елдан аны әләкчеләр исемлегеннән сызып ташлыйлар.

Инкыйлабтан соң жандарм идарәсе архивлары җәмәгатьчелек кулына күчә. Шагыйрьгә хөкем була. Мәхкәмә, Сәгыйть Рәмиев шымчылык белән шөгыльләнмәгән, дигән нәтиҗәгә килә һәм аны аклый. Алай да, шагыйрь бу хәлне авыр кичерә, үзен мораль яктан пычранган, дип саный һәм авыруга сабыша.

Сәгыйть Рәмиевнең татар теле һәм орфографиясе буенча да күп кенә эшләр башкаруын искәртеп узу зарур. Бу мәсьәләдә ул, шактый телчеләрдән аермалы буларак, гарәп хәрефләрен үзгәртеп, сипләп булашуны кирәк санамый, турыдан-туры латин имласына күчүне мәгъкуль күрә: яңа хәрефләрне татар телендә куллану проектларын төзи, «Идел» газетасында (Әстерхан) бастырып чыгара.

Беренче бөтенсоюз тюркология корылтае (Бакы шәһәре, 1926 ел) узган көннәрдә Сәгыйть Рәмиев Уфа хастаханәсенә салына. Шагыйрьнең хәлен белергә килгән Касыйм Гыйрфанов бу чорны болай сурәтли: «Мин, съезддагы фикер алышулар һәм

Уфадагы татар зиратында Сәгыйть Рәмиев кабере

Шагыйрь соңгы көннәрен яшәгән йорттагы элмә тактасы (Уфа шәһәре, Октябрь инкыйлабы урамы, 29 йорт)

карарлар язылган газеталарны алып, аның янына больницага бардым. Съездда латин хәрефләре кабул ителгәнлеген телдән дә, укып та аңлаттым. Ул сабыйларча куанды, нурланып киткәндәй булды.

Мин, сәламәтлеге, кәефе ничеклеге турында сораша башладым.

– Хәлем яман түгел. Ләкин кичкә табан, бигрәк тә кояш баегач, авыраям. Һава җитмәгәндәй була. Әмма кояш чыгар алдыннан хәлем яхшылана... – дип сөйләгәч, мин аңарга көлебрәк кенә Бальмонтның:

Я в этот мир пришел,

Для того, чтоб видеть солнце!..[1] –

дигән шигыреннән бер-ике куплет[2] укыдым. Ул тагын да җанланып киткәндәй булды:

– Төн таңга таба авыша башлагач та, тән җиңеләйгәндәй була башлый. Бу, әлбәттә, кояш тәэсире инде. Мин «кояш культы» төзегән кешеләрне бик акыллы һәм реалист булганнар дип уйлап ятам, – диде.

Мин аның «кояш культы» турындагы фикерләрен бик кызыксынып тыңладым. Бу 1926 елның 16 марты иде.

Көн кичкә таба авышты. Мин, күп сөйләтеп арытмыйм, дип рөхсәт сорап, иртәгә тагын килермен, дип кулын кысып күрештем.

– Кил, кил! Син килгәч, рәхәт булып китте әле!.. – дип, мине күзләре белән озатып калды...

Ләкин икенче көнне ул юк иде инде...»

Сәгыйть Рәмиев Уфа шәһәрендә вафат була. Татар зиратында җирләнә.

Әдәбият:
1. Рафаэль Мостафин. Һәрберсен исемләп искә алыйк. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. – Б.195.
2. Уйласам уй, сызлый күңлем, сызлый җан... Сәгыйть Рәмиевнең тормыш юлы һәм иҗатына карата яңа мәгълүматлар. Төзүче-автор Чулпан Зарипова-Четин. – Казан: Яңалиф, 2005. – Б.91-104.

***Рүзәл Мөхәммәтша** әзерләде.* ■

[1] Текстта шулай бирелгән. Оригиналда: «Я в это мир пришел, чтоб видеть Солнце!..»
[2] Текстта шулай бирелгән. Дөресе – строфа.

УТЛЫ КИСӘҮ

Лерон Гыйльфанов

(Истәлекләр, уйланулар)

АШАУ-ЯШӘҮ

Шөкер, әле дә 1 метр да 68 сантиметр булып үсеп җиттек. Әнигә рәхмәт инде, безне шулай итеп үстерә алды. Җәйгә чыккач, кычыткан, тукранбаш үләне турап аш пешерә идек. Ә урманнан бәләкәй капчык белән урман какысы, балтырган, шомакай алып кайта идек. Он күзеңә дару итеп кенә сипмәле. Күбәк мәктәбенә ашарга үзем белән шалкан, төче торма алам, ипине аталы малайлар алып килә. Мин үзем әнине тыңлап үстем. Бары бер мәртәбә генә сүз тыңламадым, яңадан андый хәл булмады.

Көз укулар Күбәктә октябрь башларында гына башлана. Авылда да, Күбәктә дә колхоз бәрәңгесен алышабыз. Колхозлар безнең авылда да, Күбәктә дә киндер, горчица чәчә. Укый башлагач, Күбәктән кайтып, коры агач ботагына барабыз. Лесниклар урманга кертми иде.

Елын төгәл әйтә алмыйм, 1950 нче еллар тирәсе иде шикелле. Безнең колхоз авылдан ярты километр тирәсе ераклыкта диләнкә алган. Әни, Сәүдә апа, Раян Мәрьяме, тагын башкалар агач кисә. Эш беткәч, ягардай коры агач ботагы алып чыгалар. Менә беркөнне лесник (ул авылдан 1,5 километр ераклыктагы кордонда яшәде, халык аны Лотый дип атап йөртте) әниләрне район судына биргән. Әниләр Яңа Сәет авылына (*шагыйрь Зөлфәт, язучы Фәтхулла Абдуллин туып-үскән авыл.* – Ред.) судка бара. Билгеле инде, әниләр җәзасыз калмый. Югыйсә, колхоз диләнкәсенә Лотыйның катнашы булырга тиеш тә түгел. Аның өчен колхоз җаваплы. Менә шуннан аңлагыз инде. Ни ашарга, ни кияргә юк, дигәндәй...

«Утлы кисәү» бер сәгатькә арттан калмый хәзергәчә озатып килә.

Безнең әни тыл ветераны да булмады. Әнинең нинди эшләрдә эшләгәнен белгәнгә, ачынып әйтәм. Авылның колхоз маллары елганың теге ягында иде. Сыерлар, сарыклар, күпмедер санда дуңгызлар, бозаулар бар. Әни шунда төнге каравылда торды. Баштарак колхоз кәнсәсен, соңрак атлар карады. Кирайларга каршы келәтләр бар иде. Анда да төнге каравылда торды әни. Салихов абыйлар тыкрыгында сушилка урнашкан иде. Ул Хәйбулла абыйлар янында, чокырның теге ягындагы басу турысында түбәсе генә су үтмәстәй кирпечтән җайлап салынган иде. Менә шунда әни белән Гыйльмиямал апа, соңыннан Хәбибулла абый карчыгы эшләде. Әни, мәрхүмәкәй, нинди генә эшләр эшләп китмәде. Ир-аты булганнар мондый хезмәтне төшләрендә дә күрмәде.

Уйлап куям да, ник безнең гаиләгә атлаган саен кайнар көлгә басып атларга язган, дим?

КУНАКЛАР, АТЛАР ҺӘМ БЕЗ

Числосын яза алмыйм, истә калмаган. 1942 елның көз ае. Безнең авылга бер гаилә Ленинград ягыннан китерелде. Гаиләдәгеләрнең иң олысы – 70 яшьләрдәге әби. Аннары ул әбинең килене, кызы һәм 13-15 яшьләрдәге ике малай. Болар гел урысча сөйләшә. Ләкин үзләре урыс милләтеннән түгел.

Башы журналның быелгы 2 нче санында.

Лерон Гыйльфанов әнисе Хәмдия белән. 1961 ел

Сентябрь ае булдымы икән, колхоз өендә торган чак. Колхоз шушы гаиләне без торган өйгә кертте. Бу өй урамга арты белән салынган иде. Без торган башында дүрт тәрәзә, эчке өлеше биш метрлар тирәсе. Ә өйалды тактадан иде. Менә шушы өй эчен икегә бүлеп, безгә бер тәрәзә кертеп, такта ишек куеп бүлеп бирделәр. Безнең урын нык кысынкы булды, әле анда әни каз да утыртты. Анда торганда, безнең мамыклы кәҗә, сыер, бозау бар иде. Бу килгән «кунак»лар бик тыныч халык булып чыкмады – тиз арада безнең бер казны һәм тагын кайбер кешеләрнекен үзләренеке иттеләр.

Менә шул бер тәрәзәле кечкенә бүлмәдә аш та пешер, дәрес тә кара, йокла да. Төнлә янган 5ле, 7ле, 10лы лампаларның яктысы өстәл яныннан аз гына китә иде. Менә бу безнең балачак инде. Күз алдына китерсәң, исләрең китеп аварлык. Бу килгән кешеләр белән бер кыш чыктык. Икенче елны болар китте, җәй иде.

Мәктәпне Тимерханның әнисе карый иде. 1945 елны авылда башлангыч белем алдык. Менә шул апа, сугыш бетте, дип әйтте. Көн җылы, 20 градуслар булгандыр. Бала-чага бик сөенеште. Исән калганнар әкренләп кайта башлады, ни кызганыч, безнең әти бүгенгәчә юк инде. Әле безне язмыш «утлы кисәү»нең табасына ныклап батыра. Әмма дөрес: «утлы таба» өстендә яңача яшәү башлана.

Хәзерге Мөсәббихалар планының арт өлешендә каравыл өе бар иде. 1945 елның көзендә безне (әни, мин, сеңелкәш) башта торган өйдән чыгарып, шушы йортка урнаштырдылар. Монда тагын бер тәрәзә кертеп, тактадан яшәр өчен урын бирделәр. Менә шушында «тәмуг утлары» күренә башлады инде. Сугыш бер җан иясен дә читтә калдырмады. Сыерларга, атларга ашау җитми. Шушы елның көзендә атларда корчаңгы чире башланды. Бу чирле атларны карап дәваларга кирәк. Безнең авылның башына Карамалыга таба өй салган, ике өй аркылы ветсанитар Мирхаҗиян абзыйлар бар иде. Атларны менә шул Мирхаҗиян абзый, чишмә очы Саимә апалар һәм тагын Тәфкил исемле яшь егет дәвалады. Көннәр суыта башлагач, без торган йортның өйалды өлешенә 7-8 чиләк су керешле мич чыгарып, анда ниләрдер кушып, дару ясыйлар иде. Ул якта атлар көн җылынганчы булды. Аларның чире тиз генә бетмәде. Без торган башта каравылчыга урын ясадылар. Урта ишек ачылгач, безнең якка да сасы дару исләре керә иде. Күпме кирәк – сула гына. Шуңадырмы, Мирхаҗиян абзыйның

Күренекле артист Наил Әюпов туып-үскән йорт. 1960 нчы еллар

сәламәтлеге начарланды. Күзләре тәмам күрмәс хәлгә килде. Ә хезмәттәше Тәфкил абый бакыйлыкка күчте. Билгеле, мондый яшәү безгә дә шактый зыян салды. Әнинең йөрәк авыртулары башланды...

Кулымнан килсә, болар турында кино төшерер идем.

Алда исә – һаман да «утлы кисәү».

ӘНИ БЕЗНЕ НИЧЕК ӨЙЛЕ ИТТЕ ЯКИ КҮЧМӘ КИНО ҺӘМ БАШКАЛАР

1945-1946 еллар кышында әни, мәрхүмәкәй, үзебезнең өй булсын, дип, күрше Бакалы районы Кәчти, Сарашлы һәм башка авылларда йөреп, берни таба алмый кайтты. Соңыннан Иске Карамалының безгә таба очыннан бәләкәйрәк дүртпочмаклы өйалдысыз өй алып кайттык. Ул өйне хәзерге планга салдык. Икенче кышны да өйалдысыз чыктык.

1946 елның көзендә Күбәккә йөри башладык. Киләсе кышка кергәндә инде өйалды да булды. Бу өйдә 1960 елга кадәр яшәдек. Хәзерге йортның агачларын урманнан зелпе тамыры чыгарып алдык.

Бая язганда әйтеп бетермәгәнмен: ул чирле атларны авылдашым Апыра Закир (аңа күп кеше шулай дип әйтә иде) төнлә карый иде. Аның бер кызык ягы бар иде, ул бераз ачы бал эчеп, йомшап килә иде. Үзенчә болайрак җырлап ала:

Трат-та-там, трат-та-там,
Язгы чәчү вакытында
Тик ятуны яратам.

Ул да күптән мәрхүм инде.

Без Күбәктә укыганда, укулар 7 класска кадәр иде. Мин Күбәктә 7 классны үземнән 3-4 яшькә олыраклар белән укып бетердем. Урта мәктәп район үзәге Мөслимдә иде. Авылдашларым Равил, Гөлсинә, Халидә (инде барысы да мәрхүм), Вәсимә белән бергә 1952 елда укып бетердек. Мин Мөслимдә безгә кардәш, әтинең әнисе ягыннан Бүләк авылына барып тоташа торган Рабига апада тордым. Аның Камил исемле бер малае бар иде. Казанда агрономлыкка укыды. Башта Алтай крае якларында эшләп, соңыннан Казанга кайткан, дигәннәр иде.



Лерон Гыйльфановның армиядә хезмәт иткән чагы. Саратов, 1953 ел

Кайсы елдан башлаптыр, авылга күчмә кино килә иде. Акча булмаса, кем ничек җаен таба: чикләвек, тавык йомыркасы кебек нәрсәләргә кино карап була иде. Кино тавышсыз. Киномеханик үзе белгәнчә безгә аңлатып бара. Кино карарга акча-әйбер булмаса, тышкы яктан тәрәзә аша карыйлар иде. Зуррак малайлар-егетләр кул белән мотор әйләндерә иде.

Мин белгәндә, авылга председатель итеп Мизхәт абыйның туганы Гаттаров абыйны куйдылар. Күпмедер вакыт эшләгәч, район җитәкчелеге аны агроном-председатель әзерли торган техникум тибындагы мәктәпкә укырга җибәрде.

Өскә-башка кияргә күп нәрсә юк иде. Ничә яшькә хәтле аякка чабата кияргә туры килгәндер, төгәл белмим. Шулай да мин үзебез өчен чабатаны үзем ясый идем. Лесниклар карательный отряд кебек булды. Урманга төнлә генә керә идек.

Менә шулай кайгы-хәсрәтләр кичереп, бәләкәй малайлардан үсмер егетләргә әйләндек. Шушы урыс илен саклап, әти ягыннан Гыйльфан бабам, әтием Хөҗҗәт башларын салды. Үлгәндә әтигә 37 яшь була. Әни, сеңелкәш, үзем, «утлы кисәү»гә баскан килеш, ниндидер яхшылыкка ирешербез, дип авылдашларым белән һаман алга таба барган булабыз.

Шушы урыс җирендә яңадан сугышлар булмасын, дип, мин дә армиядә 2 ел да 4 ай булып, запастагы офицер дәрәҗәсендә хезмәт итеп кайттым. Башта Саратовта, аннан соң Вольск шәһәрендә кече командирлар әзерли торган берьеллык мәктәптә укып, аерым танковый частьта булдым. Сыйныфташым, дустым Диктат Галиев тә (хәзерге вакытта Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиллек җитәкчесе, генерал-майор Равил Әхмәтшин хатынының әтисе) Саратовта хезмәт итте. Ул – запастагы офицер. Армиядән авылга, әни янына 1955 елның 10 декабренда кайттым.

Мин армиядә чакта безнең авыл Иске Карамалыга кушылган иде.

Дәвамы бар ■

ТЕАТР ЕЛЪЯЗМАЧЫСЫ

Театр белгече, тәрҗемәче, педагог, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Театр әһелләре берлеге әгъзасы Рәмзия Идиатулла кызы Такташ 1932 елда Казанда туа. 1954 елда ул Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлый. Башкалабызның 117 нче мәктәбендә рус теле һәм әдәбиятын укыта.

Габдрахман Әпсәләмов, Диләрә Тумашева, Рәмзия Такташ һәм Мәҗит Рафиков. 1962 елның 14 гыйнвары

Рәмзия Такташ 1963-1989 елларда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында баш режиссёрның әдәбият буенча ярдәмчесе булып эшли.

1989 елдан театрның музей фондларын саклаучы вазифасын башкара. Бер үк вакытта Казан дәүләт университетында «Татар әдәбияты тарихы» һәм «Тәрҗемә теориясе» дигән махсус курслар алып бара.

Рәмзия Такташ 1956 елдан татар язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итә башлый. 70 нче елларда Татарстан Язучылар берлегендә рус теленә тәрҗемә итүчеләр бюросын җитәкли. Мирсәй Әмир, Фатих

Хәсән Туфан Рафаэль һәм Аван Такташлар белән. 1959 ел

Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов, Шәйхи Маннур, Аяз Гыйләҗев, Хәй Вахит кебек язучылар белән иҗади хезмәттәшлек итә. Туфан Миңнуллин, Хәй Вахит, Рабит Батулла пьесаларының рус теленә синхрон тәрҗемәсен эшли.

1979 елда Мәскәүнең «Советский писатель» нәшрияты Хәй Вахитның пьесалар җыентыгын бастырып чыгара. Анда кергән «Давыл», «Мәхәббәтең чын булса» пьесаларын Р.Такташ тәрҗемә итә, шулай итеп, ул үзен югары әзерлекле профессиональ тәрҗемәче буларак таныта.

Р.Такташ Г.Тукайның тормыш юлын һәм иҗатын тирәнтен белә, шагыйрьнең иҗатын тикшерүче профессор И.Г.Пехтелевны үзенең остазы дип саный. 1979 елда Мәскәүнең «Молодая гвардия» нәшриятында Р.Такташның сүзгә-сүз тәрҗемәсе нигезендә «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән И.Нуруллинның «Тукай» китабы дөнья күрә. Р.Такташ Татарстан китап нәшрияты белән дә даими хезмәттәшлек итә: аның тәрҗемәсендә Г.Тукайның хатлары, фельетоннары урын алган сайланма әсәрләре, соңрак татар язучыларының әкиятләре һәм новеллалары дөнья күрә.

Үзенең ире Аван Такташ (Һади Такташның улы) белән Рәмзия Идиатулла кызы Татарстан язучылары съездларында, Г.Тукай клубы эшчәнлегендә катнаша, К.Нәҗми, М.Әмир, Х.Туфан, Х.Сәлимҗанов, Г.Кутуй, Г.Минский гаиләләре белән якыннан аралашып яши.

Күренекле татар язучылары һәм шагыйрьләре белән хезмәттәшлек итү Р.Такташның М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрындагы эшчәнлегенә дә уңай йогынты ясый. Бу, беренче чиратта, театр репертуарын милли әсәрләр белән баетуда чагыла. Ул Х.Вәлиуллинның «Самат» һәм «Дим буйлары», Б.Мөлековның «Кара йөзләр», Н.Җиһановның «Алтынчәч», Р.Гобәйдуллинның «Җиһангир» операларын; Ә.Бакировның «Беренче факел», Р.Гобәйдуллинның «Мәхәббәт җыры», «Кияүләр» исемле музыкаль комедияләрен; Ә.Бакировның «Су анасы», Н.Җиһановның «Ике легенда», А.Монасыйповның «Үлмәс җыр», Л.Любовскийның «Кыйссаи Йосыф» балетларын; Л.Хәйретдинованың «Мәкерле песи», З.Хәбибуллинның «Сихерләнгән малай», Р.Кәлимуллинның

Безнең мирас №3 март 2017

Аван һәм Рәмзия Такташ балалары Искәндәр һәм Йолдыз белән. 1962 ел

«Ерактагы кәккүк авазы» әсәрләрен сәхнәләштерүдә актив катнаша.

Р.Ахиярованың соңгы елларда театрда сәхнәләштерелгән «Шагыйрь мәхәббәте» операсы (Р.Харис либреттосы) зур уңыш казанды. Әлеге спектакль, шулай ук Н.Җиһановның «Җәлил» операсы театрда Р.Такташның синхрон тәрҗемәсендә тәкъдим ителде. Театрның татар телендәге рекламалары, афишалары, буклетлары Р.Такташ тарафыннан эшләнде. Ул Тукай партиясен башкаручы Әхмәт Агадигә татар теле буенча күнекмәләр дә бирде.

Тукайның балачагы, үсмерлек еллары шигърияте Р.Яхинның 1987 елда куелган «Фидаи» балетында чагылыш таба. Аның либреттосын Л.Исакова һәм Р.Такташ яза.

Р.Такташның эшчәнлеген күренекле режиссёр Нияз Даутов югары бәяләде. Театр үсешендә аның мәгърифәтчелек эшчәнлеге дә мөһим урын тота. Ф.Шаляпин һәм Р.Нуриев фестивальләре уңаеннан оештырылган күргәзмәләр, Шаляпин укулары, иҗади очрашулар, сәхнә ветераннары өчен хималык акцияләре, опера сөючеләр клубы эшчәнлеге, радио һәм телевидение тапшырулары, тамашачылар конференцияләре – һәммәсе Р.Такташ оештырган чаралар.

Театрның өлкән хезмәткәре Р.Такташ театр эшчәнлеге белән бәйле тарихи материалларны өйрәнә, системалаштыра һәм кадерләп саклый. Ул – чын мәгънәсендә М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының елъязмачысы, аның аяклы энциклопедиясе.

Матбугат өчен Татарстан Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре ***Флюра Дәминова*** *әзерләде.* ■

ИЛЧЕ КҮЧТӘНӘЧЕ

Равил Вәли

Сәйдәшнең Идел буйларына хәвефле сәфәре, Черек күлгә алып кителеп, аннары эштән кыскартылуы, боларга бәйле рәвештә ашказаны чире азып, авыр хәлдә калуы турындагы борчулы хәбәр ерак Алжир тарафларына да барып иреште.

СССРның бу илдәге генераль консулы Хәбибулла Фәтхуллин илчелек йомышлары белән иртәгә үк Мәскәүгә очарга тиеш иде. Ныклы күзәтү астындагы Салих аганы күптән күрә алган юк. Бу кайтуында, җаен табып, һичшиксез, Казанга да сугылып чыгарга кирәк.

Дөрес, ул Мәскәүгә һәр кайтуында моңарчы Салих агасы турында да онытмады. Ашказаны чире белән интеккән композитор өчен бик кирәкле Алжир күчтәнәчләре – кызгылт-сары мандариннар белән әфлисуннар Казан каласына агылып кына торды. Башта илче Хәбиб күчтәнәчләрне үзе алып кайтып, үз куллары белән тапшыра иде. Ләкин ул яшәгән йорт тирәләре Черек күл шымчыларының ныклы күзәтүе астына алынуы ачыклангач, илчелек карьерасына зыян салмасыннар өчен, бу хәвефле сәфәрләрне башта азайтырга, аннары бөтенләй туктатырга туры килде.

Моның шулай булуын Сәйдәш үзе теләде. Юк, үзе өчен түгел, ә дәрәҗәле илче Хәбиб энесе өчен борчылудан.

Казанга хәтле үк кайтып йөри алмаса да, Хәбибулла Фәтхуллин авыру Сәйдәшне

Башы журналның быелгы 1 нче санында.

гаять кирәкле илче күчтәнәчләреннән өзмәү җаен тапты. Кичке якта Мәскәүнең тимер юл вокзалына сетка-сетка күчтәнәчләр күтәреп килде дә, аларны Казанга кайтучы пассажирларның берсе аша биреп җибәрә башлады һәм, ни гаҗәп, аларның барысы да тиешле иясенә барып җитә һәм тапшырыла торды.

Тимер юл вокзалына бер килүендә үзенең авылдашын – Яңа Кенәр егетен очраткач, эшләр бөтенләй көйләнде. Мәскәүнең авыл хуҗалыгы академиясендә аспирантура үтүче – булачак фәннәр докторы һәм Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләге иясе Марсель Маликов дигән бу яшь галим үзе дә Сәйдәш иҗатына мөкиббән киткән бик ышанычлы егет булып чыкты.

Илче күчтәнәчләрен Алжирдан туган Казанына еш җибәреп торгач, Хәбибулла Фәтхуллинны яшелчә һәм җиләк-җимеш кибетчеләре дә күптән белеп бетергән иде инде. Вакыты тыгыз, эше күп чакларында ул аларга телефоннан гына шылтырата. Кәрҗин-кәрҗин әфлисун, мандариннарын күтәреп, алар хәзер килеп җитә.

Менә бу юлы да телефон ярдәмгә килде. Сатучы мөселман өммәтеннән булып чыкты:

– О-о... Салих Сәйдәшев! Кызыл Армия маршы! «Хуш, авылым!»... Беләбез, беләбез! Хәзер, Хәбибулла әкә, хәзер... Бер аягыбыз монда, икенчесе Сезнең янда булыр.

– Юк, монда ук килеп йөрүегез кирәкмәс. Мин сезне үзем чыгып каршы алырмын.

– Ярый, Хәбибулла әкә, ярый...

***

Ходай саклангинны саклар, ди.

Илче Хәбиб тә бу алтын кагыйдәгә гомере буе тугры булып яшәде. Башта Кытайда һәм Вьетнамда, аннары Мисыр белән Алжирда озак еллар вә үтә сак яшәү, сак сөйләшү буенча бөртекләп тупланган бай тәҗрибәсе аңа бу юлы да югалып калмаска ярдәм итте. Театр артындагы торак йорт урнашкан ишегалдына килеп керүгә, ул биредә як-якларына шикчел каранып, киләп салып йөргән ике карачкыны күреп алды. Хәер, булыр сиңа карачкылар – көт! Икесе дә озын кара плащ, киң кырыйлы кара эшләпә кигән, күзерикләрен кашларына хәтле батырып төшергән. Күренеп тора: теге усал оешмадан көндәлек кенә түгел, тәүлеклек күзәтүгә җибәрелгән кара козгыннар иде болар.

Илче Хәбиб, ят шымчыларга игътибар бирмәскә тырышып, юлын дәвам итте. Сәйдәш яши торган фатир ишеге каршына килеп җитә язган иде инде. Күчтәнәчләр күплегеннән бүселеп чыгарга җиткән калку эчле, затлы-йомшак тышлы юл сумкасын җиргә куеп, ишек тоткасына үрелүе булды – теге ике карачкы, ике яктан култыклап алып, аның юлына аркылы төште:

– Ыстоп!.. Кайдан бирегә кайтыш? – дип ысылдады аларның берсе.

– Кемгә?.. Нигә?.. – дип өстәде икенчесе.

Илче Хәбиб тиз генә уйлап өлгерде: әгәр дөресен әйтсәң, төпченә башлаячаклар: син кем, нигә чит илдә яшисең, халык дошманы Кәрим Тинчуринның җан дустына ни йомышың төште?

Хәбиб үзе өчен курыкмый. Аның СССР илчелегендәге зур һәм җаваплы постларда озак еллар намуслы хезмәт итеп казанган авторитеты бар. Шулай да әлегә бу козгыннарның ул турыда берни дә белми торулары хәерле.

Ә менә Салих Сәйдәшев мәсьәләсенә килгәндә... Юк, соңгы елларны болай да чын-чынлап советчыл каныгуга дучар ителгән бөек композиторга карата урынсыз һәм куркыныч шикне арттырырга һич кенә дә ярамый!

Тукта!... Күзнең явын алып торган кызгылт мандариннар Советлар Союзының

кайсы төбәгендә үсә әле? Әлбәттә, Абхазиядә! Әлбәттә, андагы Пицунда төбәгендә! Кара диңгез буендагы бу әкияти гүзәл шәһәрдә кайчандыр илче Хәбибкә дә бер айлап ял итү бәхете татыган иде. Аларны шул көннәрдә әфлисун, мандарин кебек цитрус җимешләр үстерә торган махсус хуҗалыкка да алып бардылар. Шундагы бакчага кертеп җибәрделәр дә, үзләре теләгән кадәр җыярга рөхсәт иттеләр. И җыйдылар кинәнеп капчык-капчык мандариннарны, и җыйдылар!..

Теге карачкыларның берсе, түземсезләнеп, ниһаять, уң як кабыргага төртте:

– Йә... Нигә сүзсез терәлеп каттык әле?

– Кайсы яктан? Кайсы төбәктән? – дип өстәде икенчесе.

Тиешле вакыты җитеп, ниһаять, илче Хәбиб тә телгә килүне кирәк тапты:

– Абхазиядән мин... Пицунда каласыннан...

– Питсунда... Питсунда... – дип тел очында бераз әвәләп трды да, өлкән шымчы рифмалы нәтиҗә ясап куйды,– Питсунданы белми монда чуртым да!

– Питсундадан булгач... Ә сине Казан якларына нинди җилләр ташлады? – дип өстәде икенчесе.

– Күчтәнәч китердем.

– Нинди күчтәнәч?

– Мандариннар.

– Оһо-о, мандариннар! – дип теле белән иреннәрен ялап куйды өлкән шымчы. – Ә кемгә?

– Иң кадерле кешемә.

– Аның исеме бармы?

– Салих ага дип ишеткәнегез бармы икән?

– Ә-ә...Теге атаклы халык дошманының тагын да атаклырак җан дустымы?

– Минем өчен ул – иң яраткан композиторым!

– Нинди көйләрен беләсең?

– «Хуш, авылым!»

– Ыһы, бар андый җыруы... – диде өлкән шымчы һәм, бик белдеклеләнеп, сорап куясы итте. – «Наемщик» балетыннан теге Гөлйөзем ариясеме?

Музыкаль сәнгать өлкәсендәге мондый тупас буталуларга драматург Хәбибулла Фәтхуллин түзеп кала алмады:

– Юк! Балет жанрындагы әсәрдә бернинди ария дә була алмый! – диде ул кистереп. – Ә «Хуш, авылым!»а килгәндә... «Күзләр» драмасыннан ул ... Рәйсәнең беренче җыры!..

– Тагын, тагын?.. – дип сүзгә кушылды икенче шымчы.

Илче Хәбиб бу яшь шымчыны да бик тиз тиешле урынына утыртты:

– «Совет армиясе маршы»н ишеткәнегез булдымы?

– Маршал Будённый сәгать бүләк иткән көйме?.. Булды, булды!..

Наданлыклары телләренә чыккан бу мескен шымчылар илче Хәбибкә бик кызганыч булып китте:

– Будённый түгел, маршал Ворошилов бүләк иткән сәгать!.. Күренеп тора: күренекле сәнгать осталары яшәгән бу йорт тирәли тәүлек буе күзәтеп йөрсәгез дә, чормалар бигүк бай түгел икән сезнең.

– Гел көй дә көй... Ә зуррак әсәрләреннән? – дип сүз көрәштерүен дәвам итте өлкән шымчы.

– Әйтик, «Яшел шәл»...

– О-о, «Яшел шәл»!.. Халык дошманы Тинчурин белән икәүләшәп язган пычрак әсәр!

– Юк! Һәм тагын бер мәртәбә юк!

– Да-а!.. Чорма чумаданыңны буш дип булмый... Ә бәлки синең юл чумаданың да

шулай буш түгелдер, ә? – диде өлкән шымчы, ниһаять, үзе һөҗүмгә күчеп. – Йәле, ачып җибәр – күрик нәрсәләр барын!

Юл чемоданына охшатып эшләнгән зур сумка бикләнгән иде. Өске төймәсенә бер мәртәбә басып куюга, ул шыртлап ачылып китте, һәм кызгылт мандариннар, саргылт эфлисуннар белән лимоннар, тоташ бер агым хасил итеп, җиргә коелды. Аларның берничәсе, авыш җиргә туры килеп, хәтта ишегалды капкасына таба ук тәгәрәшеп китте.

Шулай нишләргә белмичә аптырашып торганда, ишектән кәкре башлы кул таягына таянган Сәйдәш үзе, аннары хатыны Асия Казакова килеп чыкты. Асия ханымны атаклы татар байлары Казаковлар нәселеннән икән дигәннәр иде. Шулайдыр. Эштән кыскартылган ире белән бер уңайлыклары булмаган кысан гына фатирда яшәсә дә, дөньяга шактый горур карый.

Асия Казакова – Сәйдәшнең өченче хатыны. Беренче хатыны Валентина, әтисенә гаҗәеп охшаган малай табып, яшьли үлеп китте. Икенче хатыны белән аерылыштылар. Ә менә өченчесе Сәйдәш кебек иҗат кешесен аңлый белә торган юньле хатын булып чыкты.

Илче Хәбибнең аны беренче күрүе иде әле. Шуңа күрәме, бер-берләрен өйрәнгәндәй, алар шактый гына үзара карашып торды.

Театрдагы вазифасыннан бушатылып, эшеннән китәргә мәҗбүр ителгәч, һавасы чыгарылган туп кебек, татарның бөек композиторы тәмам ябыгып-сүрелеп киткән иде.

Өстендәге киемнәре, аеруча җиң-балак тирәләре бушап, лыштырдап калган. Тиздән бит аның театр тамашачылары белән соң мәртәбә хушлашу кичәсе! Оркестр хәтле оркестр белән ул ничекләр генә дирижерлык итәр? Сәхнәгә соңгы тапкыр менү һәм, иң мөһиме, төшү өчен, ул үзендә ничекләр генә көч табар?! Сәхнә, бары тик сәхнә өчен яратылган йөрәге шартлап ярылмыйча моңа ничекләр түзәр?!

Каршыларында басып торган Салих Сәйдәшевне күргәч, шымчы-карачкылар тиз генә чалбар-күкрәк кесәләрен җирдә тәгәрәшеп яткан күчтәнәч җимешләре белән тутырды. Имеш, экспертиза ясату өчен! Агулап җибәрмәгәннәрме, янәсе. Аннары, күздән дә юк булдылар.

«Күзләр» драмасы һәм андагы гаҗәеп аһәңле җыр сүзләре авторын күргәч, Сәйдәшнең сүрән йөзе кинәт балкып-яктырып китте:

– О-о... Сине дә күрәсе көннәр бар икән, Хәбиб энем!.. Исән-саулар гынамы, бәгырь! – дип, аны хәлсез-ябык күкрәгенә кысты. – Ә бу җирдәге мандариннар син апкайткан Алжир күчтәнәчләредер инде, әлбәттә... Рәхмәт, бәгырь, рәхмәт!

– Күчтәнәчләр иде дә менә...

– Ә аларны теге кара карчыгалар җиргә коеп китттеме? Әйтәм аны, тизрәк таю ягын карадылар...

Кайчандыр уртак җимешле иҗат авторлары булган ике фикердәш, култыклашып, тиздән кысан гына фатир эченә кереп китте. Ә Асия ханым, зур табак-савытлар алып чыгып, шуларга җирдә кызарышып яткан күчтәнәчләрне тутыра башлады.

Бераздан чәй дә кайнап чыкты. Ул арада Асия ханым Казакова белән дә якыннанрак танышырга мөмкин булды. Ул йөз-кыяфәте ягыннан гына түгел, затлы-тәрбияле холкы белән дә Сәйдәшнең чит ирләргә еш гашыйк булган, шунлыктан аерылышкан икенче хатыны Сафия Әлнәевага бөтенләй охшамаган иде.

Илче күчтәнәчләреннен авыз итә-итә, «Күзләр» драмасының сәхнәгә менгән көннәрен искә төшерә-төшерә, тамак ялгап алдылар. Бу спектакльнең режиссеры ире Рәхим Тумашев вафат булып, ике баласы белән тол калган, коточкыч авырлыкларны җиңеп, Мәскәү хәтле Мәскәүдә театр институтын яңа тәмамлап кайткан

Кәшифә Тумашева иде. Кичке кочегарка уты яктысында күздән яшьләр китерерлек драма язып тәмамлаган студент Хәбибне дә башта ул табып ала. Медицина институтында көндез укып йөргән бу чибәр егет Кәшифәнең туган ягы Балтачка чиктәш Яңа Кенәр авылыннан була. Искиткеч тырыш һәм иҗади сәләтле егет! Драманың төп герое Рәйсә, сукырлыктан котылып, әсәр азагында яңадан күрә башлау бәхетенә ирешә. Аның кичерешләрен тамашачыны бик тиз үзенә җәлеп итә. Өстәвенә, яшь драматург Рәйсә җырының тирән мәгънәле, үтә гади һәм халыкчан сүзләрен дә яза. Ә композитор, искиткеч моңлы, киң сулышлы көен чыгарып, «Хуш, авылым!» дигән ул җырны үлемсез итә. Бу ике иҗатчыны табыштыру һәм таныштыручы да шул ук Кәшифә ханым була.

Баштарак шактый боек күренгән Салих Сәйдәшев, «Күзләр» драмасына бәйләнешле җылы истәлекләрдән күңеле ачылып китеп, бүлмә почмагындагы рояль каршына килеп утырды. Аны кайчандар яшүсмер Салихка, музыкаль сәләтен күреп, җизнәсе Шиһап Әхмәров бүләк иткән иде. Сәйдәш инде шактый искергән, ләкин үзе өчен ифрат кадерле булып кала биргән рояльнең тонык ялтыраулы капкачын ачып, аклы-каралы клавишларына бармакларын тидерде. Йөрәкләрне гаҗәеп рәхәт, гаҗәеп тансык хисләргә күмеп, илаһи моң авазлары түгелде:

Матур була, ямьле була
Яз көннәрең, җәйләрең...

Композитор Сәйдәшев янәшәдә утырган илче Фәтхуллинның кунадай түгәрәк иңбашларына хәл кереп киткән ябык кулларын салды:

– Дөресен әйтим: үземә дә бик ошый бу җыр. Ул, күп көйләрем кебек, озынкиң сулышлы, халыкчан-моңлы булып туды. Драмадагы язмышларны артык якын иткәнгә шулай килеп чыкты ул илче күчтәнәче. Аваздаш кушымчалар белән бик матур яңгыраган, ләкин артык образлы итеп әйтелгән соңгы сүзләрне ишеткәч, Хәбибулла Фәтхуллин ирексездән сорап куйды:

– Гафу итегез, Салих ага! Ә ни өчен илче күчтәнәче? Җыр – җыр инде ул! Ә ерак Алжир якларыннан мин җибәреп яткан татлы әфлисуннар яки мандариннар түгел...

– Юк, алай түгел, бәгырь!.. Син язган һәм академия театрында күп еллар гөрләп барган «Күзләр» пьесасы татар драматургисенә, ә андагы «Хуш, авылым!» татар җыр сәнгатенә СССРның Генераль консулы Хәбибулла Фәтхуллин тарафыннан кертелгән үзенә күрә «илче күчтәнәче» булды. Ягъни, образлы итеп, күчерелмә мәгънәсендә һәм киңәйтеп аңлаганда без моның белән горурланырга хаклы!..

– Шулай дисәгез генә...

Бераз сүзсез торгач, Сәйдәш көтмәгәндә сорап куйды:

– Ә исеңдәме, Хәбиб энем: Казанга элегрәк кайтуларыңның берсендә син туганнарың фатирында очрашу мәҗлесе җыйган һәм шунда мине дә чакырган идең.

– Хәтердә ул кичә, Салих ага, хәтердә...

– Менә шул мәҗлестә син, бәгырь, чит илдә яшәүче кешенең туган илен ничек сагынып яшәве турында бик матур шигырь укыган идең...

– Әйе, әйе... Укыган идем...

– Менә шуның сүзләрен кабат искә төшереп, мөмкин булса, язып та бирә алмассыңмы, бәгырь?

– Рәхим итегез, Салих ага! «Хуш, авылым!» җырына бик аваздаш юллар алар.

Дәвамы бар ■

Өстәл рәвешле гөслә

2015 елда Мари Иле Республикасында гөсләләрнең тагын бер яңа төре ачыкланды. Ул да булса – «өстәл рәвешле гөслә». Халык арасында аны «аяклы гөслә», яисә «тәпиле гөслә», – дип атыйлар. Өстәге уйнау тактасы (дека) өч аякка куелып, ярымтүгәрәк агач тартма эченә салынган. Әлеге тартманың капкачы бар, ә төбе юк. Музыка коралының гомуми озынлыгы – 91,5 см, киңлеге – 49 см, калынлыгы – 13,5 см, идәннән биеклеге – 73 см. Деканың үлчәмнәре: озынлыгы – 90,5 см, киңлеге – 48,5 см. Ул ике өлештән тора. Астан ике яклап өстәмә такта кисәкләре белән ныгытылган. Кыллар саны – 13. Тавышны көчәйтә торган 8 мм диаметрдагы биш түгәрәк тишеге бар.

Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

Аяклы гөсләнең хуҗасы – Галина (Галинә) Владимирова, ул 1940 елда Мари Иленең Мари-Төрәк районы Верхний Мир авылында дөньяга килә, хәзерге вакытта Йошкар-Ола шәһәрендә яши. Бу кабатланмас коралны аның өчен махсус 1960 еллар башында этисенең энесе – Сарафьон Архипов (1915-1985/86) ясаган булган. Архипов Сарафьон (халык телендә – Сарапый абый) – Татарстанның Арча районы Сәрдәбаш авылының данлыклы балта остасы, аның кул астыннан чыккан гөсләләрдә әле дә Таисия Ефимова һәм Халидә Мөхәммәтханова яратып уйный.

Өстәл сыман гөсләне өй тирәсендә генә кулланганнар. Сәхнәдә чыгыш ясар өчен Галинә апа үзе белән гади гөсләне йөрткән булган. Тәпиле гөслә әкренләп туза төшкән. Тора-бара капкачы, боргычлары алышынган. Баштарак чөйләр агачтан булса, соңрак тимердән эшләнелгән. Шуңа күрә дә гөсләне махсус җайланма (отвёртка) ярдәмендә көйлиләр. Кайбер кыллары өзелеп, уен коралы озак еллар хәрәкәтсез яткан. Үтенечемә колак салып, Галина ханым гөсләне яңартып җибәрде. Шуңа да килешле корыч гитара кылларын (Plain steel: PL010) сузып куйды. Нәтиҗәдә, «Авыл көе» («Сәрдәбаш көе»), «Күн авылы көе», «Арча», «Шахта», «Бию көе», «Алмагачы», «Күбәләк» һәм башка көйләрне язып алырга насыйп булды. Традицион үрнәкләр белән чагыштырганда, өстәл рәвешле гөсләнең тавышы бераз тоныграк чыга. Бу үзенчәлек аскы деканың юклыгы белән аңлатыла.

Мари Иле керәшеннәренең гөслә традициясе бик борынгылардан түгел. Мари-Төрәк җирлегендә халык, Арча, Балтач, Киров якларыннан килеп, 1920-1930 елларда гына төпләнә башлый. Мәсәлән, гөсләче Г.В.Владимированың эти-әниләре Верхний Мир авылына 1930 еллар тирәсендә Сәрдәбаштан күченеп килә. Биредә төрле традицияләр

Автор фотолары

Өстәл рәвешле гөслә

Галина Владимирова.
Йошкар-Ола, 2015 елның июне

кушылып (алар барысы да Казан арты төньягына карый, әлбәттә), яңа үсеш алган булган.

Ике яклы һәм өстәл рәвешле гөсләләрне мин, корылыш тәҗрибәсе, эшләп карау уңаеннан барлыкка килгән мисаллар, дип раслыйм. Андый үрнәкләр башка төбәк керәшеннәрендә очрамый. Хәтта башка халыкларга да хас түгел. Әйе, өстәл шикелле гөсләнең рус һәм удмуртларда таралуы билгеле. Тик аларда уен коралының формасы турыпочмаклы, ә бездә – ярымтүгәрәк. Ике яклы гөслә исә – тулысынча уникаль әйбер. Һәрхәлдә, мондый мәгълүматларга әлегә тап булмадым. Киләсе тикшеренүләр, бәлки, яңа ачышлар алып килер.

Эльмира Каюмова,
сәнгать фәннәре кандидаты. ■

Безнең мирас №3 март 2017

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТАЗЛАР *тар.* – Төрки кабиләләрдән берсе, үзатамалары – удэ. Бу кабилә хәзерге күпчелек төрки халыкларның (мәс., казакъларның, татарларның, башкортларның) этник составына кергән. 2002 елгы мәгълүматларга караганда, Ерак Көнчыгышта яшәүче удэларның гомуми саны – 276 кеше, телләре – рус һәм таз телләре, православие динен тоталар.

Кайбер галимнәр, әле Геродот үзенең «Тарихы»нда телгә алган *«ялтыр баш аргиппейлар»* атамасы хәзерге вакытта «тазлар» этнонимында сакланып калган, дип уйлый.

Шуны да әйтеп китик, патша Россиясе чорында Амур өлкәсендә яшәүче кытайлашкан удэгеларны тазлар дип атаганнар.

//Таслар аймак табышкан, тана суеп сыйлашкан. Себердәге кара татарлар әйтеме.

Ык елгасының уң кушылдыгы Тазлар суы дип атала. Түбән өлкәсендә Тазлар елгасы бар.

Тазлар – электә Татарстандагы авыл исеме. *(Иске Тазлар, Яңа Тазлар;* совет чорында бу авылларның исеме *Байкал* һәм *Ташчишмә* дип үзгәртелгән, безнеңчә, кадими атамалардан баш тартып, тарихка хилафлык эшләгәннәр). 2002 елгы халык санын алу мәгълүматларында Башкортстанда 4 кеше үзен таз милләтеннән дип күрсәткән, ә Татарстанда тазлар теркәлмәгән.

ТАЙГА – Себер татарлары сөйләшендә – саз, баткаклык. Рус телендә *тайга* сүзе 1847 елда гына теркәлгән. Аны төрки телләрдән алынма дип саныйлар (алтай телендә «тайга» *тау урманы* мәгънәсендә). Барлык башка телләргә ул рус теленнән кергән.

Тайгада вак куаклар юк чамасында, агачларның күпчелеге – ылыслы. Тайгалар коры җирнең 10%ын алып тора.

Коми телендә тайганы парма диләр.

ТАЛАК *г.* – Хатын аеру. *«Талак кылу, иреккә җибәрү»* мәгънәсендәге «талакун» сүзеннән.

Талак кылучы ир *талик* дип, ә иреннән аерылган хатын талика дип атала. *Митлак* – Талак кылучы (кушамат). Аллаһы Үзе рөхсәт иткән нәрсәләр арасында талак Аллаһ сөймәгән гамәлләрдән исәпләнә. Шуңа күрә талакны булдырмый калу өчен барлык мөмкинлектән файдалану зарур. Коръән-Кәримнең «Хатыннар» сүрәсендә 128 нче аятьтә болай диелә: *«Әгәр бер хатын иренең бизгәнен яки талак кылырга теләгәнен сизсә, бу хатын белән иренең арасын төзәтеп дуслаштыруда гөнаһ юктыр. Килешү, гафу итешү аерылышудан хәерлерәк.»* («Коръән тәфсире» буенча.)

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

Тартай арбасы (таратайка)



Тартай

Талак гыйбарәсенең ир тарафыннан ничә тапкыр әйтелүенә карап, кире кайтарылышлы һәм кире кайтаргысыз талак төрләре булган.

Талак сүзен өч тапкыр кабатлаудан соң, талак кире кайтаргысыз булып исәпләнгән. Ләкин әлеге гыйбарәне куллануда гарәпләр әллә нинди нечкәлекләр уйлап чыгарганнар. Мәс., *«Синең муеныңда бау», «Алжир шәһәрендә ничә чирәп булса, мин синең белән шулар санынча аерылам»,* дип әйтү *«өчле талак»* исәбенә кертелгән, ә *«Син минем хатыным түгел инде», «Син үз иркеңдә»,* дип әйтү бер тапкыр кабатланган гыйбарә булып исәпләнгән. *«Син яртылаш аерылган һәм тагын өчтән бер өлешкә талак кылынган»* дигән гыйбарә исә, мондагы өлешләрнең арифметик суммасы хәтта бер бөтенгә тулмаса да, ике тапкырлы талакка бәрабәр дип аңлатылган.

Ир белән хатынның аерылышуы хатын инициативасы белән эшләнгән очракта (хуль) никях яңартыла алмый. Бу вакытта хатын иренә, ул биргән мәһәрне кире кайтару өстенә, компенсация дә түләргә тиеш *(гыйваз).*

ТАЛЛАҺИ *г.* – «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (2005) гарәп теленнән алынма булуы күрсәтелгән. Алла исеме белән ант итү сүзе, «Орфографик сүзлек»тә *ымлык* дип искәртелә. Чыннан да, бездә ул гадәттә *билләһи, валлаһи* сүзләренә ияреп кенә йөри. Ш.Мәрҗани аны гарәби чыгышлы алынмалар исәбенә кертә һәм мәгънәсен *«Аллаһ (исеме) белән ант итәм»* дип аңлата. Төрек телендә *таллаһ(и)* – Алладыр, хактыр, дөрестән дә, чыннан да мәгънәсендә. «Таллаһи» – «тәгаллаһи»дан кыскарган сүз булырга мөмкин.

«ТАРТАЙ АРБАСЫ» – Шагыйрь Шәйхи Маннурның бер шигъри әкияте шулай атала. Бу әкияттә сөйләнгәнчә, «ике тартай, бер бытбылдык», ике тәгәрмәчле кул арбасына җигелеп, «Каф тау артына» – батман алтынга дип чыгып киткән, имеш. Асылда бу әкият фольклордан килә. Тик халык әкиятендә тартай, чыпчык һәм бытбылдык сәяхәткә дип кенә чыгып киткән һәм, сазга батып, адәм мәсхәрәсе булган, имеш. XX гасырның кырыгынчы елларында әлеге пессимистик әкияте өчен Ш.Маннурны сәяси гаепләп тә маташканнар иде.

«Тартай арбасы» сүзенең этимологиясе безне рус телендәге «таратайка»га китерә, *таратайка* исә ат җигүгә көйләнгән ике тәгәрмәчле гади арбадан гыйбарәт. *//Тратайка – ике йөгөртмәле, атка җигелә торган бәләкәй арба.* Тау ягы керәшеннәре сөйләшеннән. ■

ИСЛЕМАЙ САВЫТЛАРЫ

Татарстан Республикасы
Милли музее фондыннан

Татарстан Республикасы Милли музеенда күп кенә көнкүреш әйберләре, төрле чорларга караган хатын-кыз киемнәре һәм аксессуарлары саклана. Ислемай савытларының тарихы да бик үзенчәлекле. Шәрык илләрендә хушбуйларны эшләү ысулы камилләшә һәм башка илләргә тарала. Ефәк юлы аша көнчыгыш илләреннән безгә конус формасындагы фарфор савытларда хуш исле майлар кертелә. XIX йөздә Россиядә хушбуйларны ясау фабрикалары ачыла башлый һәм алар өчен

төрледән-төрле савытлар ясала. Шул дәвердән үк хуш исле майлар өчен бәллүр һәм пыяла савытлар иң яхшы һәм җайлы дип санала. Бүгенге көндә дә ислемай савытлары күп очракта пыяладан ясала, ә иң затлылары – бәллүрдән. XIX гасыр дворян йортларында төрле формадагы хушбуй савытлары коллекциясен очратырга мөмкин булган, хәзер инде алар белән бер кешене дә шаккатырып булмый.

Гүзәлия Җәләлева әзерләде. ■

Анна Ильинична Ульянованың бәллүр ислемай савытлары. Ленин музее экспозициясе

БӘРӘКӘТЛЕ УРМАН ТАРИХЫ

«Саба үзәкләштерелгән туган якны өйрәнү музее»ның урман хуҗалыгы тарихы музей-филиалы

2003 елда, урман хуҗалыгы ветераннары тәкъдиме белән, Лесхоз бистәсендә «Саба үзәкләштерелгән туган якны өйрәнү музее»ның урман хуҗалыгы тарихы музей-филиалы оеша. Ул 2004 елның 24 мартында (РСФСРның һәм ТАССРның атказанган урманчысы, Почёт Билгесе һәм Октябрь революциясе орденнары кавалеры Нургали Миңнехан улы Миңнехановның туган көнендә) ачыла. Әлеге музей Татарстандагы урман хуҗалыгы үсеше тарихын яктырта. Биредә меңгә якын экспонат саклана.

МУЗЕЙ ӨЧ БҮЛЕКТӘН ГЫЙБАРӘТ:

«Саба урман хуҗалыгы тарихы» бүлеге. Биредә Саба урман хуҗалыгының 70 еллык тарихы һәм урман хуҗалыгына кагылышлы вакыйгаларны чагылдырган документлар белән танышырга мөмкин. Үзәк экспозиция Нургали Миңнехановка багышланган, анда. атаклы урманчының шәхси әйберләре тупланган.

«Саба урман хуҗалыгындагы хайваннар дөньясы». Бу бүлектә киек кош һәм җанварларның карачкылары белән танышырга мөмкин.

Картиналар галереясы. Монда, Саба урман хуҗалыгының алдынгы хезмәткәрләре белән беррәттән, Миңнехановлар гаиләсе сурәтләнгән рәсемнәр дә урын алган.

Россиянең төрле төбәкләреннән тыш, музейга Кытай, Австрия, Греция, Финляндия, Вьетнам, АКШ, Швеция, Франция һәм башка чит илләрдән дә кунаклар килгән.

Безнең мирас №3 март 2017

Н.Миңнеханов: «Шулай матур итеп үсегез, кадерлеләребез!»

Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Россия Федерациясенең атказанган икътисадчысы МИННӘХМӘТ КАШАПОВ истәлекләреннән:

«Амур флотилиясенең укыту базасында үзебезнең чордаш офицерлар белән таныша башладык. Татарстаннан без элемтәчеләр ротасында өчәү идек: Арчадан – ***Мөхәммәт Мәһдиев****, Сарманнан –* ***Фәйзрахман Гыймазетдинов*** *һәм бу юлларның авторы. Берничә көннән соң, без яшәгән торакның икенче катында – механиклар ротасында Балык Бистәсе районыннан килгән тагын бер егет табылды. Соңыннан аның якташым, Тәкәнеш районының Игенче авылында туган* ***Нургали Миңнеханов*** *(булачак Президентыбызның әтисе!) икәнлеге ачыкланды. Шулай итеп, Татарстаннан дүртәү булдык!..»* (Кара: «Язмышым бүләге». М.Кашапов. – «Безнең мирас», №12, 2014).

***

«Без, Нургали белән (Балык Бистәсе районы хәрби комиссариаты 27 яшьлек Нургали Миңнехановны Хабаровск краендагы Амур флотилиясенә өч айга хәрби җыенга озата), төрле роталарда булсак та, җай табып, күрешеп сөйләшергә тырыша идек.

Салкын сугыш»ның көчәйгән еллары иде бу. Венгриядә ике система бәрелешеп тә алды. Илебезнең «Адмирал Кузнецов» исемендәге зур корабының Кара диңгездә шартлавын ишетеп борчылсак, Американың 60 мең тонна су сыйдырыш-

Ял вакытларында...

лы «Форрестол» дигән авианосецының дөнья океаннарында иркенләп йөрүе безнең күңелләрдә көнчелек хисләре тудыра иде.

Дөресен әйткәндә, минем дә, Нургалинең дә бу җыенга барасым килмәгән иде. Нургалигә җаваплы эш урынын, бигрәк тә яшь балалы гаиләсен, икенче баласын (Рөстәмне. – ***Ред.***) *табарга әзерләнгән хәләл җефетен калдырып китүе җиңел булмагандыр?!*

Ниһаять, хәрби җыенны тәгәлләп, без туган авылларыбызга кайттык. Яңа елның гыйнвар азагында, гаиләбезне нурлап-балкытып, кызыбыз Роза туды. Нургали белән Вәсиганың да, 1957 елның

Гариф Ахунов белән Нургали Миңнеханов

1 мартында, яз хәбәрчесе булып, икенче уллары – Рөстәм дөньяга аваз сала...

Шунысын да искәртеп үтим: танылган каләм әһелләренең Нургали кордашка, Вәсига ханымга һәм аларның үрнәк гаиләсенә атап язган байтак тезмә һәм чәчмә әсәрләре бар. Заманында Татарстанның халык язучысы Гариф ага Ахунов та биниһая хөрмәтле Миңнехановларга матур бер шигырен багышлаган иде». (Кара: Т.Нәҗмиев, М.Абдуллин. «Керик әле Саба урманнарына». – «Идел-Пресс» нәшрияты, 2000).

(Истәлек-язма М.Кашаповның «Шәхесләр: язмышлар балкышы» дигән китабыннан («Ихлас», Казан) алынды).

Урман хуҗалыгы тарихы музееннан фоторепортаж белән **beznenmiras.ru** сайтыннан танышырга мөмкин.

Безнең мирас №3 март 2017

Иске Казан

Равил Фәхретдинов

Монда, биек тау башында, алты гасырга якын элек зур учак янган. Көл катламының калынлыгына караганда, ул учакны кабат-кабат тергезеп җибәргәннәр булырга охшый. Борынгы бабаларыбыз, шушы учак янына җыелышып, көзге озын кичләрен монда җылынып уздырганнардыр. Учакны чакма чагып кабызганнар, чакмалары да шунда көл эчендә калган. Аннары тагын XV йөзнең башларында сугылган көмеш акчалар да бар; янчыгы-ние белән утка эләккән дә, янчыкның янып бетмәгән җепселләре исә көмешкә ябышып каткан, көмеше караеп-яшелләнеп калган. Учактан янә бизәкле чүлмәк ватыклары, атның баш сөяге, сарык сөякләре, балык һәм кош-корт сөякләре килеп чыкты. Калада яшәүчеләр ул учак янында җылынып кына калмыйча, тамакларын да туйдырган булсалар кирәк. Учакның калкурак җирдә, кала ныгытмалары янында булуын исәпкә алсаң, аны сакчылар якканлыгы ачыклана. Шунда инде күз алдында мондыйрак бер күренеш пәйда була.

Тау башында кальга урнашкан; аның әйләнә-тирәсендә имәннән коелган ныклы дивар, чат саен биек манара. Ул манараларда, дивар уентыларында, капка тирәләрендә ук-җәяләр, сөңгеләр, пищальләр (борынгы утлы корал) белән коралланган сакчылар басып тора. Ачык капкадан атлы сак астында төяүле олаулар чыга да сәүдә эшләре белән төньяк тарафларга юнәлә. Каршы яктан мари кенәзен озата килүче бер төркем җайдаклар күренә. Идел-Урал төбәгендәге олыс вә

кенәзлекләрдән йә илчеләр, йә башлыклар үзләре җыелышып беткән инде. Казан әмирендә бүген зур киңәшмә: Казан олысына мөстәкыйльлек алу мәсьәләсен кузгатырга җыеналар.

Ә каланың түбәнге өлешендә, елганың сул як ярында тормыш үз көенә баруын дәвам иттерә: чүлмәкчеләрнең, чуен коючыларның мичләреннән төтен бөркелә; тимерчеләрнең бертуктаусыз чүкегәне ишетелә; балта осталарының аяк астына йомычкалар коела... Шәһәр кешеләренең сөйләшкәне ишетелә, әнә тәгәрмәчләр шыгырдый. Нижгардан су юлы белән кызыл мал төяп килүчеләр янына сәүдәгәрләр ашыга; елганың югары агымында исә Казан суы башыннан килгән салларны сүтеп маташалар.Ерактарак, ухылдап, тегермән эшләп утыра, балыкчылар җәтмәләрен җыялар...

Ахшам җитә. Каравы алышына, шәһәр капкалары ябыла. Көн караңгылыгын ертып, тау башында учаклар кабына, аларга җавап биргәндәй, болынлыкта һәм яр буйларында ат саклаучы малайлар үз учакларын ягып җибәрәләр...

Үткәннәрне өйрәнүче археолог буларак, үзебез актарып ташлаган көлнең – әллә кайчан сүнгән-күмелгән учакның янында басып торганда, борынгы кала минем күз алдымда әнә шундыйрак булып гәүдәләнде. Шәһәрлекнең аеруча биек урыны шушында, моннан бөтен тирә-юнь уч төбендәгедәй күренеп, җәйрәп ята.

Һөҗүмнән саклану өчен моннан да җайлы урын юк инде анысы. Табылган әйберләрнең дә күпчелеге сугыш кирәкяраклары: тимер ук очлары, бүтән төрле тимер кыйпылчыклары, көбәдән калган боҗралар, кылыч саплары...

Игътибар үзәгендә булырга лаеклысы – үтәли тишекле балчык ядрә: андый сугыш коралының бөтен төбәктә очраганы юк иде, бу – искиткеч зур табыш. Аның янына бәләкәйрәк өч тимер ядрәне дә куярга мөмкин. Бу әйберләрнең моңарчы сукаланмаган, аскы катламда табылуы аларның, һичшиксез, Иске Казанның үзендә булуын исбатлый. Димәк ки, әлеге табыш Урта Иделдә беренче утлы коралның булганлыгы турында сөйли. Рус елъязмалары андый коралның XIV йөздә Болгар каласында кулланылганлыгын телгә алалар, әмма Иске Казан шушы үк төбәктәге шәһәр бит, хәтта әле көмеш тәңкәләрдә «Болгар әл-Җәдид» (Яңа Болгар) дигән тамгасы да очраштыргалый.

Иске Казан акча суга торган калаларның берсе була, ә инде Жучи олысы таркалган дәвердә, ягъни XV йөзнең 20-30 нчы елларында, Шәһри Болгар бу җирләрнең сәяси һәм икътисадый үзәге булудан туктагач, дәүләтнең төньягында акча сугучы бердәнбер шәһәр булып кала. Гомумән, сәяси-икътисадый үзәк ул арада Иске Казанга күчеп өлгерә. Шушында табылган жучи тәңкәләренең иң күбесе XV йөзгә карый диярлек. Өстәвенә әле без соңгы елларны гына (1972, 1983, 1984тә) акча ясау өчен әзерләнгән көмеш коелма кисәге, язулары язылып өлгермәгән тәңкәләр, шулар белән бергә үк язулы, тәмам әзер тәңкәләр. Гомумән, Иске Казан шәһәрлегеннән һәм әйләнә-тирәдән узган гасырларда ук шактый әһәмиятле табышлар булганы, хәтта акчалы хәзинәләр табылганы мәгълүм.

Узган гасырларда Көнбатыш Европа һәм Россия сәяхәтчеләре, татар фольклорчылары Иске Казан хакында халык арасында шактый риваятьләр җыялар. Ул тарих төрле кулъязмаларда, халкыбызның язма әдәбиятында да күп урын алып тора. Гәрчә әлеге язмалар шактый соң – XVII йөзнең азагы һәм XVIII йөзнең башында төзелгән булып, аларда тарихи шәхесләрнең исемнәре, вакыйгаларның еллары аз-маз буталса да, Казан тарихының башлангыч чоры буенча кызыклы мәгълүматлар бирәләр.

Немец этнографы һәм табигать белгече, Петербург фәннәр академиясе академигы, Россия буйлап күп тапкырлар сәяхәт иткән И.Г.Георги XVIII йөзнең 70 нче елларында Казан губернасы татарларыннан язып алган риваятькә генә тукталыйк. Шәһри Болгарны (кулъязмада ул Бряхимов, ягъни Ибраһим шәһәре дип атала) алгач, Аксак Тимер Габдулла ханны үтертә. Габдулланың уллары Алтынбәк белән Галимбәк качып кала алалар. Аксак Тимер киткәннән соң алар элеккеге мәркәзне торгызып маташмыйлар. Алтынбәк Казан суы буенда яңа кала корып җибәрә – шул Иске Казан була да инде. Әмма аның урыны төрле уңайсызлыклар тудыра, барыннан да бигрәк – хатыннарга тау башына су ташуы авырга килә, әнә шул сәбәпле, шәһәрне Казан суының Иделгә коя торган җиренә – ягъни хәзерге урынына күчерәләр.

«Утта янмас хан кызы турында хикәя»дә хәйран кызыклы мәгълүмат туплаган. Хан, дөресрәге, Болгар әмиренең кызының ни рәвешле исән калуын без инде шәһри Болгардагы Кара пулат уңаеннан беләбез. Шуннан инде хан кызын Аксак Тимер янына китерәләр. Җиһангир аның гүзәллегенә һәм акылына соклана да үз янына алырга карар кыла. Аның белән бергә ханның өченче улы Шәүнебәкне дә ияртә. (Монысының ничек итеп исән калганы әйтелми.) Аксак Тимер үлгәннән соң, болар аның улына хезмәт күрсәтәләр. Бервакыт, яшь падишах табын янында сыйланып утырганда, Шәүнебәк затлы бер савытны төшереп вата. Хөкемдар моның өчен гаепленең башын кисәргә әмер бирә. Аңа егетнең Болгар әмиренең улы икәнен искәртәләр. Шуннан Аксак Тимер улы егетне кичерә, әмма хан сараенда эзе булмасын, дип боера. Габдулла ханның кызы белән малае әлеге әсирлектән качып котылалар. Туган якларына кайтсалар – анда шәһри Болгар хәрабә хәлендә. Шуннан болар төньяккарак, Кашанга барып чыгалар. Анда абыйлары икесе дә исән икәнне, Казан каласын корып җибәргәнне ишетәләр дә шунда юл тоталар. Озакламыйча хан кызы Алтынбәк белән бергәләшеп Казан каласын корган гаскәр башлыгы Мулла Хуҗитазга кияүгә чыга. «Хикәя»дә тегесенең Иске Казандагы каберенә, әүлия кабере иттереп, зиярәт кылырга йөрүләре әйтелә; аның җәмәгате, риваятьнең каһарманы, ягъни янмый калган кыз каладан 2 чакрымдагы Әйшә зиратына күмелгәне хәбәр ителә.

Әүвәл «менла», тора-бара «мулла» булып киткән сүз бездә, «әфәнде» кебек үк, олылау билгесе булып санала. Гаскәр башлыгы булган чагында Мулла Хуҗитаз илгә-җиргә зур файда китергән

булса кирәк, шуңа күрә халык аны әүлиягә чыгарган. Аның кабере бүген «Мулла Хаҗи кабере» дип йөртелә һәм зур хөрмәткә лаек; анда үзенә күрә «хаҗ кылырга» дип якын тирәдәге авыллардан гына түгел, Казанның үзеннән дә, хәтта аннан арырак җирләрдән дә килеп йөриләр. Әйшә авылы янында аның җәмәгатен дә халык онытмый – «Гайшәбикә кабере», дип, хөрмәт күрсәтә. Хәер, тарихи чыганакларның берсендә авылның исеме тулырак – «Гайшәбикә авылы» дип йөртелә.

Искәртеп китәсе нәрсә шул: безнең төбәкне Аксак Тимер яулап алды, дигән фикер фәкать соңгы вакыттагы язмаларда, аннары тагын халык риваятьләрендә генә очраштыргалый. Чынында исә ошбу вакыйгаларда күбрәк Бату ханның кулы уйнаган булырга охшый, тарих һәм вакыт шуны күрсәтә; әмма риваятьләрдәге Бату хан исеме урта гасыр Евразиясендә бераз соңрак яманлыклар кылучы Аксак Тимер исеме астында күмелеп калган булуы да бик ихтимал.

Иске Казанның урынын археологлар ике җирдә дип билгелиләр: беренчесе – безгә мәгълүм Иске Казан (Камай) шәһәрлеге булып, ул Казан суының уң як биек ярында 6 гектардан аз гына күбрәк мәйдан биләп тора; икенчесе – Рус Урматы авыллыгы булып, анысы Биектау районының Камай авылы белән шул Рус Урматы арасында, Казан суы елгасының сул як үзәнлегендә, аның Урмат дигән тармагы буйлап 124 га мәйданны били. Шәһәрлек дигәнебез – Иске Казанның сәяси үзәге, кремле, кальгадан гыйбарәт; археологларның табышлары һәм тарихи язмалар күбрәк әнә шул өлешенә кагыла. Авыллык дигәнебез исә бернинди кальгасыз-нисез генә, Иске Казанның һөнәрчеләре, сәүдәгәрләре яшәгән бистәдән калган урын.

Бистәнең көньяктагы борынгырак өлеше XII гасырның азагына, болгар халкының Казан суы тирәләрен үзләштерә башлаган заманга туры килә. Монгол явыннан соң, чагыштырмача тынычрак, урманлы төньякта, тау башында кальга барлыкка килә. Тиздән ул яңа шәһәрнең сәяси үзәге булып китә. Ә инде үскәннән-үсә барган астагы ачык өлеше һөнәрчеләр бистәсенә әйләнә. Урта гасырлардагы бүтән шәһәрләр кебек үк, Иске Казан да нәкъ әнә шул рәвешле үсеп китә. Әлеге күренеш XVII йөзнең азагында тупланган **«Дәфтәри Чыңгызнамә»** дигән тарихи язмада шактый төгәл сурәтләнә: «Ханның уллары Алтынбәк белән Галимбәк, «кальга корып, шәһәргә нигез салдылар», – диелә анда.

Шәһәр үсә, анда һөнәрчелек һәм сәүдә эшләре, төзелеш, гамәли сәнгать шактый нык җәелеш ала. Археологик эзләнүләр нәтиҗәсендә табылган керамика, алтын-көмештән коелган бизәнү әйберләре, эш һәм сугыш кораллары, тимер һәм бакырдан ясалган йорт кирәк-яраклары, әле җитмәсә – металл коюу һәм чүлмәк ясау остаханәләре, торак йортлар, эпиграфика (ташка язу һөнәре), нумизматика әнә шул хакта сөйли.

Арада гаҗәп кызыклы нәрсәләр бар. Жучи тәңкәләрен һәм кайбер сугыш коралларын әйткән идек инде. Алардан тыш, тагын бизәкле көмеш һәм алтын балдаклар, бизәкле бакыр беләзекләр, алты кырлы җиз чукмар, гәрәбә һәм пыяладан муенсалар, зиннәтле әйберләр коя торган таш калыплар, кеше башы сурәтендә ак кургаштан коелган тәңкә һ.б. Эш һәм сугыш кораллары, йорт кирәк-яраклары дигәндә – кылыч сыныклары, сөяк саплы пычаклар, ат авызлыгы, матур бизәкләр төшерелгән сөяк хәнҗәр сабы, җиз көзге, җиз бизмән һ. б. әйтеп китәргә мөмкин булыр иде. Тагын әле агач тартманы бизәп торган гаять нәфис орнаментлы бакыр тасма, чабатачының шөшлесе дә бар. Балчыктан ясалган нәрсәләр арасында бәләкәй генә кара савыты, янә дә балчыктан коелган һәм гаҗәеп бай бизәкләр төшерелгән күптөрле савыт-саба, өстенә калын ялтыравык йөгертелгән кыйммәтле савытларның ватыклары, кытай чынаягы һ.б.

Әмма тора-бара, һөнәрчелек һәм сәүдә эшләре бик нык үсеп киткәч,

каланың зур судан еракта булуы сәясәт һәм икътисадның башында торучыларны канәгатьләндерми башлый. Шуннан инде Казан каласын Казан суының урта агымыннан Иделгә коя торган җиренә, елга тамагына күчерәләр. Казан каласының зур су юлына, Иделгә килеп төпләнүе, яңа сәяси һәм икътисадый үзәккә әверелүе тарихи әдәбиятта да, халык авыз иҗатында да лаеклы урын алган.

Яңа Казан барлыкка килгәч, Иске Казаннан халык, барыннан да элек, һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр тизрәк китү ягын кайгырта. Бүгенге көндә Камай шәһәрлеге тәшкил иткән кальгалы

өлеше генә хәрби үзәк буларак яшәвен беркадәр дәвам иттерә. Казан ханлыгы оешып җиткәнчегә кадәр җучи тәңкәләрен шунда сугалар. Шул ук вакытта ул төньяктагы бик әһәмиятле хәрби үзәккә һәм бертөрле кальгатөрмәгә дә әверелә. Нәкъ шул сыйфатында соңгы тапкыр Иске Казан рус елъязмаларында 1536 елда телгә алына: Җангали ханны, Мәскәү яклы булып татар халкына каршы сәясәт алып барган өчен, шунда китереп җәзалыйлар.

Фоторәсемнәрдә сурәтләнгән корылмалар Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Таттелеком» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры ***Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин*** *җитәкчелегендә төзекләндерелде һәм яңартылды .* ■

Безнең мирас №3 март 2017

Ядкярләргә – бер гасыр

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондыннан

1917 елның 2 марты

КАЗАН ХӘРБИ-СӘНӘГАТЬ КОМИТЕТЫ ЭШЧЕ ТӨРКЕМЕНЕҢ ЛИСТОВКАСЫ

Эшче гражданнар! Бөек вакыйгалар заманы. Петроградта халык иске хакимият белән көрәш алып бара. Дәүләт Думасының Вакытлы комитеты, халык һәм армия ягына күчеп, халыктан ярдәм итүне сорый.

Гражданнар! Без бар көчебезне башланган көрәшнең халык җиңүе белән тәмамлануына куярга тиешбез.

Оешканлык кирәк, бөек көрәшкә берләшеп катнашырга, гауга чыгара торган зарарлы чыгышлардан читләшергә кирәк, безнең дошманнарыбыз өчен генә файдалы булган мондый чыгышларны кискен тәнкыйтьләргә, эшчеләр оешмасын яңадан тергезергә, эшче депутатларны сайларга кирәк.

ТР ҮД ТСДА, листовкалар тупланмасы, №155.

1917 елның 23 марты

ЧИСТАЙ ӨЯЗ ҖӘМӘГАТЬ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ КОМИТЕТЫ БАШКАРМА СОВЕТЫНЫҢ ӨЯЗДӘГЕ ПРАВОСЛАВ ҺӘМ МӨСЕЛМАН РУХАНИЛАРЫНА ХАТЫ

Элекке тәртип тарафдарлары аңсыз крестьян гавамына төрле ышанычсыз һәм бернигә дә нигезләнмәгән гайбәт сүзләр тарата.

Чистай өязе халыкларының бар төркемнәре вәкилләре съезды шундый карар чыгарды: өязнең православ һәм мөселман руханиларыннан яңа тәртипнең дошманнары тарафыннан таратылган гайбәт сүзләрнең мәгънәсез икәнлеген халыкка аңлатуларын сорарга; иске тәртипкә кайту булмаячак һәм ирекле дәүләттә барлык гражданнар үз намуслары кушканча дин тотарга иреклеләр, диндә бернинди дә көчләү булмаячак, дигән үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә.

Әлеге карарны гамәлгә ашырганда, Өяз комитетының башкарма советы бу турыда өязнең руханиларын акылсызлыклар һәм хәтта аерым дин тотучы төркемнәр арасында дошманлыклар да булырга мөмкин икәнлеге турында кисәтә.

ТР ҮД ТСДА, ф.36, оп.1, э.147, 168б.

ИСХАК КАЗАКОВ ХАТЛАРЫ

1917 елның 30 марты

Кадерле һәм ягымлы Нәфисәкәй!

Гафу ит, кадерлем, шулай озак яза алмаганыма, эш белән нык мәшгуль идем, Солдат һәм эшче депутатлары советына депутатлар сайладык һәм шактый күп мәшәкать өйделәр, шуның өстенә, берничә комиссиягә язылганмын, барысында да эшләргә кирәк. 26 мартта минем инициатива белән мөселман корылтае җыелды. Без, әлбәттә, Петроградка якын һәм бездә беренче көннән үк асты-өскә килде. Полицейскийларның, жандармнарның барысын да кулга алдык, башта аларны казармаларда сак астында тоттык, ә аннары, революцион маршевиклар белән берләштереп, фронтка озаттык. Царизмга үҗәт тугрыларны бернигә карамый кулга алдык һәм кая тиеш – шунда олактырдык, генераллар һәм башка югарыдагы затлар белән дә тәкәллефләнеп тормадык. Бездә хәзер тулысынча тәртип, берәү дә солдат һәм эшче депутатларына каршы барырга җөрьәт итми. Солдат һәм эшче депутатларының башкарма комитеты – төбәктә иң югары хакимият.

Документлар урыс теленнән тәрҗемә ителеп бирелә.

Исхак Казаков



30 марта 1917 года.

Милая и дорогая Нафисочка!

Прости, дорогая, что так долго не мог писать – был до невероятности занят, выбрали депутатом в совет солдатских и рабочих депутатов и навалили массу хлопот, приходится с утра до поздней ночи работать в собраниях, к тому еще записан в нескольких комиссиях всюду приходится работать. 26 марта по моей инициативе было созвано мусульманское собрание представительствовал я и поэтому собранию не мало было хлопот, словом вспомнил я все старое 1905, 6 и 7 годы, "Дугачи-черепетово" у меня прошло теперь в полном смысле. Все же я от тебя очень мало получаю писем, вчера только получил два письма, благодарю его за старание, а ты пишешь в последнее время очень мало, письма твои коротки, не ясны, по всему видно, что ты чему-то дуешься, не сердись, портишь кровь не время, настал теперь час торжеству по окончании войны я ожидаю много хорошего и светлого, дай Бог только живым вернуться, а со стороны немцев, ведь, нам грозит злая большая опасность. Все же я думаю, что все это скоро прекратится и не будет уже больше того, что было.

30 мартта язылган хатның төп нөсхәсе

* * *

1917 елның 31 марты

...Яңалыклар әлегә безнең юк, искечә яшибез. Пасхага башкарма комитет концерт оештыра, барып карарга уйлап торам. Бирердә безнең көн саен митинглар, җыелышлар һәм лекцияләр. Лекцияләр бик кызык булгалый, аны Петербург һәм мондагы профессорлар укый. Сиңа тагын бер нәрсә әйтәм: азатлык игълан иткәннән соң, минем өстән авыр йөкнең яртысы төшкәндәй булды, шунда ук җиңеләеп киткәнемне тойдым, хәзер кысу-җәберләүләр, офицерлар, жандармнар һәм башка кабахәтләр яки төрле буржуйлар тарафыннан да мыскыллаулар юк. Без, бай булмасак та, хәзер ирекле һәм бернинди кыенсынуларсыз яшик, дип, Аллаһка дога кылам. Аларның байлыгы ни хаҗәтемә, миңа фәкать ирек һәм азатлык кына кирәк...

ТР ҮД ТСДА, ф. 30, оп. 12, э. 2.

Документларны басмага ТР Дәүләт архивы секторы мөдире
***Римма Садыйкова** әзерләде.* ■
E-mail: prm.archive@tatar.ru
www.arhiv.tatarstan.ru

ИСХАК МОСТАФА УЛЫ КАЗАКОВ – сәясәт эшлеклесе, педагог. 1876 елның 26 нчы декабрендә Казан шәһәрендә туа. 1897 елда Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Вятка губернасының Кадыбаш авылына җибәрелә, ә аннары Тәтеш урыс-татар мәктәбенә күчерелә. 1911 елда, укучылар арасында хакимияткә каршы пропаганда алып барганы, татар телендә сәяси төсмердәге җырлар өйрәнгәне өчен, кулга алына һәм гаиләсе белән Сембер губернасына, ә аннары, укытучы булу хокукыннан мәхрүм ителеп, Оренбург шәһәренә сөрелә.

Беренче Бөтендөнья сугышы башланганнан соң, М.Казаков армиягә алына. Оренбург, Пермь, Нарва, Юрьев калаларында хезмәт итә. Юрьевта Февраль революциясен каршылый: солдатларның революцион митингларын оештыруда, төрмәдән сәяси тоткыннарны азат итүдә катнаша. 1917 елның сентябрендә демобилизацияләнә һәм яңадан Тәтештә укыта башлый. 1918-1921 елларда Үзәк мөселман комиссариаты баш коллегиясенең төп әгъзасы, Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең нәшрият бүлеге начальнигы, РКП(б)ның Казан губкомы мөселман бюросы рәисе, 1921-1923 елларда ТАССР Үзәк башкарма комитеты Халык комиссарлары советының Президиумы рәисе урынбасары. ТАССР төзелү турында декрет имзаланганнан соң, ул Вакытлы революцион комитет составына сайлана. 1924 елдан педагогик хезмәттә. 1937 елда хаксызга репрессияләнә, 1939 елда төрмәдә вафат була. 1957 елда аклана.

Биредә И.Казаковның фронттан хатынына язган хатлары кыскартып тәкъдим ителә.

«Кояш» газетасында **«Казан хәбәрләре»:** 1917 елның март ае

Текстны басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мөгаллимнәр җыены

Мартның 8ендә Казандагы мәктәп вә мәдрәсә мөгаллимнәренең гомуми җыелышы булды. Мәҗлес мөгаллимнәр җәмгыяте тәшкил итәргә вә яңа хөкүмәтне тәбрик итеп телеграмма бирергә карар бирде вә вилаятьтә тынычлык саклау комиссиясенә Әхмәдҗан Мостафин һәм Мансур Ишмаев әфәнделәрне вәкил итеп сайлады. Бирелгән телеграмманың гыйбарәсе: «Петроград. Дәүләт Думасы рәисенә. Казан шәһәрендәге бөтен мәдрәсәләрнең мөгаллимнәре Русиянең яңаруына үзләренең олуг шатлыкларын һәм хөсне тәвәҗҗеһләрен [күркәм мөнәсәбәтләрен] изһар кыйлалар [белдерәләр]. Гомуми булган шатлык белән рухланып, милләтләрне аермаенча, бөтен гражданнарның мәнфәгатен бертигез күзәтеп торган яңа хөкүмәтне тәбрик итәләр. Яшәсен һәммә садыйк [тугры] угылларына сәгадәт өчен үзгәргән хөр Русия!» Казан мөгаллимнәреннән вәкил: Әхмәдҗан Мостафин.

Кояш. – 1917. – №1092. – 14 март.

Хатын-кыз митингысы

Кичә, 16 нчы мартта «Свет» театрында Казан мөселманнары хатын-кызына махсус митинг ясалды.

Имамнар арасында

Хөкүмәтнең зур идарәсе алмашу илә Казан имамнары да үзләренә махсус җәмгыять ясап, үз кирәкләрен вә дини кирәкләрен күзәтә башладылар. Аларның һәр көн диярлек җыеннары була вә җыеннары бик самимият вә иттифак белән бара.

Кояш. – 1917. – №1093. – 17 март.

Мосафир

Балаларга махсус «Ак юл» журналы мөхәррире Фәхрелислам Агиев кичә Мәскәүдән шәһәремезгә килде. Мәскәүдә мөселман хәрәкәтләренең эчендә йөри торган кеше булганлыктан, Фәхрелислам әфәнденең Казанга килүдән максуды Казан мөселманнарының соңгы тәшәббесләрен [керешкән эшләрен] өйрәнеп белүдер. Ул мөселман комитетының кичәге мәҗлесендә Мәскәү мөселманнарының хәрәкәтләре хакында мәгълүмат та бирде.

Кояш. – 1917. – №1093. – 17 март.

Мөселман приказчиклар

Казан мөселман приказчиклар һәм суд хидмәткәрләре бюросы чынлап эшкә керешү, «Болгар» мосафирханәсендә приказчикларга һәрвакытта җыелып

Даталар иске стиль белән бирелә.

киңәшү өчен номер алды. Бюро һәр көнне гади көннәрдә кич 5тән 10га кадәр, бәйрәм көннәрдә көне буе ачык булачак.

Эшчеләр арасында

17 нче мартта дары заводында эшләүче мөселманнарның җыелышы булып, үз араларыннан Мөселман комитетында иштирак итәр [катнашыр] өчен Нәсыйх Мөхтәровны вә Эшчеләр шурасында булыныр өчен Нәҗип Хәлфин вә аңа ярдәмче итеп Габдерахман Вәлидовны сайладылар.

Директорга нәфрәт

Казандагы мөгаллимнәрнең җәмгыяте өченче җыенында гавам мәктәпләренең директоры Васильевның мөселманнарга тигән зарарларын санадылар. Мөгаллимнәр, беравыздан: ул безне тәхкыйрь [мыскыл] итте, без дә аңа аерым бер мөгаллимнәр түгәрәге исеменнән нәфрәт итик, аңар протест бирик, дип карар бирделәр.

Кыскасы, мөселманнарга афәт булган Васильевны моннан соң мөселман мәктәп вә мәдрәсәләре өстеннән алып ташларга, аны директор дип танымаска карар бирделәр. Мөселманнарның үзәгенә үткән Васильевны руслар да белсеннәр, русларга да мәгълүм булсын, дип, рус матбугатына да язарга, дигән бер карарга килделәр. Безнең мәктәп вә мәдрәсәләремезнең башында уку-укыту эшләремезнең тамырына балта чабучы башка Васильевлар да булмасын, дип, җәмгыятьтә безгә мәктәп вә мәдрәсәләремезне, бу көннән башлап милли теләкләремезне үземез теләгәнчә эшләргә кирәк, дигән мәфһүмдә [эчтәлектә] хәрарәтле [кайнар] нотыклар сөйләнде.

Кояш. – 1917. – №1095. – 21 март.

Мөселман вәкилләре

Халык тынычлыгы вә куркынычсызлыгын саклау комитетына мөселманнардан 37 кеше сайланып кертелде. Башта руслар вә яһүдләр тарафыннан бу комитетка мөселманнардан фәкать биш вәкил генә кабул итәргә теләнсә дә, мөселман комитеты әгъзаларыннан берничә затның тырышып исбат итүләре вә хак уларак таләп итүләре аркасында, бара торгач, 37 мөселманны кабул иттеләр.

Мөхәррирләр вә гәзитәчеләр клубы

Мөхәррир вә гәзитәчеләрдән гыйбарәт берничә затлар, үзара җыелышып, Казанда мөселман мөхәррир вә гәзитәчеләренә махсус бер клуб вөҗүдкә китерү тугрысында фикер алышканнан соң, шул эшне башлап йөрүче бер комиссиягә тапшырганнар. Бу комиссия, башка милләтләрнең шундый клубларының уставларын тикшереп вә мөселман клубы өчен устав ляихәсе [проекты] тәртип иткәннән соң, Казан әһле каләменнән гыйбарәт олуг бер җыелыш ясап, шул эшне гарыз итәргә уйлыйдыр.

Кояш. – 1917. – №1097. – 27 март.

Кадыйр Сибгатуллин мәзәкләре

Якташлар. Сулдан уңга: Кадыйр Сибгатуллин, Сәет Шәкүров, Хәлим Җәләй

ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ СӘНӘГЕ

Колхоз болынында печән әйләндерәбез. Тәмәке тартып гәпләшеп туктагач, кечкенә бер сөйләшү булып алды:

– Шунда гына кадаган идем, минем сәнәкне кайсыгыз алмаштырды?

– Барыбер түгелмени? Сәнәк урынына сәнәк бардыр ич?

– Юк. Һәркемнең үз сәнәге булырга тиеш...

КОМАНДИРОВКА

Район газетасы редакторын хезмәттәшләре атна буе эштә очрата алмаган чаклар еш була. Ялт итеп күренеп ала да, Казанга китеп югала. Бу кайтуында беренче очраган кешесе җыештыручы Нәкыя апа булды.

– Исәнмесез, Нәкыя апа?! – дип, ерактан ук сәлам бирде мөхәррир. – Эшләр барамы?

Нәкыя апа ел буе күрешмәгән танышын очраткан кешедәй балкып китте:

– Шөкер, Мөхәммәт энем. Эшләр дә бара. Печәнне бетерделәр инде. Уракка төшәргә торалар бугай. Теге шәп яза торган малаең син юкта, исеме кем соң әле, Вәгыйзме, Вәзыйхмы, шул малаең армиягә китте. Әйбәтләп озаттык. Инде барып та җиткәндер.

Үзең соң, тагын командировкага кайттыңмы?

ЗЫЯН

Гонорар юып хезмәт хакы беткән.

ГАЗЕТА РЕДАКТОРЫ

Газета редакторы – кысыр сыердан бозау таптыручы.

АҢЛАШТЫЛАР

– Кичә кешегә охшамаган идең син.

– Рәхмәт.

– Менә бүген кешегә охшаган.

– Кызганыч.

МӘГЪНӘЛЕ ҖАВАП

Бер адәм бүлмә ишеген ачып карый да, түбәнчелек беләнрәк сорый:

– Иптәш Ишмөхәммәтов сез булмыйсызмы?

Бүлмә хуҗасы өч сүз белән ишекне әчтән ябып куя:

– Мыскыл итмәгез әле!

ҮТЕМЛЕ ЧАРА

Берәү төн уртасында исереп кайтып хатынына бәйләнә:

– Нишләп биш сәгать ишек ачмый торасың? Кайтмас дип сөендеңме?

– Бик тиз ачтым бит.

– Әйтәм кабаланасың, берәрсен күрергә зарыккансың икән.

– Сине көттем.

– Ни пычагыма дип йөзең карурман шикелле алайса? Мине күргәч кара көюеңдер инде.

– Киресенчә, бик күңелле чагым.

– Әйтәм авызың колакта. Кем белән сүз куешкан идең?

– Әйт әле, зинһар, нәрсә дип бәйләнүең бу? Кайтып кергәннән бирле бер генә авыр сүз әйтсәм иде үзеңә, ичмаса!

– Шул кирәк тә инде миңа. Ярар, әйдә тыныч кына йоклыйк.

ВАКЫТ ТӨШЕНЧӘСЕ

Дүшәмбе көнне иртән сөйләшеп утыралар:

– Бүген кайсы число инде?

– Егерме бише.

– Ай да беткән икән. Вакытны әйтәм, яшен ташымыни, шәйләми дә каласың. Менә гыйнвары да тулды, диген...

– Хезмәт хакы алырга бер атнадан кимрәк калды.

– Ә... Тагын бер атна... Ерак икән шул. Күзең күгәрер. Әзенә түзгәнне күбенә дә түзәрбез инде. Вакытны әйтәм, көзге болытмыни, узмаса узмый икән...

КОТЫЛГАН

Ике хатынны автобус кавыштырды. Авылдашлары, күрше-күләннәре, дусишләре, белгән-белмәгәннәре турында тәмле итеп бик акыллы сөйләшеп баралар:

– Әсмабикәләр ничек тора?

– Карты үлде, теге атнада гына җирләделәр.

– Китсәнә! Авырдымы?

– Юк. Эчеп үлгән, диделәр.

– Алайса... Котылган икән Әсмабикә. Исерек ир белән гомер иткәнче... Балалары барыемы?

– Җиде баласы белән калды Әсма.

– Ай Алла-а- а! Җиде бала диген! Ирсез башы инде нишләр икән?!

КАПКОРСАК

Абый армиядә иде. Без әни белән икәү генә торабыз. Тормыш авыр. Салган налогларны түләп бетереп булмый. Налог җыючы Н. безгә бик еш килә. Калын портфелен ачып куя да аннан кәгазьләр тартып чыгарып салкын гына әнигә күрсәтә.

– Менә, инде биш ай түләнмәгән. Булмый, биш көн түгел биш минут та көтә алмыйм. Теләсәң каян тап.

Шулай сөйләнеп утыра бирә. Аның болай гына китмәсен алдан ук белгән әни, иске бишмәтен киеп, әкрен генә чыгып китә. Мин беләм, әле бер, әле икенче күршеләргә кереп бер яртылык акча тапканчы, ул урамны әйләнеп чыгачак. Ә Н. көтә. Менә әни дә кайта, өстәлгә ярты менеп утыра. Әни актык йомыркаларны чоланнан алып кереп пешерә. Актык кисәк май чыга. Барысы да Н. ның корсагына кереп урнашканнан соң, ул, буш өстәлне комсыз күзе белән бер сөзеп чыга да, портфелен яба.

Ишек төбеннән «рәхмәт» сүзе ишетелә:

– Икенче килгәндә булсын, озак көтә алмыйм.

Фәния Хамматова *әзерләде.* ■



Шагыйрь, публицист Рәфикъ Юнысның Татарстан Республикасы бәйсезлеге өчен көрәшне чагылдырган саллы хезмәте. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 2000.

«Безнең мирас» *елъязмасы / март*

• 670 ел элек (1347)

Венециянең сенаты илчеләрен Алтын Урдага җибәрә. Гөлстан каласында үзара солых төзелә. Үзбәк хан заманындагы тәртипләр торгызыла, ике як та бер-берсенең товарларына 5 проценттан артык салым салмаска карар кыла. Татар дәүләтеннән чыккан товарлардан тамга (таможня) салымы алмаска килешенә.

• 90 ел элек (1927)

19-20 мартта Казанда яңалифчеләрнең беренче конференциясе була. «Яңалиф» җәмгыятенең рәисе итеп Фатих Сәйфи-Казанлы сайлана.

• 85 ел элек (1932)

1 мартта Ленинградта яңа оешкан татар дәүләт театры үзенең эшен Һади Такташның «Камил» әсәрен сәхнәгә кую белән башлый.

ТАПП секретариаты утырышында Һади Такташның әдәби мирасы, архивы мәсьәләсе тикшерелә.

• 75 ел элек (1942)

30 мартта шагыйрь Мифтах Вәдүт (1915-1942) яу кырында һәлак була.

«Совет әдәбияты» журналында Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повесте басылып чыга.

• 60 ел элек (1957)

24 мартта күренекле язучы Кави Нәҗми (1901-1957) вафат була.

• 55 ел элек (1962)

18 мартта язучы Габдрахман Әпсәләмов СССР Верховный Советына депутат итеп сайлана.

• 45 ел элек (1972)

«Казан утлары» журналында Фәнис Яруллинның «Җилкәнне җилләр еккач» повесте дөнья күрә.

• 25 ел элек (1992)

21 мартта Татарстанның дәүләт бәйсезлеге турында референдум үткәрелә. «Сез Татарстан Республикасының суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты буларак, Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы шартнамәләр нигезендә коруына ризамы?» – дигән сорауга референдумда катнашучыларның 61,39 проценты, «әйе», дип җавап бирә. ■

Мирасворд

Кятиб, Камалов

XIX йөз рус рәссамы

... - ачык

Актаныш һәм Зәй районнарындагы авыл

Капчыкка охшаган тире яки күн савыт, турсык (иск.)

XV-XVI йөзләрдә Казан ханлыгында ирекле хәрбиләр катлавы

Шагыйрь Бари ...

Юеш балчык (диал.)

Татар хатын-кызларының элекке бизәнү әйбере

Татар мифологиясендә карчык кыяфәтендәге урман рухы

... Батулла

Чокып ясалган агач табак (диал.)

Кайнатып киптерелгән ашлык оныннан әзерләнгән ашамлык

Борынгы грек һәм римлыларда балчыктан эшләнгән чүлмәк

Шириннең сөйгәне

Әрмәнстан акчасы

Борынгы Рим табибы

Австралия тәвә кошы

«Югары, бөек, күтәренке» мәгънәсендәге хатын-кыз исеме

Һуннар патшасы, Атилланың абыйсы

Хәсән Туфан поэмасы

Салават репертуарындагы җыр

Караиделнең сул кушылдыгы

Татар-монгол гаскәрләрендә йөз кешелек берләшмә командиры

Фәнзаман Баттал туган авыл

Билге

Ике башы беркетелгән арколы агач

Мәчет каланчасы

Җырлы-биюле уен

Җәнлек оясы

Астагы рәсем

Фин-угыр халкы

VII-XI йөзләрдә Азиядә яшәгән төрки телле кабилә

Морза, түрә

Кыргый, чыгымчы ат (диал.)

Нәсел, токым

Кузна, ашык уеннарында шакмакларга төбәп ыргытыла торган таяк

Он тузаны

Борынгы Персия һәм Кавказда: көмеш акча

... - ера

Мишәр абзые

2 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Султан уңга: Кот,«Афәт», угия,«Ил», Диас, Саимә, калта, Зәйнәп, ая, архив, Леду, анам, Рәсүл, Әрә, Садри, катлам, Галилео, Әхмәдиев, Кев, Крат, тугра, өре, Юнг.
Өстән аска: каба,«Фидая», Неарх, Хәлил, ата, Мәргән, сарт, даир, төн, Ликург, ЗИЛ, киерге, сәвер, Алвар, курай, Дәште, Таҗи, го, Индус, Кол, тирмә, Әпсәләмов.

Рәис Габдулла төзеде.



Безнен мирас №3 март 2017

СОДЕРЖАНИЕ

Историческое наследие: «Булгар. Колодец капитана»; «Странники» А.Мухаммадиев; «Вам от меня светлые пожелания ...» М.Файзи; «Полярная звезда исламского мира» Х.Валиахматов; «Задушевная женщина Бибигайша»; «Путешествие в Чефет кале» С. Шамси; «На земле моих предков» Ф.Табеев.

Религиозное наследие: «В мечеть пойду, когда состарюсь ...» Г.Баруди; «Исламский мир» Абдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Кутадгу билик» («Благодатное знание») Ю.Баласагуни; «Белое облако Чингизхана» Ч.Айтматов; «Галиябану», рожденная в муках душевных» Р.Шарафиев; «Шахнаме»/ «Книга царей».

Культурное наследие: «Гусли в форме стола» Э.Каюмова.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов» А.Тимергалин.

100 лет назад..: «Казанские вести» в газете «Кояш»: март 1916 года».

Шутливое наследие: «Весёлые парчи». К.Сибгатуллин.

Мирасворд.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT

Historic heritage: «Bulgar. The captain's well»; «The pilgrims» by A.Mukhammadiev; «The bright wishes from me to you...» by M.Fayzi; «The Polaris of the Islamic world» by Kh. Valiakhmatov; «The soulful woman Bibigaysha»; «The trip to the Chefet kala» by S.Shamsi; «On the land of my ancestors» by F.Tabeev.

Religious heritage: «I'll go to the mosque when becoming old...» by G. Barudi; «The Islamic world» by Abdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U. Balasaguni; «The white cloud of Genghis Khan» by Ch. Aytmatov; «Galiyabanu» written in soul torments» by R.Sharafiev; «The Shahnameh».

Creative heritage: «Table-shaped harp» by E.Kayumova.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin.

100 years ago…: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: March of 1916».

Humorous heritage: «Lively short stories» by K.Sibgatullin.

Mirasword.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

«Автопортрет».
Киндер,
майлы буяу

«Каенлык».
Киндер, майлы буяу

ФӘЙЗРАХМАН ӘМИНОВ
(1908-1984)

Фәйзрахман Габдрахман улы Әминов Пермь губернасының Кунгур шәһәрендә туа. Пермь сәнгать техникумын (1930), Ленинград сәнгать, сынчылык һәм архитектура институтын (1948) тәмамлый. Ул – СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1948), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1972), РСФСРның атказанган рәссамы (1984).

Фәйзрахман Әминов Габдулла Тукай әсәрләренә багышланган рәсемнәре, пейзажлары белән дан казана.

«Эңгер-меңгер».
Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САННАРДА:

● Замандашлары аны һәрвакыт елмаеп-балкып торган, җор телле, ачык күңелле кеше иде, дип сурәтли – юктан да кызык таба белгән, юкка да куанган. Әйе, бер карасаң, шаккатырлык ни бар соң? Язмабызның каһарманы Хәй Мушинский – иллюзия остасы, татарлар арасында бу жанрга нигез салучы, беренче татар фокусчысы лабаса, ул шундый, бая сурәтләнгәнчә булырга тиеш тә кебек.

Миләүшә Талипова.
АЧЫ АЛМА СУТЫ – ИРЕНДӘ...

● Урал аръягындагы Курган өлкәсенең Әлмән авылына Габдерәшит Ибраһимов һәм тагын алты шәкерт кышның чатнама суык вакытында килә. 500ләп шәкерт укый торган мәдрәсәдә аларга яшәр өчен урын табылмый. Әлмәнлеләрдә исә шәкертне фатирга кертү зур дәрәҗә саналган.

Әнвәр Кидрасов.
ДЕНЛЕ, ГАМЬЛЕ ӘЛМӘН АВЫЛЫ

«Безнең мирас» журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан киоскларыннан сатып алырга мөмкин.